1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 4 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

КЫЗ БАЛА
һәм ата
араларны нәрсә
якынайта

ҖӘЙГӘ
ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ
ашый-ашый...
ябыгу

яшәү өчен
КӨРӘШ
ачыктан-ачык

Альбина ФӘСХИЕВА: «Ярату кушылган ризык башка ул!»

PRESSA

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

■ «Бөтен Казанны әйләнеп тә туй күлмәге таба алмагач, Химиклар мәдәният йортына килдек. Рәт булып тезелеп киткән күлмәкләр арасында бердәнбер миңа туры килгәне дә, ни кызганыч, башка кәләшкә алып куелган», – дип искә ала әнием күлмәк тарихын. Һәм... могҗиза! Үлчәме туры килмәгәнгә ул кыз күлмәктән баш тарта. Ә әнием күлмәкле була! Ләкин аны тагын бер югалтырга туры килгән әле. Күлмәкне дус кызы үз туена дип сорап алган да, кире кайтармаган... Күлмәк әнигә берничә елдан соң гына кире әйләнеп кайта. Әниемнең туй күлмәге минем туемда да «кунак» булды. Аны киеп энемнең сөйгән кызы фәрештә ролендә чыгыш ясады. Ә бер елдан соң безгә килен булып төште ул.

Ләйсән МӨХӘММӘТШИНА.
Казан.
Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Ксения Богданова

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Альбина Фәсхиева
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 24.02.2022 ел.
Чыгу көне: 31.03.2022 ел.
Заказ О-0918
Тираж 9311

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык), П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



«Бизәк. Тормыш агачы». Алсу Тимергалина эше.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

Сабырлык

Йодрыгымда давыл йомарланган,
Ә мин челтәр чигәм тәрәзәмә.
Ябык тәрәзәмнең аръягында
Чебен сыман дөнья бәргәләнә.

Кайгыларым каеп-каеп кына,
Шатлыкларым көмеш төскә үреп,
Тәрәзәмә челтәр чигәм бүген.
Челтәрем нәкъ күршемнеке кебек.

Ул да әнә ак бизәкләр уйган,
Якты өлгеләре үткәннеке –
Үз йортының котын саклап кына,
Җирдән Ана булып үткәннеке.


Көн карасы йортка ябырылса,
Тәрәзенә ул да пәрдә тарткан.
Бисмилласын әйтеп, бишектәге
Сабыена ап-ак биләү япкан.

Бишек җыры итеп көйләп кенә,
Телле иткән, торыр җирле иткән.
Йодрыгына җан давылын йомып,
Имли-имли ак челтәрен чиккән.

Ул челтәрдән кояш нуры кергән,
Күк киңлеге иңгән, һава тулган,
Таңда былбыл җыры саркып кына,
Бишекләргә моңнар уя торган.

Үткәннәрдән откан өлгеләрдән
Иләп кенә дөнья өнен керткән.
Яманлыклар, йортка кералмыйча,
Тәрәз турысыннан үтеп киткән.

...Дөнья аръягында ниләр бардыр.
Тәрәз аръягында – кара чебен.
Давылларны йодрыгыма йомып,
Сабыр гына челтәр чигәм бүген...





Безнең тышлыкта

«Узган Рамазанда Балтачта ифтар өчен махсус наборлар әзерләдек. Халык аны өенә дә китертте, үзе килеп тә алды, бер-берсенә бүләк итеп тә җибәрде. Быел бу тәҗрибәне Казанда кабатларга телибез.»

10

Иң кайнар ризык
Гөлнур Сафиуллина







14

Мөстәкыйль тормыш
Ләйсән Рәхмәтуллина

18

«Хәзерге үсмерләр дә безнең кебек романтик»
Чулпан Галиәхмәтова

20

Нәфислек фанаты
Алсу Шакирова

Заман һәм без

Качаклар язмышы 6
Чулпан Галиәхмәтова

Татар дөньясы

Сагыну 24
Энҗе Фәйзрахманова

Зәр-зәр-зәрәгә! 28
Лилия Гәрәева

«Ирем бала караудан кача» 31

Мәдәни тормыш

Соңлаган сөхбәт Моңзадә 32
Сания Әхмәтҗанова

Ак туфлиләр 37
Лилия Гыйбадуллина

И-и, әнкәй... 39
Марат Кәбиров

Яшәеш

Тормышны үзгәрткән бер көн 44
Зилә Нигъмәтуллина

Дөм-Дөмнең зирәк кызы 48
Лилия Гәрәева

Бурыч дуслыкны бозмасын 51
Фәнзилә Мостафина

Яшәү көче кайда? 52
Чулпан Галиәхмәтова

Хуҗабикә

Яшь әни: сорау—җавап 56


Ач торып яшәрәбез 58

Мускулларны ял иттерәбез 59

Өйнең яме — гөлләрдә 62

Тест&йолдызнамә 63

34



Юл читендә
Ләбиб Лерон

40



Йолдыз
Эльмира Закирова

60



Сыр белән помидорлы самса
Венера Арсланова тәкъдим итә





КАЧАКЛАР ЯЗМЫШЫ



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Бер минутка гына күз алдыгызга китерегез әле: өегезгә кайгы килде, ди. Су басу, урман янгыннары... йә йортыгыз янында гына бомбалар шартлый... Инде ничә көн төн кунарга урын таба алмыйсыз. Хәер, тормышыгыз өчен куркып, күзегезгә йокы да керми. Көн буе йөрәгегез дөп-дөп тибә, сулышыгыз кысыла, кечкенә балагыз, яшьле күзләрен сөртә-сөртә, сезгә сыена. Ә аны юатырдай сүзләр таба алмыйсыз... Аңлыйсыз, тагын бер атна, бер ай һәм балаларыгызны ашата алмаячаксыз – чөнки акча эшләү мөмкинлеге юк. Берәр куркыныч хәл була калса, мөрәҗәгать итәр урын да юк, чөнки хастаханә дә, өегез кебек, хәрабә хәлендә. Нәрсә эшләячәксез? Шушында калачаксызмы, әллә ничек тә моннан китү җаен эзлиячәксезме? Куркыныч, әйеме? Качак язмышын теләп алмыйсың, ә яшәү өчен башка чара калмагач, шул язмыш белән ризалашырга мәҗбүр буласың. Донецк, Луганск республикаларыннан эвакуация игълан ителгәч, җирле халыкның күбесе кайда нинди чыбык очы туганы, ике сүз булса да алышкан танышы бар, шулар янына барып сыеныр өчен өйләрен калдырып китәргә ашыккандыр, мөгаен. (Әлеге язма әзерләнгәндә ул яклардан Россиягә 348 мең качак килгән, шуларның 73 меңе – балалар. – *Ч. Г.*) Тормыш иминлеген уйлаганда чакрымнар мөһим түгел. Югыйсә Донецк, Луганск, Горловка белән Казан арасы мең ярым чакрымнан артык. Атышлар барган җирдән бер сумка белән генә читкә чыгып китүчеләрнең тарихын тыңлап карыйк.



Фото: www.pixabay.com

Татарларым...

Баш өстендә тыныч күк эзләп, үз юлы белән Казанга ук килеп җиткән Донецк, Луганск качакларын вакытлыча «Ливадия» санаториена урнаштыралар. Фотограф Анна Арахамия белән шунда юл тоттык. Татар матбугаты вәкилләре икәнебезне белгәч: «Анда бер татар әбие дә бар», – диделәр. Яшьләрне, балалы гаиләләрне очратырбыз дип уйлаган идек, әмма өлкән кеше белән аралашырбыз дигән уй башыбызга да кермәде. Санаторийда бер корпусның соңгы катын качакларга биргәннәр. Әкрен генә ишек шакыдык. Ишекне спорт чалбары, яшькелт кофта, кызыл бәйләм башлык кигән әби ачты. Башлыгы астыннан чәчләре тузгып чыккан. Татарча «исәнмесез» диюгә, тешсез авызлары белән елмаеп, «татарларым», дип кочаклап та алды, елап та җибәрде.

– Әле менә телевизордан күрсәттеләр, безнең йорттан ерак түгел генә «Точка У» килеп төшкән. Аны безнең ДНРчылар бәреп төшергән. Ярый әле ныклап шартламады, фатирсыз кала идек бит, малай җаным, фатирсыз кала идек...

– Каян Украинага барып эләккән идегез соң? – дип кызыксынам Былбыл ападан.

– Киров өлкәсендә тудым мин, Мари Илендә үстем. Гаиләдә төпчек бала идем – алтынчысы. Инде барысы да үлеп беттеләр, ялгызым калдым. Казанга килеп, педагогика институтының химия-биология факультетында укыдым. Татар булганга килдем Казанга, югыйсә Йошкар-Олада да бар иде институт. Татарларны бик яратам. Һәр татар – туганым кебек... Яшьлек бит, укып бетергәч, БАМ төзергә киттем. Анда химия лабораториясе мөдире булып эшләдем. Чәчләрем бик нык коела башлагач, бер табиб: «Чәчләреңне саклыйсың килсә, кит син моннан», – диде. Ул вакытта абый Донбасста шахтада эшли иде. Шул акча өчен китте инде. Аның артыннан бөтен туганнарым шунда күченде. БАМнан кайтышлый абый янына кергән идем, кал монда, диде. Калдым. Эшкә урнаштым. Ял вакытында дус кызыма Салават шәһәренә кунакка кайткач, Рим исемле башкорт егете белән таныштым. Ул миннән җиде яшькә кечкенә иде. Институтта юридик факультетта укый. Өйләнештек тә шунда калдым. Өч ел буе техникумда биология укыттым. Анда химик комбинат бар иде, шәһәрдә һава начар. Тоттым да кире Сталинога (Донецк шәһәренең элекке исеме – *Ч. Г.*) киттем. Укып бетергәч, ирем минем янга килде. Шулай яшәп калдык Донбасста.

– Ирегез белән ничә ел яшәдегез, Былбыл апа?

– Ник яшәдегез? Яшибез. Менә 45 ел булды бергә яшәгәнгә.

– Ул исәнмени?

– Исән, әмма килмәде бит менә. Калды шунда.

– Сез балаларыгыз белән чыгып киттегезме?

– Безнең балалар булмады. Бала таба алмадым. Лабораториядә бензол белән эшләгән идем. Соңыннан гына укыдым: бензол баласызлыкка китерә икән.

– Өегездән ялгызыгыз гына чыгып киттегезмени? – дип, аптыраганнан кабат сорау бирәбез.

– Әйе, билгесезлеккә чыгып киттем. Чыгып китмәсәм, куркудан йөрәгем ярылып үлгән булыр идем. Тыныч кына яшәргә ирек бирмиләр бит. Бар иде бит ул андый чаклар. Мин – балалар бакчасы мөдире, ирем юрист булып эшләде. Лаеклы ялга чыктык. Әмма картлыкны тынычлыкта уздырырга язмаган икән. Сигез ел бит инде атыш астында яшибез. Сигез ел буе беркая чыкмый көн күрдек. Бездән ерак түгел базар бар. Шунда азык-төлеккә тиз-тиз генә барып кайта идек. Атыш тавышлары ишетелә башласа, исән кайтып җитәмме, юкмы, дип, өйгә йөгерә идек. Шулай яшәдек, малай җаным. Өйне ташлап китәсе түгел идем. 19 февраль көнне көндезге сәгать өчтә шәһәрдә сирена уларга тотынды. Урамга йөгереп чыктым. Кая барырга белмим, мин инде киң масштаблы сугыш башланды дип уйладым. Котым очты. Өйгә кергән идем, бабай телевизор ачкан. Аннан Пушилин эвакуация башланды, дип сөйләп ята. Мин шунда ук: «Китәбез», – дидем, ә бабай карышты: «Минем акчам юк, беркая китмим. Үләм икән, язмышыма шулай язылган, димәк», – диде. Менә шундый кире инде ул. «Ә мин китәм, алайса куркудан йә инсульт, йә инфаркт була. Монда калсак, икебезне дә үтерәчәкләр. Ә бәлки мин исән калырмын, ә бәлки син исән калырсың, мин үләрмен», – дидем дә, полиэтилен пакетка документларымны, әйберләремне тутырырга керештем. Бабай китмә, димәде. Без җыенып килгәнче автобуслар китеп беткән иде инде. Икенче көнне иртән торгач, тагын җыендым. Бабай озата бармакчы иде, «Барма, өйдә утыр, йә башыңа бомба төшәр», – дидем. Бер көтү хатын-кыз, бала-чага автобуска утырып Ростовка киттек. Безгә атмасалар гына ярый, бомба төшмәсә генә ярар иде дип теләп бардым. Автобусларга аталар икән, дип тә сөйлиләр иде бит. Россиягә чыгып, бераз юл үткәч, автобуслар туктады. «Без сезне Ростовка түгел, шәһәрдән 350 чакрым ераклыктагы авылга илтәчәкбез», – ди шофер. Хатыннар шаулаша башлады. Бөтенесенең Ростовка барасы килә. Безгә бит, шунда алып бара-

Картлыкны тынычлыкта уздырырга язмаган икән. Сигез ел бит инде атыш астында яшибез. Сигез ел буе беркая чыкмый көн күрдек.



чакбыз, каршы алачаклар, дип әйткәннәр иде. Бер хатынга – кызы янына Кырымга, икенчесенә – Мәскәүгә, өченчесенә Таганрогка барырга кирәк. Авылга барырга теләмәгәннәр автобустан төшә башлады. Киңәшләшер кешем юк бит инде минем, карап утырдым-утырдым да, мин дә аларга ярдәм. Ике хатын машина туктатты. «Әйдә, безнең белән, азрак түлисе булыр», – диләр. Төнгә каршы юлда басып кала алмыйм бит инде, утырдым да киттем. Үзем барам, үзем уйлыйм. Ростовта минем беркемем дә юк, кая барырга инде миңа хәзер, дим. Уйладым-уйладым да, татарларым бар бит, алар янына барам, дип, Казанга барырга карар кылдым. Безне Ростовка алып барган машина шофёрына бер мең сум түләдем. Ул безне тимер юл вокзалы янында калдырды. Тиз генә кассага йөгереп бардым да Казанга кадәр билет сорадым. Билет бәясе 2912 сум, диделәр. Егылып китә яздым. Билет бәяләре ничек күтәрелгән! Ә мин өйдән бары тик 4 мең сум акча белән чыгып киткән идем.
Алты сәгать поезд көтеп утырдым. Аннан поездда 38 сәгать килдем.

– Нәрсә ашадыгыз соң? Сезнең бит бер тиен дә акчагыз калмаган.

– Борчылган вакытта тамагымнан ризык үтми минем. Инде бик ашыйсым килгәндә кайнаган су эчтем. Ашау кайгысы түгел иде бит, Казанга төшкәч, кая барырмын дип уйландым. Монда 50 ел булганым юк! Поезд начальнигы тимер юл вокзалында кизү торучыны эзләп табып, аңа мөрәҗәгать итәргә кушты. Төшүгә үк шулай эшләдем дә. Мине бер бүлмәгә алып кереп сораштырдылар, бушлай ашаттылар. Төнгә социаль яклау министрлыгы кешеләре шушында алып килеп урнаштырды. Ә монда мине кунак каршылаган кебек кабул иттеләр. Бүлмәм чиста, телевизор бар, дүрт тапкыр ашаталар. Әкияттә яшәгән кебек яшим дә, җанда гына тынычлык юк. Бабай белән атнага бер-ике шалтыратышабыз. Хәзер мине ташлап киттең, ди. Монда чакырам. «Юк, кеше хисабыннан яши алмыйм», – ди. Артык горур инде ул минем, бик тыйнак. Шунда фатирда яшәп ята. Самолетлар гүләп очканда хәтта подвалга да төшеп тормый. Әле ул 2014 елны да Донецк өчен көрәшкә дә бармакчы иде. «Урам аркылы бер татар китте, мин дә барам», – дип йөрде. Көч-хәл белән генә бармаска күндердем.

Хәзер монда уйланып ятам инде. Нишләргә? Кире кайтыр идем, әле бәрелешләр бетмәгән. Техногенлы катастрофалардан куркам. Гомер буе монда тотмаячакларын да аңлыйм, картлар йортына да барасым килми. Тулай торактан берәр бүлмә бирсәләр, бабай да килер иде. Ләкин аны миңа кем бирә? Мин монда кемгә кирәк? Беркемгә дә кирәк түгеллегемне аңлыйм. Әлегә ашаталар, рәхмәт. Без инде, олигархлар белән чагыштырганда, хәерче халык. Тынычлап үләргә дә ирек бирмиләр бит. Монда күкләр тыныч та, күңелдә тынычлык юк. Иртәгәсе көн билгесез. 75 яшемдә кеше бусагаларында йөрермен дип уйламаган идем шул...

Былбыл апаның Казан тирәсендә бер-ике танышы бар булып чыкты. Телефонын көйләп биргәч, аларга шалтыратты ул. Аһ-ваһ килеп, Былбыл апаны тыңлап тордылар, әмма берсе дә «миңа кил», йә булмаса «яныңа килеп китәм», дип әйтмәде. Шалтыратышырбыз әле, дип саубуллашты ул алар белән. Кабат шалтыратканда алырлармы телефонын, билгесез...

Улым хакына...

– Монда бары улым хакына гына килдем. Тормышымны үзгәртергә теләмәгән идем. Китик, дип ялынды Никита, – ди Донецк өлкәсе Горловка шәһәреннән украин сөйләмле Лариса, – 2014 елда тыныч тормыш беткәч, олы улымны Казандагы дусты үзенә чакырды. Ул йөргән кызын алып Горловкадан Татарстанга китте, ә без кечкенә улым белән Кырымдагы танышларыбызда яшәп тордык. Ул вакытта дәүләттән ярдәм булмады, гап-гади кешеләр булышты. Өч атна анда яшәдем дә, беренче ирем янына Ново-Луганскига киттек. Анда да яшәргә уңайлы шартлар юк иде. Уку елына кадәр яшәдек тә, кире Горловкага кайттык.

2014 елда безнең уку елы октябрьдә генә башланды. Ул вакытта бик озак бомба җибәреп яттылар. Сигез ел шулай дәвам итә инде. 2016 елда кабат ныклап һөҗүм иттеләр. Безнең янда гына мәктәп һәм хәрбиләр ял итә торган урын бар иде. Шуларны бомбага тоттылар. Баш өстеннән ут ядрәсе очканда бары балаңның гомере турында гына уйлыйсың икән ул. Танышларымнан әҗәткә акча алып, Никита белән Казанга чыгып киттем. Никитаны абыйсында калдырдым да, ике көннән соң Горловкага кайттым.

Бераз тынычлангач, улым артыннан кире бардым. Шулай Казан белән Горловка арасын таптадым.

Поездда йөрергә яратам. Поездда рәхәт. Ә аннан чыгасың да башыңа кабат уй төшә: нишләргә? Россиядә беркемем юк. Монда Сашка бар. Никитаның шуңа бирегә киләсе килде. Озак ятарбыз, документлар эшләтербез дип уйламаган да идем. Өч-дүрт көннән төгәлләнер дә, кире кайтып китәрбез дип йөрдем. Хәзер менә безгә паспортлар ясаталар. Аның белән Горловкага да кайтырга була, диделәр. Минем кайтасым килә, чөнки өем анда. Ике фатирым бар. Фатирларым исән калсын иде дип сорыйм Ходайдан. Әгәр монда җүнле ир очратсам, калачакмын. Бу хәрби операцияләр кайчан бетә әле, аннан соң анда бушлыктан башка берни булмаячак. Улым монда мәктәпкә урнашты. Сыйныфташлары белән бик тиз уртак тел тапты. Ул бит минем вокалист. Хорда җырлый иде. Монда да музыка мәктәбендә укый. Әмма, сезнекеләр белән чагыштырганда, белем дәрәҗәсе түбән. Беренчедән, сездә алты көн укыйлар, бездә биш кенә көн укыдылар. Әлбәттә, программа да авыр. Үзегез аңлыйсыз: сигез ел киеренке хәлдә яшибез. Нинди нормаль уку процессы булсын инде?! Ватсап аша белем алып булмый ул. Балалар, нигездә, интернет аша укыды. Укумы инде ул?! Монда да пандемия вакытында онлайн белемгә күчеп, балалар бик яхшы белем алдымы әллә? Ә бездә һәрвакыт диярлек онлайн уку. Имтиханнарга әзерлек бөтенләй булмады. Әле бит мәктәпне тәмамлау гына түгел, укырга да керергә кирәк. Никитаның музыка буенча белем аласы килә. Моның өчен аңа игътибар итүләре кирәк. 2014 елда «Ливадия»дә безнең кебекләр ел ярым яшәгән. Аннан соң кая киткәннәрен белмим. Олы улым белән киленем авиация заводында эшлиләр. Улым бик эшчән минем. Балабызны карап торырыга кил, диләр, әмма бармыйм. Сәламәтлегем юк, киленемне дә яратмыйм. Эш тәкъдим итеп килүчеләр бар, әмма беркая да бармыйм. Беренчедән, авырыйм, икенчедән, күп эшләдем инде, ял итәсем килә. Тик нинди ял инде бу?! Минем бит монда кер юу машинам да юк. Кешеләргә биреп юдыртам керләремне. Чәчемне буярга буяу, эчке киемнәр кирәк. Тешләрем начар, аларны дәвалар идем, әмма стоматолог хезмәте Казанда бик кыйммәт. Кешеләр яхшы монда. Урамда маршрут сорасам, сөйләмемнән Украинадан булуымны аңлыйлар. Шундук ярдәм итәргә ашыгалар.

Иремне калдыра алмыйм



Үз юллары белән Казанга килеп егылган качакларның күбесен шәһәр белән тоташтырып торучы нәзек кенә җепләр бар. Күбесенең туганнары 2014 елдагы конфликт вакытында монда килеп урнашкан. Луганскидан килгән Витаны да Казан белән бәйләүче җеп бар: иренең әниләре монда икән. Алар да беренче бәрелеш вакытында Татарстанга килеп, «Ливадия»дә яшәгән, хәзер кечкенә генә фатир арендалап торалар. Шәһәрдә эвакуация башлангач, Вита да, баласын алып, туганнары белән чыгып китә. Казанга киләләр. Аның белән «Ливадия» ашханәсе ишеге төбендә сөйләшәбез. Саргылт чәчле яшь хатын монда эшкә кергән. Эш урынымнан киткәнемне белсәләр, ачуланырлар дип, безнең белән тиз-тиз генә сөйләште. Витаның ире Донецкида калган. «Безнең янга килеп җитәр дип бик өметләнәм. Дусларын хәрби операциягә катнашырга җибәргәннәр иде, күбесе табутта кайтты. Иремне югалтасым килми. Аның бәрелешләрдә катнашуын теләмим, – ди Вита яшь белән мөлдерәмә күзләрен еракка төбәп. – Әмма анда да кала алмый идем. Балабызның гомере өчен курыктым. Автомат тавышлары, стресслар бала психикасы өчен бик куркыныч. Монда килгәч, ул тынычланып калды. Мәктәпкә йөри, дуслары бар. Аның өчен сөенәм. Анда бит инде сигез ел куркып яшәдек. Луганскида тынычрак булды әле, шәһәр читләрендә генә атыш тавышлары ишетелде, ә Донецкида һаман һөҗүмнәр булып торды, диләр. Сез андый тормышны күз алдыгызга да китерә алмыйсыз. Без дә кинолар аша гына белә идек. Телевизордан карап кына бөтен нәрсәне тоеп бетереп булмый икән... Башыбызга төшкәч кенә аңладык. Бик куркыныч! Төнлә, ядрә тавышын ишетеп, сикереп торып утырасың, нишләргә дә белмисең. Балаңны кая качырырга белмисең. Үзең өчен түгел, балаң өчен куркасың. Монда тыныч. Әмма яшәргә кирәк. Акчасыз утырып булмый бит, шуңа эшләргә кирәген дә аңлыйм. Безгә һәр көнне ярдәм итәләрдер дип уйламагыз. Яшәп китәргә шартлар тудырган өчен дә рәхмәт. Ирем фатирлар ремонтлый иде, соңгы елларда йөк ташучы булып эшләде, чөнки эш юк. Акча өчен теләсә нинди эшкә алынырга әзер буласың инде. Аның килүен көтәм. Ул да килсә, Казанда төпләнеп калыр идек. Әле ярты ел эчендә генә чыгармаслар. Ул вакытта да килмәсә, үзебез кире кайтачакбыз. Иремне анда калдыра алмыйм бит инде...»

Фото: Анна Арахамия

ИҢ КАЙНАР РИЗЫК

Кейтеринг – безгә инглизләрдән кергән сүз. Ризыкны өйгә (гомумән, заказчы теләгән теләсә кайсы урынга – офиска, табигатькә, бакчага) китерү һәм ресторанча хезмәт күрсәтү дигәнне аңлата ул. Ресторан бизнесында чагыштырмача яңа тармак булса да, бу өлкәдә инде конкурентлар җитәрлек. Әмма «Татар кейтерингы» хуҗабикәсе, Татарстан пешекчеләре гильдиясе әгъзасы Альбина ФӘСХИЕВА оештырган кейтеринг хезмәтенең башкалардан аермалы ягы бар: ул – хәләл һәм төп ризыклары – милли аш-сулар. Тагын аның турында: «Сыйфаты – Мәскәү дәрәҗәсендә», – дип тә әйтәләр.
Альбина ханым белән кейтеринг хезмәте турында сөйләшәбез. Хәер, аның хакында гына да түгел.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Мин үзебезне рәссамнар белән чагыштырам: табын әзерләгәндә без дә иҗат итәбез.

Кейтеринг белән шөгыльләнү идеясе сезгә кайдан килде?

– Сүзне ерактанрак башлыйм инде алайса, бу өлкәгә ничек килүемнән үк. Беренче белемем буенча икътисадчы мин, университетны кызыл дипломга тәмамладым. Бер үк вакытта инглиз теленнән тәрҗемәче булырга да укыдым: ул югары уку йортыннан да кызыл диплом белән чыктым. Сигез ел «TatCenter.ru» интернет-порталының реклама бүлегендә эшләдем: баннерлар, мәкаләләр сату белән шөгыльләндем. Төрле дәрәҗәдәге кешеләр, җитәкчеләр белән аралаштым. Ул елларда туплаган тәҗрибә миңа әлегәчә эшемдә ярдәм итә... Ә аннан беркөнне әти: «Кызым, Балтачта кафе бинасын алу мөмкинлеге бар, тотынып карамыйсыңмы?» – диде. Балтач – миңа ят җир түгел, әтиемнең туган ягы ул. Дөрес, балачагым, яшүсмер елларым әнинең туган ягында – Кукмара районы Поршур авылында, әби белән бабай янында узды. Авыл тәрбиясе миндә бик нык сизелә. «Син шәһәр кызына охшамагансың», – дип еш әйтәләр. Кирәк икән, печән дә чабам, сыер да савам. Әйе, хезмәткә яшьли өйрәттеләр мине. Аш-суга да. Монысы өчен әнигә рәхмәтлемен. Ул нәрсәгә генә тотынса да, без гел икәү ясый идек: өчпочмакны да, пилмәнне дә, мантыйны да... «Әбиең мине янына якын китермәде, аның ялгышын кабатларга теләмим... Янымда булганда өйрәнеп кал – кирәк булыр», – дия иде. Гадәттә бит балачага вакытны ала, алай озак була, үзең барысын да тизрәк эшләп куясың кебек. Улым Арслан бүген менә аш-су әзерләү белән бик нык кызыксына, тартыла. Мәктәптән кайтып керүгә: «Тәмле исләр чыккан, нәрсә пешерәсең? Аңа ниләр салдың?» – дип, сорауга күмә. «Аяк астында буталма әле, ашыгам, вакытым юк», – диясе килә дә, шунда ук әнине искә төшерәм. Кызыксынсын, булышсын, өйрәнсен – кирәге чыгар...

Әтинең ул чакта: «Эшләп карамыйсыңмы?» – диюен, «эшлә» дип әйтә дип кабул иттем. Һәм... күземне йомдым да тотындым. Андый гадәт бар миндә... Ремонттан соң банкет залыбыз ишекләрен ачты. 2014 ел иде бу. Өстәлләргә эскәтер җәюем, ваза, чәчәкләр куюым, гадәти савыт-сабаны дүртпочмаклыга алыштыруым Балтач өчен яңалык булды. Әмма иң зур яңалык, әлбәттә, ризык, аның сыйфаты иде. Район зур түгел, бер көнне ризыгың уңмаса, икенче көнне үк: «Алар тәмле пешерми», – дигән сүз бөтенесенә тарала анда.

Балтачтагы уңышым Нурҗиһан апа Галимова исеме белән дә бәйле. Районның иң беренче повар-кондитеры ул, атаклы аш-су остасы Юныс ага Әхмәтҗанов белән кайчандыр бергә эшләгән. Аның миңа эшкә килүе бәхет булды. Бу вакытта аңа инде 65 яшь иде. «Мондый олы апа белән нишләрмен икән?» – дип аптыравым истә. Имеш, эшемә заманча – башка төрле караш белән тотынам... Башлаган мәлдә җиңел булмады: ул 50 елдан артык җәмәгать туклану системасында эшләгән кеше, һәммәсен дә граммлап үлчи, ә миңа күп кирәк, мул кирәк... Татар милли ризыкларын пешерергә дә ул өйрәтте. Беренче көннән үк шушы юнәлешне алдык. Башта – ризыклар белән генә. Ә өч-дүрт елдан соң официантларга жилетлар, калфаклар тектердем. Милли киемнәрдән хезмәт күрсәтү кайда да бөтенләй башкача кабул ителә.

Инде кейтерингка күчү турында. Балтачта без инде Сабантуйларда, семинарларда, районда узган «Созвездие-Йолдызлык», «Нечкәбил» кебек бәйгеләрдә шактый хезмәт күрсәткән идек. Авыл хуҗалыгы техникасы күргәзмәсе узганда кыр шартларында, басуда да эшләдек. Күрше Киров өлкәсенә Сабантуйга – губернатор өчен табын әзерләргә чакырганнары да булды.

Ә аннан пандемия башланды... Башта югалып калдым. Кул астымда эшләүчеләр өчен дә җаваплылык бар, салымнар да түләргә кирәк. Табыннарны клиентларның өйләренә барып әзерли башладык, ярымфабрикатлар, кабымлыклар ясап сатуга күчтек. Кызым Камилла ул вакыт «Приволжанка» олимпия резервы мәктәбендә гимнастика белән шөгыльләнә иде әле. Аның тренеры: «Туган көнемә бәлеш пешерә алмыйсызмы?» – дип сорады. Һич икеләнмичә: «Әйе!» – дип җавап бирдем. Тәвәккәллек бар миндә... Моңарчы гел кабымлыклар әзерлим, камырга якын килгәнем юк иде. Ә борай бәлешем тәмле килеп чыкты! Мин моны Аллаһы Тәгаләнең: «Кулыңнан килә бит», – дип әйтүе дип кабул иттем. Казанда эш ачарга уйлагач, шуңа да курыкмыйча кейтеринг хезмәтенә тотындым.

Кунакларың белән кафе-ресторанга барып утыруга караганда, кейтеринг хезмәтеннән файдалану кайсы ягы белән отышлырак, Альбина?

– Кафе-ресторанда заказны барып утыргач, кулыңа менюны тоткач кына бирәсең. Беренчедән, син теләгән, менюда күзең төшкән бөтен нәрсә булмаска да мөмкин. Икенчедән, күпме акча калдырып чыгасыңны алдан белмисең. Ризыкның ошыймы-юкмы икәнен дә. Ә кейтерингта башкача. Һәммәсе дә син үткәрергә теләгән чара башланганчы күпкә алдан хәл ителә: табынга нинди ризык куеласы, аның күпме күләмдә буласы, ничек бизәләсе, мәҗлеснең нинди бәягә төшәсе... Бюджетны һәрвакыт заказ бирүче билгели: «Менә шуның кадәр акчам, миңа табын корыгыз», – ди ул. Әмма иң мөһиме – ризыкның сыйфаты! Безгә клиентлар һәрвакыт диярлек кемдер аша килә. «Аларныкы тәмле!» – дигәнгә килә. Кейтеринг – әзер ризыкны китереп бирү генә түгел бит ул, без клиентның тормышын җиңеләйтәбез. Аның әллә никадәр вакыты янга кала. Әйтик, бүген туган көнегез һәм сез көне буе эштә ди. Ә кич сезгә кунаклар килергә тиеш! Сез кайтышка ризык кына китермибез, табынны корып ук куябыз. Матур итеп сервировка ясап!

Нindидер ризык белән кешене шаккаттыру авыр хәзер, тик шулай да...

– Чумар ашы белән шаккаттырып була. Күпләр: «Бу нәрсә?» – дип аптырый. Аннан балан морсы бар бездә. Минем үземнең аны Казанда эчкәнем юк. Шул ук борай бәлешем белән дә шаккаттыра аламдыр. Мастер-класс уздырырга Бельгиягә чакырганнар иде,

Балтач – икенче өем кебек:

ул мине аякка бастырды, күтәрде, танытты.

соңгы вакыйгалар аркасында сәфәребез тукталды. Мондый бәлешне пешерергә миңа Нурҗиһан апа өйрәтте, әмма камырын инде хәзер үземчә ясыйм, үз рецептым бар. Узган ел 5 нче разрядлы аш-су остасы исемен алу өчен имтихан биргәндә дә бәлеш пешердем. «Син әле күпкә ирешерсең», – диделәр. Минем өчен зур бәя булды!.. Сүз уңаеннан: Нурҗиһан апа миңа беренче көннән үк: «Син инде 6 нчы разрядлы аш-су остасы», – дигән иде... Нурҗиһан апа белән биш ел эшләдек. Аңардан татар халкының бик күп милли ризыкларын пешерергә өйрәнеп калдым. Әмма өйрәнәселәре, кире кайтарасылары тагын да күп. Кул астымда һәрвакыт Юныс Әхмәтҗанов китаплары. Миндә аның 90 нчы елларда чыкканы да бар, 1969 елда басылган яшел тышлысы да. 1959 елгысын гына таба алганым юк әле. Бертуктамый актарам, өйрәнәм аларны. Юныс ага нигез салган Татар ашлары йортын аякка бастырасым килә. Бу – иң зур хыялым. Бинасын сатып алырга мөмкинлегем әлегә юк, әмма аны эшләтеп җибәрергә креативлыгым җитәсенә ышанам. Моның өчен бу эшне яратырга, аның эчендә кайнарга кирәк. Ә мин бер эштән дә оялмыйм: кирәк икән идән дә юам, савыт-саба да.



Хыял дигәннән... Гиннесс рекордлар китабына кертерлек зур бәлеш саласым килә! Балтач җитәкчеләренә: «Булышсагыз, эшлим», – дип әйткән дә идем инде. Бәлки яшьләр көненә пешерербез. Вакытлыча салынган зур мичне, бәлешне трактор белән шул мичкә тыкканны күз алдыма китерәм...

Һәр заказ саен меню үзгәреп торадыр, ә үзгәрми торган позицияләр бармы?

– Бәлеш барысында да кабатлана! Аның ассортименты аз түгел бит. Күбрәк итле-бәрәңгеле бәлеш сорыйлар, әлбәттә. Борайныкын бөтенләй белмәүчеләр бар. Бигрәк тә Казанда. Аның нинди ярма икәнен аңлаткач кына: «Әйдә, пешереп карагыз соң», – диләр. Борай бәлешенең тәмле булу-булмавы ярмасының ниндилегенә бик нык бәйле. Мин үзем аны инде шактый еллар бер җирдән генә алам.

Без бәлешкә күбрәк үрдәк ите кушабыз. Каз итен бөтен кеше дә яратып бетерми, бигрәк тә районда. Казның эч-башы белән дә бәлеш пешерәбез. Бөтендөнья татар конгрессы уздырган I Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестиваль-бәйгесендә икенче урынны алдым узган ел. Ул видеода каз бәлешен ничек пешерүне генә түгел, каз йолку, чишмәдә юу тәртибен дә күрсәттек.

Кайсыдыр ягы белән бик истә калган заказлар бармы?

– Алар барысы да истә! Кичә генә булган кебек... Казанда үткәргән беренче зур туй, мәсәлән. Алып баручылар өчен мин беркем түгел идем бит: ниндидер районнан килгән, ишетмәгән, белмәгән берәү... Табынны күргәч фикерләре бик тиз үзгәрде аларның. Кунаклар да шаккатты. Сөйләшергә, аралашырга яраткач, ачык булгач, артистлар арасында дусларым-танышларым байтак минем. Балтачта бездә кемнәр генә булмады?! «Нигә Казанда үз эшеңне ачмыйсың?» – дип еш әйтәләр иде алар. Елмаеп кына куя идем. «Балтач булганда Казан миңа нәрсәгә?» – дия идем. Казанда яшәсәм дә, моңарчы ярты гомерем Балтачта узды: атнаның ике-өч көне өйдә, өч-дүрт көне анда иде. «Беркайчан да» дигән сүзне әйтергә ярамый икән...

Казанда кейтеринг хезмәте ачуга, концертлары көнне артистларга хезмәт күрсәтә башладык: Мирзаяновларга, Фазлыевларга, Әнвәр Нургалиевка, Салават Миңнехановка, «Болгар» радиосына, Сөмбел Билаловага... Илсөя Бәдретдинова беренче тапкыр чакырганда: «Кунакларны тәнәфестә һәм концерттан соң ашатырга кирәк булыр», – дигән иде. Ә чыгышы буласы көнне: «Сәгать дүрткә үк килә алмыйсызмы?» – дип шалтыратты. Ике сәгатькә иртәрәк! «Киләм!» – дип, аны тынычландырдым, ә үземнең эчтә ут. Өлгерербезме?! Сәгатьнең һәр минуты алдан ук бүленеп куелган бит. Өстәвенә, читтән дә бер бәлешкә заказым бар иде, димәк, өчне ясарга кирәк... Ярты сәгатькә иртәрәк тә барып бастык әле. Миңа ышанырга була икәнен шулай расладым. Кайсы җырчының нәрсә ятратканына кадәр беләбез инде хәзер. Әйтик, Илсөяр борай бәлеше, өйдә тозлаган кыяр-помидор, кәбестәне, ат итен ярата. «Безгә нәрсә кирәген син беләсең инде», – дип, күп клиентларым әйтә миңа... Җырчыларга хезмәт күрсәтүнең безнең өчен тагын бер рәхәт ягы бар: ул көнне концерт та карап кайтабыз. Ял бит безгә сирәк эләгә, тәүлегенә ике-өч сәгать кенә йоклаган чаклар еш була.

Кафе-рестораннарның бер өстенлеге – ризык плитәдән туп-туры өстәлгә чыга. Ә сезгә – тутырасы, илтәсе, бушатасы, тезәсе... Салкын ризыкның тәме башка инде аның.

– Җәмәгать туклану системасында инде җиде ел эшлим, Балтачта хәзер дә: «Иң кайнар ризык – сездә», – диләр. Яңа пешкән һәм кайнар булсын – бу минем ашау-эчүгә төп таләбем. Кызлар: «Без Арарат тавы принцибы

буенча эшлибез», – дип көләләр әле тагын. Миңа, әйткәнемчә, күп һәм мул булсын. Муллыкка омтылуым әнидән килә: ул кунак чакырганда безнең өстәлләр ризыктан сыгылып тора иде. Татар халкы, гомумән, табын бай булганын ярата. Заказ биргәндә: «Сез күбрәк беләсез, өстәл буш күренмәсме?» – дип еш сорыйлар. Сыйларга да, күчтәнәчкә биреп җибәрерлек итеп тә әзерләргә кирәк безнекеләргә. Барысы да бюджетка бәйле, билгеле. Әгәр ул азрак икән, туклыклырак ризыклар сайларга тырышабыз: бутерброд, брускет, камыр ризыклары...

Ә ризык суынмасын өчен нишлибезме? Әгәр заказ, әйтик, иртәнге сигезгә икән, без аны кичтән түгел, иртәнге дүрттән килеп эшлибез. Клиентлар күп вакыт өлгермәбез дип курка, борчылалар. Мин аларга аңлатырга, тынычландырырга тырышам. Ризыкны кайнар килеш саклаучы махсус җиһазлар да бар, әлбәттә. Анысы – киләчәктә инде. Әлегә термосумкаларны файдаланабыз. Узган шимбәдә Сабага заказыбыз бар иде менә. Юлы гына ике сәгать. «Мантыйларыгыз әле суынмаган да иде», – диделәр.

Үз эшең өчен үзең януың – бер хәл. Уңышка ирешү өчен кул астындагы хезмәткәрләрнең дә «әйдә, ярар әле» дип кенә эшләмәве кирәк бит.

– Әйе, үзең кебек эшләүче кешеләрне эзләп табу – иң авыры. Әйтик, Балтачтагы Нурҗиһан апа кебекләрне. 70 яше тулганчы эшләде дә, ул инде ялга китте хәзер. Мин болай йомшак булсам да, эшкә карата бик таләпчәнмен – кызлар аны белә. «Аз, матур түгел!» – дип кабатларга ятратканымны да. Заказга әзерләнгән тәлинкәләр бар яктан да идеаль булырга тиешлеген дә. Әмма нидер килеп чыкмаса, тавыш күтәрмәгәнемне, йөзгә бәреп әйтмәгәнемне дә... Юлымда төрле кешеләр очрады, әмма янымда сиңа иң кирәклеләре генә кала икән аның.

Казанда эш башларга ниятләгәч: «Ә Балтачларны ничек калдырып китәрмен?» – дип бик борчылдым. Гаилә белән ялга барганда да: «Сезнең хәлләр ничек анда?» – дип шалтыратып алҗытып бетерә идем үзләрен. Ә хәзер тынычландым. Миңа ничек кирәк – шулай эшләгәннәрен беләм. Казандагы кызларыма да ышанам. Икесе дә бәлеш пешерә белә. Кул астымда барлыгы ун кеше эшли бүген. «Иртәнге сәгать дүрттә әзерли башларга тиешбез», – дисәм дә, «ярар, киләбез» генә диләр. Мин идея бирә, өйрәтә алам, әмма эшне без бергәләп кенә башкарып чыга алабыз.

Балтачтагы уң кулым – Регина. Өч ел элек официант булып килгән иде, хәзер инде кухня аның өстендә дисәм дә була. Ә Алсу – Казандагы уң кулым. Безнең ничек табышуыбыз үзе бер тарих. Мин черлидинг белән шөгыльләнәм. Аны бию дип тә, әмма күбрәк спортның бер юнәлеше дип әйтәләр: биюне, гимнастиканы һәм акробатик трюкларны берләштерә ул. Без, мәсәлән, бер-беребезне күтәреп пирамидалар ясыйбыз. Татарстанда ата-аналардан торган бердәнбер команда ул. Оешканыбызга өч кенә ел, әмма инде Сочида, Анапада узган ярышларда катнашып, икенче-өченче урыннар алып кайтырга өлгердек. Минем балалар бу спорт белән шөгыльләнми, бер дус кызым чакыргач барып эләктем ул командага. Ә Алсуның киресенчә – үзе түгел, баласы йөри. Ярышка барганда поездда урыннарыбыз янәшә туры килде шулай. Сөйләшеп киттек... Безнең шунда ук уртак тел табуыбыз, бер-беребезне хәзер сүзсез дә аңлавыбыз гаҗәп түгел – ул инде моңарчы сигез ел бер кафеда эшләгән. Алсу белән икәү генә дә илле кешене ашата алабыз. Күрсәтүгә, теләсә кайсы эшне нәкъ синең кебек башкаручы белән бик җиңел. Ә Алсу шундый. Казанда кейтеринг хезмәте ачарга да мине ул этәрде, ул рухландырды. Кыз йолдызлыгы астында туган булуыбыз да якынайтты бугай. Икебез дә кызу – аш-су тирәсендә башкача булмый да. Мин үземне кайчак сигезаяк кебек хис итәм: берьюлы әллә ничә эш эшлим – камыр куям, бәрәңге чистартам, кабымлыклар кисәм; бер телефоннан сөйләшәм, шул ук вакытта икенчесеннән кемгәдер җавап бирәм... Безнең эш сезон белән бәйле: җәен туй-никах чорында, Сабантуйлар гөрләгәндә, Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан көнне төнгә ялгап эшлибез. Безнең эш гел вакыт белән бәйле: билгеләнгән сәгатькә өлгерергә кирәк. Кемнеңдер гомер бәйрәме – банкеты, фуршеты ничек узуы шушыннан да тора. Зур җаваплылык бу! Эшебезне җиңел димәс идем: без бит һәр кичне яңа җирдә яңа ресторан ачабыз. Башкача ничек чагыштырасың?! Зур мәҗлесләр оештырганда ярты машина савыт-саба гына төяп барабыз. Сүз уңаеннан, кейтерингның бер кимчелеге – гел күчереп йөрткәнгә савыт-саба еш ватыла.

«Кәефең начар икән, эшкә килеп тормасаң да була», – дигән Юныс Әхмәтҗанов. Бу сүзне кызларга гел кабатлыйм. Әйе, кәефеңнең нindiлеге нык тәэсир итә ризыкка – энергетикаңны шунда ук сизә ул. «Яратып эшләнгән, ярату белән әзерләнгән» дигән гыйбарә юктан гына килеп чыкмаган.

Сез гел башкаларга бәйрәм ясау белән мәшгуль, ә үзегез өчен бәйрәм нәрсә ул?

– Гел аш-су тирәсендә катнашкач, пешекчеләр юан булырга тиеш дип уйлый күпләр. Утырып ашау түгел, бер чынаяк чәй эчмәгән көннәр дә була. 150–200 кеше ашатасы булганда чәй кайгысымыни?!

Ял иткән көннәрдә гаилә белән булырга тырышам – минем өчен бәйрәм шулдыр. Әти-әниемә рәхмәт – балаларны карауны үз өсләренә алдылар. Арсланыбыз йөзү белән шөгыльләнә – әти аны көн саен тренировкага йөртә. Моңа үзебез өлгермәс идек.

Кичә менә ял иттем, ике-өч көнгә җитәрлек ризык пешереп куйдым. Бу да бәйрәм! «Көн саен болай әзерләсәм, 20 килограммга артканыңны сизми дә калачаксың», – дим иремә. Айрат – минем иң төп таянычым. Күтәрү-төшерү эшләре дә байтак бит бездә – ирем булышмый кем булышсын?!

Хоббием бар – чигүле сөлгеләр җыям. Гомумән, борынгы әйберләр яратам. Савыт-саба, кашык-чәнечке... Кайнанам Мамадышта яши, ул да миңа шактый экспонатлар тапты. Һәр яңа табыш – минем өчен бәйрәм! «Милли ашлар» проекты белән күргәзмәләрдә еш катнашам – чигүле сөлгеләр, эскәтерләр гел кирәк.

Күптән түгел франшиза сату буенча Бөтенроссия күргәзмәсендә катнаштым. Биш-алты кеше бездән франшиза сатып алырга теләк белдерде. Димәк, үсәргә мөмкинлекләр бар. Күңел өчен бу да бәйрәм! Зур бәйрәм!

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Әниләр авырмый бит алар, аларга авырырга ярамый да әле. Балаларны мөстәкыйль, әти-әнигә карата булган ихтыяҗдан азат итеп тәрбияләргә тырышсак та, без, үзебезгә ничә яшь булуына да карамастан, әниләрнең ятып торуына да, кирәк чакта ярдәм итә алмауларына да ияләшмәгән. Алай гына да түгел, шулай килеп чыккан очракта аларга ачуыбыз чыга, кәефебез кырыла.



Ләйсән
РӘХМӘТУЛЛИНА



Барлык әти-әниләр дә балаларының мөстәкыйль, яхшы кеше булып үсүләрен тели. Дөрес, бу юлда абыну-егылулар да еш булуын һәм сабырлык кирәген онытырга ярамый. Мин дә балаларымны үз мәнфәгатьләрен үзләре кайгыртырлык итеп тәрбияләргә телим, эшкә дә өйрәтмәкче булам. Яңа чирләрнең шаукымы, читтән торып эшләү белән, балаларны гел күз уңында тоту мөмкинлеген дә бирде. Һәр адымнары күзәтү астында – болай булгач, һичшиксез, өйрәтәм инде дип тә уйлыйм үзем.

Дөньядан артта калмыйча без дә мәктәпкә барабыз, берничә түгәрәгенә дә чабабыз. Иртән әтисе эшкә киткәндә улыбыз дзюдога кереп кала, ә мин ике сәгатьтән соң барып алам. Тренировкаларыннан соңрак чыккан көннәрдә әле шул арада кибетенә кереп ипиен, маен да алып өлгерәм.

Ул пәнҗешәмбедә дә шулай булды. Кибеттән ашыгып чыгып барганда, кар астында яткан боз гына җимерде бар планнарны. Баскыч рәшәткәсенә тоты-

МӨСТӘКЫЙЛЬ ТОРМЫШ



Фото: Анна Арахамия

ныр кала алдым алуын да, тик аягымны тоймый идем инде. Эсселе-суыклы булып китте, буранлап торуына да карамастан, куртка изүләремне үк чиштем, баштагы шарфым шуып төшкән килеш, якындагы карлы эскәмиягә барып аудым. Аякны кыймылдатып та булмый, авырта. Шунда бер ханым килеп:

– Ярдәм кирәкме? Булмаса, «ашыгыч ярдәм» машинасын чакыртыйк, – дип, үзенең егылуы турында да сөйләп алды, ахры. Тик берсе дә истә калмаган, чөнки шул секундта үземнең башымда да төрле уй кайный иде: «Кая дип чаптың инде син?! Синең балаңны кем алып кайта хәзер?» Нишләргә белмичә берничә минут утырганнан соң, балама шалтыратып, светофорның яшел утына гына юлны аркылы чыгасын аңлаттым. Менә сиңа мөстәкыйль тормыш, аның бит әле бер генә тапкыр да үзенең генә юл аркылы чыкканы юк.

– Улым, тренировкаң беттеме? Әйдә, киен дә чык. Мин монда – каршы якта, кибет парковкасында. Светофорга кадәр кил, аннары яшел ут янгач кына, бөтен машиналар туктап беткәч кенә юлның теге ягына чык, аңладыңмы?

– Әйе, әйе, аңладым, ярар. Хәзер чыгам, – диде дә телефонын сүндереп тә куйды. Бераз алгарак үтсәм, күренәсе икән дә, дип, эскәмиядән торып бастым. Авыртуга чыдап булмый, күзләр яшьләнә, шулай да әкрен генә алга таба берничә адым ясый алдым.

Бу юл чаты зур түгел үзе. Кеше дә моннан бик еш йөрми, шуңа күрә кайбер машина йөртүчеләр светофорның сары уты, кызыл уты, димиләр, туктап тормыйча чабып үтүчеләрне дә күргәләгәнем булды. Шуларны искә төшереп, тагын балам номерын җыйдым:

– Син кайдан әле?

– Менә светофорга җитәм, әни, – ди.

Барысын да яңабаштан кабатлап, юлны ничек чыгарга кирәклеге турында лекция укып алдым.

– Беләм инде мин, беләм, – ди ул үзе.

PRESSA

Баланы мөстәкыйль тормышка әзерләү әти-әнидән сабырлык һәм эмоциональ ярдәм таләп итә.

– Юлны чыккач, сулга борылып азрак үт тә, мин шунда, күрерсең. Телефоныңны кулыңда тот, аңа карама, – дип тә куйдым. Хәзер һәр ике баланың берсе үзе атлый, ә үзенең күзе – телефонда.

Юлны ничекләр генә аркылы чыгар инде бу сабый, дип, 8 яшьлек балам өчен ут йотып торган арада аяк кайгысы да онытыла башлаган иде инде. Киләә, ниһаять. Үзе шат, канәгать.

– Мин үзем чыктым, әни, күрдеңме? Әйдә, икенче юлы да шулай гына эшлик әле, мин үзем дә бара беләм инде. Әйдә әле, әни, ә? – дип сайрый зур кеше.

– Ярар, карарбыз. Булдырдың! Үзең чыктың, улым, – дип күңелен күтәреп, уңышын билгеләп тә куйдым. Чатан аяк кыйссасын бәян иткәч, улым, үзенең авырлыгы да хәйран булган сумкасына да карамыйча, кулымдагы пакетны да үзе күтәрде. Житәкләшеп әкрен генә машинага таба киттек. Әле ярый машина автоматта, әле ярый сул аяк имгәнгән, дип, әлеге хәлләрнең бер генә булса да уңай ягын табарга тырышам.

– Авыртамы, әни? Бик авыртамы? Кайсы җире, моннан – астанмы? – дип төпчендe улым сызлануымны күреп.

– Түзәрлек, әйдә кайтыйк әле тизрәк, – дим.

Гадәттә, машина ишеген үзем ачып-ябып балаларны төяп китә идем. Бүген үземне ишек ачып утырттылар, сумкамны да балам үзе алып куйды. Рәтен белә икән бит, дим эчемнән генә. Кайтып өй каршына туктагач та, улым ярдәм итеп торды. Ишекләрне ачты, япты, сумкаларны кертеп куйды, аннары кибеттән кайткан пакетны бушатып бар нәрсәне урынына урнаштырды. Төшке аш әзерләү бурычы да үз өстендә булды. Ризык әзерләү эшенә булган кызыксынуының да кирәге чыкты тагын: микродулкынлы мичтә үзе теләгән кайнар бутербродлар ясап, мине дә сыйлады. Ипи валчыкларына һәм уылган сырга баткан аш өстәлен җыештыру гына миңа калды. Баланың күңелен кырып, моның ише вак нәрсәләрне билгеләп торуның кирәген тапмадым.

Көн дә башкара торган әлеге гади хәрәкәтләр турында күбебезнең уйлап караганы да юктыр. Табынга бер куй, бер ал, сөрт, җыештыр, күлмәген алып бир, керләр арасыннан оекбашын тап, шешәсенә су тутыр, әйберен тотып торыш, кирәк урында «төртеп» җибәр һәм башкасы... Көне буена күпме җыела икән бит ул. Бүген исә, дирижер сыман, боларның барысы белән дә идарә итеп кенә утырдым. Ул минутларда үземне сафтан чыккан солдаттан да ким хис итми идем.

Әниләр авырмый бит алар. Аларга авырырга ярамый да әле. Шушы бер-бер артлы тезелгән көндәлек ритмны тудырган хәрәкәтләрнең берсе генә өзелсә дә, өйдә тәртип югала, хаос барлыкка килә.

Кич белән өйдәгеләр җыелганчы, аякның сынмаганлыгын раслап, лангет киеп, кайтып диванга яткан идем инде. Ул кайтканда гел ашарга әзерләп, аш бүлмәсеннән чыгып каршы ала торган әнисен горизонталь юнәлештә күрү кечкенә балага шок ясады.

– Авыртамы, әни? Кайсы җиреннән? Син хәзер ятып кына торасыңмы? Моны салырга ярыймы? Син кайчан йөри башлыйсың инде? Ә безне кем ашата? – дип сораулар яудырды.

Алар кайтканчы ук инде ипи кисеп, табынны әзме-күпме әзерләп куйган идем. Шулай да күбесен үзләренә эшләргә туры килде: ашны алып кереп җылытырга куйдылар, шкафтан чынаякларны алып тезделәр дә, чәй кайнады, утырып ашадык. Шул арада әле тегесе, әле монысы онытылган дип, суыткычка таба да берничә тапкыр сәяхәт кылынды. Соңыннан пычрак табак-савыт раковинага җыелды, юарга теләк белдерүче дә, шуңа әзер кеше дә табылмады.

Диванда аяк сузып утырып торган арада әле берсенә, әле икенчесенә нидер кирәк була башлады. Кечкенәсе арлы-бирле чабып – рюкзагын, икенче көнне балалар бакчасына киясе кара галстугын да (бакчага күлмәк белән галстуктан бәйрәмчә киенеп йөри) таба алмый интекте. Житмәсә, нәкъ менә бүген балалар бакчасыннан ук кайнатма белән коймак ашыйсы килеп кайткан булган икән. Олысы дәресен күрсәтә, тегеләй дөресме, болаймы, дип, диван белән өстәл арасында чабулый. Бер чатан аяк аркасында дөньяның асты өскә килде, рольләр алмашынды, гаиләдә канәгать булмаган кешеләр артты, коймак булмаганга кәефләр кырылды. Алар – сорап, мин җавап биреп талчыктым... Алар, яннарына килеп, гозерләрен үти алмавыма ачуланды, үзем исә болар бит берни дә эшли белми дип көрсендем.

Без әниләрнең ятып торуына да, кирәк чакта ярдәм итә алмауларына да ияләшмәгән. Алай гына да түгел, шулай килеп чыккан очракта аларга ачуыбыз чыга, кәефебез дә кырыла әле.

Танышым Ландыш та үзе белән булган хәлләрне сөйләде. Аның әнисе Равия апа әле Ландыш студент чакта ук җәй көне аягын сындырган булган.

– Әле ярый җәй көне иде, имтиханнарны тапшырып бетереп, әни янында тора алдык, – дип сүз башлады ул. – Имтихан тапшырган көнне үк кичке автобус белән өйгә кайтсам, гипска чорналган аягын күтәреп әни утыра. Әллә нишләп киттем шул чакларда. Әллә ни куркыныч әйбер дә булмаган инде югыйсә, ә күңел йомшарды, әни бик тә кызганыч иде. Аның шул яшенә җитеп, шулхәтле утырып торганы булмагандыр да әле.

Авыл, җәй, эшнең очы-кырые күренми. Шушы йортта туып-үсеп, бөтен эшне эшләп үскән кеше булсам да, җиңелләрдән булмады ул. Бакчага бәрәңге чүбен чабарга дип чыгып китәм дә, ярты көн үткәч кенә керәлә. Әни шул арада мине кызганып, ашарга булса да пешерим, дип, сынган аягын урындыкка куеп аш бүлмәсендә булыша иде. Үзенең эшли алмавына үзе уфтана, көрсенә, шулай килеп чыгуына ачуы

да килә иде. Элеккеге кебек чабып йөри алмавына үз-үзен битәрли иде ул. Кәефе юк, нервлары чыдамый, берочтан миңа да эләгеп ала. Югыйсә эшен эшлим, зарланмыйм, эндәшмим, тик әни генә һаман да кәефсез була торган иде.

Әнигә дә кыен булгандыр инде. Бер ияләшмәгән кешегә тик кенә утырып тору җиңел түгелдер ул. Йөрәге түзмичә, култык таякларына таянып бакчага да чыккалаганы булды аның. Әнинең шулай иза чигүен күрү мине дә төшенкелеккә салды, шул минутларда, нишләптер, бар дөньясына ачуым сагыз күбегедәй кабарып шартлый да, үземне бөтенләй бөтереп ала торган иде. Әнигә үпкәләмим дә, әмма канәгать тә түгелмен. Ә ул йөри алмавына ачуы килеп, нишләргә, безгә ничек ярдәм итәргә белми аптырый иде. Эшләнгән эшнең аныңча булмавына да кәефе кырыла иде. Бу вакытларда өйдәге тискәре энергия берничә лампочканы электр белән тәэмин итәр иде, мөгаен. Әни кешене кәефсез күрү мине дә бәхетсез итә иде.

Шул гипстан котылу көнен Яңа ел төненнән дә ныграк көттек. Минем өчен әнинең сау-сәламәт килеш йөреп торуыннан да кадерлерәк әйбер булмагандыр. Менә шул көнне инде мин өйнең яме дә, ашның тәме һәм минем яхшы кәефнең дә әнигә бәйле булуын аңладым.



Резеда АКБИРОВА, «Сердәш 129» хезмәтенең медицина психологы

Мондый хәлдә калмас өчен баланы аның яшь үзенчәлекләренә туры килерлек дәрәҗәдә мөстәкыйльлеккә дә өйрәтергә кирәк. Әнисе авырып киткән очракта, әлбәттә, балага карата булган игътибар кимиячәк. Бу хакта балага хәбәр итмиләр икән, ул аның өчен стресс була ала. Дөреслекне белмәгәндә, килеп туган сорауларга җавапны бала үзе уйлап таба башлый. Кайвакытларда бала үзен гаепле хис итә башларга да мөмкин, шуңа күрә әни кеше йә үзе, әтисе яисә башка кеше балага хәзерге вакытта әнисенең авырып торуы турында сөйләп аңлатса әйбәтрәк.

Аннары мондый очракларда балансны саклау да мөһим, ягъни балага бала булып калырга мөмкинлек бирергә һәм аңа артык йөкләмәскә тырышырга да кирәк. Мондый чакларда әбибабаларны, туганнарны җәлеп итәргә дә була.

Без балага мөстәкыйльлекне кинәт кенә түгел, ә гомеренең беренче көннәреннән үк бирә башлыйбыз. Тумыштан аңа үзенең башын борырга, сөт имәр өчен күкрәкне табарга мөмкинлек, ирек бирәбез. Айлар, еллар үткән саен, күбрәкне рөхсәт итә башлыйбыз. Инде 2–2,5 яшендә сәламәт бала күп нәрсәләрне үзе эшли ала: йөри, йөгерә, сораулар бирә, үзенең теләк һәм ихтыяҗларын белдерә.

Баланы мөстәкыйль тормышка әзерләү әти-әнидән сабырлык һәм эмоциональ ярдәм таләп итә. Киләсе киңәшләр баланы мөстәкыйль тормышка өйрәтергә булышачак.

- Бала өчен ул үзе эшләргә өйрәнгән әйберләрне аның өчен эшләргә ашыкмагыз. Мәсәлән, бала 2 яшьтә үзе кашык тотып ашый, 3 яшьтә – киенә, уенчыкларын җыя белә. Әмма күп әти-әниләр өчен баланы үзләре ашату, киендерү тизрәк тә, җиңелрәк тә. Тик баланың үзенә дә мөмкинлек бирергә кирәк. Кулларыгыз бала урынына нәрсәдер эшләргә үрелә икән, үзегезгә сорау бирегез: ни өчен ул аны үзе эшләми? Баланың физик мөмкинлекләре чикле булган очрак – икенче мәсьәлә. Ул вакытта әти-әни эшли. Баланың боларны эшләргә теләмәве, игътибар таләп итүе, көйсезләнүе – башка. Бу очракта бала белән сөйләшеп, аны тынычландырырга, киңәш бирергә кирәк, тик аның өчен артык эшләмәскә. Әгәр белми икән, өйрәтегез. Моны эшләп күрсәтергә, бала белән бергә эшләргә була яисә бала әнисе әйтеп торуы буенча үзе яисә тулаем мөстәкыйль рәвештә үзе генә эшли.
- Балага ялгышырга рөхсәт итегез. Тәнкыйтьне әзрәк басыгыз. Әлбәттә, 3 яшьлек бала идән юа алмас, ул аны юешләтер генә. Бу очракта әти-әни баланы мактарга, ярдәм иткәне өчен рәхмәт әйтергә һәм ул үзе күрмәгәндә сиздерми генә җыештырып бетерергә була. Һәрбер хата – тәҗрибә. Тәҗрибә генә кешене мөстәкыйль, бәйсез итә ала.
- Балага сайлау иреге бирегез (теләгән киемен кияргә, үзе сайлаган секциягә йөрергә, ялын ничек үткәрергә, иртәнге ашка нәрсә ашарга һәм башкалар). Балагызга ышаныгыз, янында булыгыз, кирәк чакта булышыгыз. Боларны башкару бала өчен эшләп бирүгә караганда, авыррак бирелячәк. Бераздан әти-әнигә җиңел булачак, ә балага – файдага гына.
- «Ярамый», «юк» сүзләрен кулланыр алдыннан уйлагыз. Кайбер тыюлар, чынлап та, кирәкле: шулай итеп без баланың куркынычсызлыгын кайгыртабыз. Күп очракта бу сүзләрне әйтеп, үзебезгә уңайлы булсын дип тә тырышабыз. Балага гөлгә су сибәргә биргәнче, аны рөхсәт итмәү җиңелрәк. Ул гөлне аудара, җирен чәчә, суын түгә. Бала ялгышлар аша гына өйрәнә. «Ярамый» сүзен куркыныч эшләргә карата гына кулланырга тырышыгыз. Мәсәлән, кулларны юмыйча ашау, тиешсез җирдә юлны чыгу һәм башкалар.
- Баланы кызыксындыра белергә дә кирәк. Аның өчен һәрбер процесс – уен. Фантазиягезне эшкә җигегез.
- Әти-әниләр идеаль була алмый. Безнең бурыч – аларны безгә карата булган ихтыяҗдан азат итеп тәрбияләү.

«ХӘЗЕРГЕ ҮСМЕРЛӘР ДӘ БЕЗНЕҢ КЕБЕК РОМАНТИК»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт яныңда сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире РАДИК САБИРОВ һәм аның кызы ИЛҮЗӘ.



Илүзә, син романтикмы?

– Юк! Романтика баналь бит ул.

Синең өчен романтика нәрсә ул?

– Бер-береңә карата хисле мөнәсәбәтләр дип уйлыйм. Янымда кеше булмаганда гына хисләргә бирелә алам. Хисләр миңа кисәк кенә килә. Шул вакыт якыннарыма: «Мин сине яратам», – дим. Бу сүзне күбрәк әтиемә әйтәмдер. Нигә аңа күбрәк әйтәм – белмим. Бәлки, ул бик йомык һәм кырысрак булгангадыр. Ул компьютерда эшләп утыра. Мин аңа «яратам», дим. Ул «ыхы», ди йә «мин дә сине яратам», ди. Шулай дип кенә әйтә ул, әмма аңа бу минутта бик рәхәт булганын беләм инде. Сер генә бирми.

Әтиең сине көндәлекләр яза, ди.

– Әйе шул. 9 яшьтән башлап алып барам. Ул вакытта икетуган апам минем өчен үрнәк иде. Аңа охшарга тырышып яза башлаганмындыр. Хәзер көндәлекләрне киләчәктә укып, үткәннәрне искә төшерер өчен язам. Көндәлегем өстәлемдә ята. Әмма аны беркем дә алып укымый, чөнки беләләр: ул – минем шәхси әйберем. Бездә шәхси чикләрне хөрмәт итәләр һәм саклыйлар.

Көндәлекләреңдә әти-әниең белән сүзгә килүләрне дә язасыңмы?

– Глобаль аңлашылмаучылык булганы юк безнең. Үпкәләгән кыяфәт чыгарсам да, үпкәләмим. Әти белән холыкларыбыз бик охшаган: үз фикеребездән кайтмыйбыз. Әнием – психолог. Аның белән конфликт бөтенләй юк. «Кызым, әйдә, үзара ышанычларны югалтмаска килешәбез», – ди ул һәрвакыт. Әти-әни белән сүзгә килсәм, үземне бик начар хис итәм, чөнки гаепле икәнемне аңлыйм. Кайчагында ашыгып әйтеп ташлыйм шул.

Әтиеңнән курkасыңмы?

– Начар билге алган өчен өенә кайтырга куркучылар бар. Ә мин начар билге алсам, әти-әнием түгел, үземне үзем орышам. Аларның мине әрләгәннәре дә юк бугай. Хәтерләмим инде. Бәлки, ачулануларын ачулану дип кабул итмимдер. Ә этидән куркырга кирәкми. Кечкенә бер ялгышың өчен дә әтиләр ачуланалар, җәза бирәләр икән, бу нормаль хәл түгел. Ул вакытта аңа мөрәҗәгать итмисең инде, башка кешеләргә сөйли, ярдәм сорый башлыйсың. Олылар тарафыннан басым була икән, бала депрессиягә китәргә һәм ерагаерга мөмкин. Гомумән, нормаль әти бала белән коннектны (*мөнәсәбәтләрне – Ч. Г.*) көйли белергә тиеш.

Кофе алырга тәкъдим иткәч, «Юк, кирәкми ул бит сезнең акчагыз», – дидең. Акчага мөнәсәбәтең турында сөйләшик әле.

– Кызык бер хәл искә төште хәзер. Бәләкәй чагымда әти-әни акчасын әрәм-шәрәм итмәсен өчен, бер тапкыр кибеттән чупа-чупс урладым. Ул вакытта ук аларның акчаны зур көч куеп эшләгәннәрен аңлый идем. Хәзер инде үзем акча эшли ала торган яшьтә. (*Илүзә 9 нчы сыйныфта укый. – Ч. Г.*) Шуның өчен бик шатланам. «Шаян ТВ»да алып баручы булып эшлим, «Изумрудный город» эстрада биюе студиясендә биим. Төрле концертларда катнашабыз. Студиядә кечкенә балаларны да биергә өйрәтәм әле. Акчаны үземә түгел, күбрәк якыннарыма тотам. Үзем эшләп алган акчама аларга бүләкләр алганда шундый горурланам. Лагерьга юллама алганда, бию белән бәйгеләргә барганда, «үзем түлим», дим. Минем өчен акча тотканда никтер уңайсызланам.

Егетең кафега чакырды да синең өчен түләргә теләде ди...

– Анысы ярар... Юк. Үзем түлим диячәкмен.

Нинди егет синең өчен идеаль?

– Сине яраткан егеттер, мөгаен. Чибәр булсын инде ул. Аңа карагач, «нинди матур егет сайлагансың», дисеннәр. Кешеләрнең тышкы кыяфәтенә артык игътибар бирмә, диләр. Ничек игътибар итмисең инде?! Егетләр дә үзләрен карап йөрергә тиешләр. Китап укысын ул! Укыган китапларым турында сөйләшергә фикердәш кирәк булачак. Менә шундый егет идеаль инде.

Әтиең белән горурланасыңмы?

– (*Күзләре* яна башлый.) Әлбәттә, горурланам. Бик нык! Ул бит барысын да үзе булдырган. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган, университетта укыган, аннан шунда укыткан. Безнең мәктәпнең директоры – әтиемнең укучысы. Ул бик гыйлемле минем! Хәзер ул баш редактор. «Әтиемнең инстаграмы юк», «Минем әтинеке бар, әмма ул юзер», диючеләр күп. Ә минем әти – кәттә блогер. Бик күп социаль челтәрләрне алып бара, аның подписчиклары меңәрләгән, видеолары күп карау җыя. Дусларым да аны карап бара һәм соклана. Әше күп булса да, безне дә кайгыртырга җитешә. Ул бик көчле холыклы. Һаман укый, һаман үсештә.

Радик, син романтик үсмер идеңме?

– Романтика барыбызда да булгандыр инде ул. «Элен и ребята» киносы килеп кергән чор бит ул. Аларны күреп, бүлмәгә постерлар ябыштыра башладык. «Ласковый май», София Ротаруны тыңлый-быз. Район үзәгенә барган саен кассеталар алып кайтабыз. Качырып кына шигырьләр яза башла-дым. Беренче мәхәббәт белән хатлар языштык. Ул шәһәр кызы иде. Май аенда сирень чәчәкләре өзеп, аңа бүләк итүләр – барысы да үсмер чактагы матур бер хатирә.

Миңа калса хәзерге үсмерләрдә романтика юк. Ә син ничек уйлыйсың?

– Бар ул аларда, Чулпан. Үземнең кызларда сизәм. Зур кызым холкы белән миңа бик охшаган. Көндәлекләр алып бара. Кечкенәсенең дә хәзер үз күңел дәфтәрләре бар. Хәтерләсәң, безнең вакытта да бар иде андый дәфтәрләр...

Сокланып та куйдым сиңа. Күп әтиләр кызларының тормышыннан хәбәрдар түгел. Ә син көндәлек алып баруларына кадәр беләсең.

– Күренгәли бит инде ул. Ике кыз бит әле алар. Кечкенәсе вакыт-вакыт апасын сатыштыра да. Менә Илүзәнең мин белмәгән яңа бер аккаунты барлыгын да әйтте әле.

Күп үсмерләр гадәте бу. Нигә әти-әнидән яшерәләр икән?

– Яшүсмерлек романтикасыдыр инде. Үзебез күрсәттекме әллә әти-әниләргә?! Ата-анадан аерылу дип санамыйм, мөстәкыйльлеккә бер адым ул. Моңа һич тә үпкәләргә кирәкми. Һәр кешенең үз дөньясы булырга тиеш. Билгеле, вакыт-вакыт куркынычсызлык ягын да уйлап куясың. Хәзер, ни әйтсәк тә, безнең балалар контрольдә. Без үскәндә булмады ул. Шуңа әти-әнидән эләккәләде дә. Кызларымның тәрбияле булуына шикләнмим. Милли тәрбиядә үсәләр. Яшәү урыныннан ераграк булса да, юкка гына Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясен сайламадык. Кызларның, авылга кайтып, «әбика», «бабайка» дип йөрүләрен күз алдыма да китермим.

Син кызларың белән бик якын. Һаман балалар белән, алар тормышы белән яшисең кебек.

– Кызларым белән горурлану бар. Аларның уңышлары белән социаль челтәрләрдә дә уртаклашасы килә. Илүзә олимпиадаларда җиңә, бию буенча уңышлары зур, Галия фигуралы шуу белән шөгыльләнә. Әлбәттә, тормышлары белән кызыксынам. Минем кызлар бит ул. Алар өчен җаваплымын. Әтине бала вакытта мин дә күрмәдем. Ул җитәкче кеше булгач, иртән чыгып китте дә төнлә кайтып керде. Иртән аркадан сөеп чыгып киткәнен йокы аралаш сизеп кала идем. Аның белән горурландым. Яратудан туктамадым. Кызлар аңлый: мин эштә. Көн саен алар белән була алмыйм, әмма җай чыккан саен, без бергә.

Кыз бала әтисеннән куркырга тиешме ул?

– Курыкмасын, ә менә әти каршында җаваплылык тойсын. Илүзә миңа охшаган. Әти-әни алдында оятка калмыйм дигән уй белән яшәдем, хәзер кызым шулай. Укуы, әйбер сорамавы, акча бирсәм дә, нигә аның кадәр күп салдың, диюләре миңа охшаган.

Акча дигәннән, кадерен беләме?

– 14 яшендә паспорт алуга, без аңа акча картасы ачтык. Депозитларны өйрәттем. Без бит аны бөтенләй дә белми үстек. Илүзә хәзер барысын да күзаллый. Акча кадерен белә. Бүгенге көн белән генә яшәмәскә, акчаны саклап тотарга өйрәттем дип уйлыйм. Илүзә хәзер үзе шактый акча эшли инде.

Әти көнләшүе бармы ул? Син аңа ничек карыйсың?

– Табигый процесс инде ул. Балалар өлгерә, мәхәббәт барлыкка килә. Кинаяләр рәвешендә сора-шам, кечкенәсенең апасын әзрәк кенә саткалаганы дәрәҗәсендә беләм. Билгеле, дус булган еге-тенең кем икәнен беләсе килә. Аның бик тә тәрбияле булуын телисең. Көнчелек юк. Әлегә юк... Бәлки, соңрак булыр. Әмма булуын теләмәс идем. Үрнәк әти образын егетләренә күчерсәләр, әйбәт булыр иде. Без – ирләрдә дә хатыным әнигә охшасын иде дигән фикер яши бит.

Син үпкәчел әтиме?

– Булгалый инде. Вакытында шалтыратмаса, үпкәләп куясың. Кызлар белән гел языштып торам. Миңа алар белән элемтәдә тору бик мөһим.

Кыз бала әтидән бүләк алып үсәргә тиешме?

– Әлбәттә! Мин әле хәзер дә, зур кызлар икәнен белә торып, йомшак уенчыклар бүләк итәм. Алар аны куанып кабул итә, ул уенчыкларыннан аерылмыйлар. Бәйрәмнәрдә, чыгышларыннан соң чәчәкләр бүләк итәм. Сәнгать кешеләре чәчәк ярата бит ул. Кыз бала буларак, аларны иркәләп үстерергә кирәк. Кочаклап үбүләрсез булмый инде. Хәзер Илүзә зур инде, андый иркәләүләр арткарак калып бара. Ә Галия белән сөешәбез әле. Күңел белән иркәләү – бала белән араларны якынайта гына ул.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна Арахамия



Алсу
ШАКИРОВА

– Әтинең бабасы үз якларында оста куллы бик танылган тимерче булган. Укымышлы, зыялы иде дип тә искә ала аны әти. Бу сыйфатлары улына – минем бабама да күчкәндер. Ул балаларына гадәти булмаган исемнәр биргән. Каян килгән авыл малаена мондый омтылыш? Олы кызына Зәрия, ягъни таңда туган кыз дип исем кушкан. Кече улы – Аргинал. Оригинал дигән исемне шулай үзгәртеп язганнар. Әтигә Планет исеме кушкан, ягъни бар планетадан алдан, алдынгы дигән мәгънә салган исемгә. Аны татарчалаштырып, туу таныклыгына Планит дип теркәгәннәр, – дип башлый әңгәмәне Лилия ШӘФИЕВА. Тимерчеләр нәселеннән килеп чыккан бу исем ниндидер үтә дә нык эретмә, яңа бер элементны хәтерләтеп яңгырый хәзер – бер ябышса кире аерылмый торган, тыгыз, мәңгелек, ышанычлы Планит. Лилия ханымга әнә шундый сыйфатлар өсти кебек әтисенең исеме. Ләкин хикмәт исемдә генә микән соң?

«Бик яхшы сөйләүгә караганда, бик яхшы эшләү яхшырак». Лилия ханымның өстәлендә танылган сәясәтче, дипломат Бенджамин Франклинның шул сүзләре беркетелгән. «Яраткан эшең белән шөгыльләнсәң, үз гомереңдә бер генә көн дә эшләмәссең», дигән әйтем дә – аның кебекләр турында. Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре, Татарстанның нәфис гимнастика федерациясе вице-президенты, «Фидакарь хезмәт өчен» медале иясе Лилия Планит кызы гади эшчеләр гаиләсендә туып-үстем дисә дә, әнисе Фирдәвес апа – Республиканың атказанган икътисадчысы. «Точмаш» заводында эшләп, күпсанлы хезмәтләре белән беррәттән, патентны экономик яктан нигезләү формуласын исәпләп чыгарган кеше. Әтисе – без инде искә алган Планит абый – Кама Тамагы районы Кыртапа авылы егете. Армия сафларында хезмәт иткәннән соң, Казанда калып төпләнә.

– Гомумән, нәселдән «кайнап торучан» без. Мәктәпне тәмамлагач, һөнәремне балалар белән бәйлисе килгән иде бит. Тәрбияче булырга да хыялландым, балалар табибы да... «Экономист булсаң, югалмассың, – диде әни. – Калганын тормыш күрсәтер». Нәтиҗәдә, барыбер бөтен гомерем балалар белән бәйле менә...

Казанның Горки дип йөртелгән микрорайонында урнашкан фатирлары каршындагы бушлыкта бүген илнең иң алдынгы һәм зур гимнастика үзәкләренең берсе төзелгән.

НӘФИСЛЕК ФАНАТЫ



Аның урынын да Лилия ханым киләчәктә үзе сайлаячак. Дөрес, Олимпия резервындагы «Приволжанка» спорт мәктәбе өчен карап куйган урын була ул. Ләкин 2013 елда Казанда узасы Универсиада планнарын көтелмәгән яссылыкта киңәйтеп җибәрә.

– Гимнастика үзәген шәһәр уртасында салырга кирәк дигән теләкләргә каршы килеп, Идел буе районы өчен көрәштем. Ул вакыт Татарстанның спорт һәм яшьләр министры Марат Бариев фикердәшлек күрсәтте, моның өчен әле дә рәхмәтле мин аңа. Проектын төзүдә дә үзем катнаштым. Алай гына да түгел, экономист буларак, Спорт министрлыгы расчетларны үземә эшләргә бирде. Формулалар, брошюралар тоттырдылар кулыма. Плитка, буяу метражларын тәфсилләп санап, клининг күпме кирәк булачагына кадәр исәпләп, кәстрүлләр, тәлинкәләр санын тәңгәлләп башкардым ул эшне.

«Гимнастика үзәге» директоры итеп билгеләнгәч, «җылы урынга кереп утырды» дип әйтүчеләр Лилия ханым башкарган эшләргә алыныр иде микән ул вакытта, ай-һай... Универсиада алдыннан яңа спорт үзәгенә директор булып килергә теләүчеләр табыла, әлбәттә. Күпчелеге – ирләр. Ә ул инде үз урынын төзелеш башланганчы, проект этабында ук хезмәте белән раслаган. Лилия Шәфиева кандидатурасын яклаучылар күп була. Республикада нәфис гимнастикага кагылышлы барлык мәсьәләләрне аркылыга-буйга гизгәнен дә күреп, белеп торалар. «Нәфисләр өчен» дип бар көчен куеп, күз алдында «үстергән» спорт үзәген спорт гимнастикасы белән дә бүлешергә кирәк булачак дигән сүзне бөтенләй кабул итә алмый ул. Ишетүгә, күзеннән яшь бәреп чыга. Ләкин бу – үзәкнең киләчәге өчен төп шартларның берсе икәнен аңлый җитәкче. Ризалаша. Аннары спорт гимнастикасына кай арада гашыйк булганын сизми дә кала. Үзәкнең ачылышына килгән Россия спорт министры Виталий Мутко яңа директорга тагын бер җаваплылык йөкли әле: «Батутта сикерү – бик яхшы спорт төре. Синең бөтен мөмкинлегең дә бар, алын», – ди. Шулай итеп, бер түбә астында җайлап кына өч спорт төре эшләп китә...

Кечкенәдән тиктормас булып үсә Лилия. Бию белән шөгыльләнә, җиңел атлетика белән мавыга. Сыйныфташ кызлары белән Пионерлар йортына барып, аларның нәфис гимнастика белән шөгыльләнгәннәрен ишек ярыгыннан карап торырга ярата. «Шпагат»ка утыруларына, «мостик»ка төшүләренә таң калып тора бәләкәй кыз. Табигый сыгылмалылыгы белән аерылып тормагач, бу спорт төренә керергә уйлап та карамый ул. Ә читтән карап, чын фанатына әйләнә. Әтисе, кармак сабын кисеп, атлас тасма бәйләп, гимнасткаларныкы кебек лента да ясап бирә. Ә Лилия шуны тотып өйдә бөтерелә, биергә ярата. Еллар узгач, спорт ветераннарын чакырып, бәйрәм белән котлаганда шул сыйныфташ кызларның берсе – спорт ветераны әйткән сүзләре әле дә исеннән чыкмый: «Лилия, кем уйлап караган бит... Мин нәфис гимнастика белән шөгыльләндем, ә син аны үстерәсең», – ди ул.

Әйе, нәфис гимнастика белән якыннан олы кызы Динара аша гына таныша әле ул. Фәридә Вафина исемле тренер бәләкәй кызны балалар бакчасында күреп, тренировкаларга алып килүен сорый. «Үзем биедем, кызым да биюгә

Әни: «Укып чык әле, аннары тормыш күрсәтер», – диде. Күрсәтте!

йөрер», – дип кырт кисә Лилия ханым. Ләкин тренер аннан да үзсүзлерәк булып чыга, барыбер кызны китертә. «Бер генә тапкыр алып барам», – дип чыгып киткән юлдан 34 ел атлый инде Лилия Шәфиева. Динарасы нәфис гимнастика белән шөгыльләнә башлауга, бухгалтер эшеннән китәргә туры килә аңа. Үз баласы хакына гына түгел – бөтенесен кайгыртып. Ул вакытта хәзерге кебек шартлар юк, ярышларга барган вакытта балаларны карар өчен әти-әниләрдән башка берничек тә мөмкин булмый.

– Кызларны ашатыр өчен үзебез белән плиткаларга кадәр алып бара идек. Тушенка таба алсак – бәхет инде. Пешкән бәрәңге, йомырка тутырабыз сумкаларга. Шулпа пешерү өчен шакмакчыклар чыккач, сөендек – без инде аш та пешерә алабыз бит! Бөтен команданы тукландырырлык ризык төяп, олы сумкалар өстерәп йөрдек, – ди ул.

Ул вакытта Казанда нәфис гимнастика буенча бердәнбер 11 нче мәктәп кенә була әле. Әнә шулай булышудан башланган активлыгы гомерлек хезмәткә әйләнгәнен үзе дә сизми кала Лилия ханым. Ышанычлы әнидән әти-әниләр комитетын җитәкләвен үтенәләр.

– Ярыш вакытында мин генә түгел, бөтен туганнар җыелышып килә. Безнең гаилә шундый – үзебезнекенә дә, башкаларга да җан атабыз. Әле дә хәтерлим, Россия–Германия дуслыгы уеннары узганда Динара әле катнашмый да иде. Бакчада булган бөтен чәчәкне кисеп, җитәрлек булсын өчен кыр чәчәкләре җыеп өстәп, һәр катнашкан кызга бәйләм бүләк иттек.

Шул рәвешле, рәсми эшен ташлап, күңеле тарткан даирәгә башаяк белән чума Лилия ханым. Сәбәбе дә чыгып тора – Динара спорт мастерлыгына разряд яклыйсы елда спорт мәктәбе директоры аларны җыеп, мәктәпнең капиталь ремонтка ябыласын хәбәр итә. Андый чакта нинди йөрәк белән читтә калырга кирәк?!

– Балалар урамда кала дигән сүз бит бу. Тегендә дә кереп карыйбыз, бу ишекне дә шакыйбыз. Шунда берничә тренер, оешып: «Лилия, нәрсә дә булса уйларга кирәк, булыш безгә, оештырып җибәр», – дип, миңа мөрәҗәгать иттеләр. «Мин моңа катнашырга теләмимен, булышсам гына», – дип тотындым. Вишневский урамында Татарстанның үзәк депозитарий залын арендага алып, ҖЧҖ «Нәфис гимнастика үзәге» ачып җибәрдек.

Бөтен исәп-хисапны үзе алып бара Лилия Планитовна. Яңа үзәкнең рәсми директоры мөнәсәбәтләрне җайга салыр өчен төрле сораулар белән кая да булса сөйләшергә барса: «Директорыгыз килсен!» – дип, Лилия Планитовнаны чакырталар. Тәҗрибәсе дә, үҗәтлеге дә, теләге дә бар – барган җирендә мәсьәләне хәл итеп кайта, үзен ишеттерә белә. Беркайчан да баш тартмый ул, чөнки яңа формалашкан гимнастика үзәгенә ничек тә акча эшләргә, исәп-хисап тотарга, яшәргә кирәк була.

– 1999 елда шәһәрдә беренче түләүле төркемнәр ачтык. Ул вакытта безне аңлаучы булмады – моңарчы кеше

Фото: Анна Арахамия

Шартлар булмауга кызларның берсе дә зарланмый. Һәм... җиңәләр бит!



Ә менә 8 Март көне аларда – Әти көне. Равил абый үз кызларын җыеп, берәр кая ял итәргә, сыйларга алып бара – күңелләрен күрә.

күрмәгән, белмәгән хәл бит. Ләкин балалар килә башлады. Җыелган акча бөтен чыгымнарны капларга гына җитә иде. Энтузиазмга корылган тырышлык белән бер тиенсезгә эшләдем. Ике елдан соң, ниһаять, һәммәбезгә бишәр сум акча эшләдек. Ул сөенгәннәр!

Аннары ярышлар уздыруга да алыналар. Шактый ишекләрне шакырга туры килә. Ә алар турында инде шәһәр хакимияте дә хәбәрдар. Ишеткәннәр, беләләр... Теләкләр һәм мөмкинлекләр тәңгәл килә – Идел буе районы башлыгы Вадим Маркелов аларны үз канаты астына ала. Шул вакыттан Теплоконтроль бинасында яшь мәктәпнең яңа тормышы башлана.

– Үзәктә шөгыльләнгән балалар өчен – дөнья чите иде ул Теплоконтроль. Безгә кем иярер соң дип борчылам. «Шартлар тудырсагыз, балалар да килер», – диделәр. Ә акча каян табарга? Бирәм дип торган кеше юк бит. Мин иремә – Равилгә сөйләдем моны. «Нишлибез?» – дим. «Борчылма. Изге эшкә кызганыч түгел», – дип, акчасын да тоттырып җибәрде, бригадалар да табышты. «Приволжанка»ны шулай аякка бастырдык.

Спорт мәктәбендә җигелеп эшли Лилия Планитовна. Мәктәп ачылышына килгән район җитәкчелеге башкарылган эшне күреп чын соклануын белдерә. «Нәрсә белән ярдәм итим?» – дигән сорауга Лилия Планитовнаның генпланы әзер. Бинаны тулысынча спортчылар өчен бушатырга, интернат төзергә! Аш булмәсе, ял бүлмәсе, сауна кирәк балаларга! Балалар да җыела. Әкренләп түгел! Беренче җыелышка ук 180 бала килә! Ә эшләрлек белгечләр юк. Үзе дә әле генә гимнастика белән шөгыльләнүдән туктаган Динара белән тагын бер яшь тренер бер генә баланы да кире какмыйлар, тренировкаларны башлап җибәрәләр.

– «Нәрсә хакына?» – дип сорыйлар миннән. Нәфис гимнастиканы яратуым сәбәпче моңа. Телевизордан ярыш барганын күрсәм, битараф кына узып китә алмыйм – ахырынача карыйм. Ә җан атуым – үзе бер күренеш. Равил видеога да төшергән иде бервакыт. Соңыннан карап, көлдем.

Яңа мәктәпне уңыш күттерми – балалар арасыннан Россия беренчелеге призерлары тәрбияләнә. Булачак йолдыз – Олимпия уеннары җиңүчесе Дарья Шкурихина үсеп килә. Ул инде мәктәпне башка биеклектә таныта, җиңүләр китерә. Казан кызларын Ирина Винер үзе күреп ала, Россия җыелма командасына чакыра башлый. 2004 елда илнең йолдызлы гимнасткалары Алина Кабаева, Ләйсән Утяшева, Ольга Капранова белән бергә ярышка килеп, Казанның меңьеллыгы уңаеннан Россия чемпионатын уздыру хокукын Казанга бирә! Бу яңалыктан башлары күккә тия!

– Ничек әзерләнгәнне белсәгез! Коверны да, помостны да хатын-кызлар үз җилкәбезгә салып ташыдык. Ничек җәясен дә белмибез – өйрәндек, – дип искә ала Лилия Планитовна.

Үз баласы кебек кадерләп үстергән спорт мәктәбен тиздән ышанычлы кулга тапшырып, инде Федерациянең вице-президенты буларак бөтен Татарстан өчен хезмәт куя башлый Лилия ханым. Төркем белән чыгыш ясау популярлаша ул елларны. Ә Татарстан артта булырга күнекмәгән, һәрвакыт алга омтылучы Федерация дә үзенә яңа биеклекләр, зуррак максатлар куя. Тотынгансың икән – яхшы нәтиҗә дә булсын! Лилия Планитовна Татарстанның нәфис гимнастика Федерациясе президенты Гөлнара Сергеева белән кулга-кул тотынышып эшлиләр.

– Гөлнара Илдусовна Федерация ихтыяҗларын югарыда кайгырта, статусны арттыру юнәлешендә зур көч куя, мөмкинлекләр таба. Аның тәҗрибәсе, ярдәме белән безне хәзер бөтен илдә танып, безнең белән исәпләшәләр. Элек ярышларда безне уйлап та карамыйлар иде, хәзер «Татарлар чыгыш ясамады әле», дип, безнең команда чыгышын көтәләр. Ирина Винер ризалыгы белән тренерларны Мәскәүдән чакырдык, безнең кызлар белән алар эшләде. Бөтен көчне 2013 елда буласы Универсиадага юнәлдердек, чөнки анда Россия чемпионатында откан команда барачак. Бу – безнең яңа максат иде...

Ләкин аның четерекле яклары да күп була әле. Идел буе спорт һәм туризм академиясенә студентларны бөртекләп туплыйлар. Чөнки Универсиадада катнашыр өчен гимнасткаларның студент булулары мәҗбүри. Диана Семенова исемле спортчы кыз моның өчен мәктәпне экстерн рәвештә тәмамалап, бер ел алдан керә академиягә. Казанда команданы бөтен ил буйлап җыялар, студентларны хәтта үзләре түләп укыталар. Төзелеш эшләре дә бетмәгән залда әзерләнгән кызлар шунда ашый, шунда ук ял итә. Уртак максат бөтен команданы бербөтен итеп туплый, барысына да түзәләр. Һәм... җиңәләр бит! Атаклы «Лесгафт» Петербург гимнасткалар команда»сын җиңәләр!

Кызганыч, Универсиадага безнең команда бара алмый кала... «Бары тик илнең җыелма командасы гына барачак», – дип хәбәр итә Ирина Винер. Моны ишетүгә елый башлый Лилия ханым. Бик зур югалту кичергән кебек хис итә үзен. Никадәр каршылык аша үттеләр бит алар! Ничек әзерләнделәр! Алар әзер бит! Казан җиңәргә әзер!

– Нәфис гимнастика минем өчен беркайчан да икенче планда булмады. Ул – минем төп тормышым. Шуңа күрә бик авыр кабул иттем. Ирина Александровнага рәхмәт, барыбер безнең Лена Романченконы җыелма командага алып, ай ярым эчендә программаны өйрәтеп, Универсиадада катнашты. Казанга өч алтын медаль алып кайтты ул.

Әйе, һичшиксез, Лилия Планитовнаның бөтен тормышы нәфис гимнастика белән бәйле. Кайсы темага кереп китсәк тә, ул барыбер эшенә әйләнеп кайта. Казанның гимнастика үзәгендә Шәфиевләрнең өченче буын вәкиле йөри бит инде. Оныклары да бу бинада спорт белән, бию белән шөгыльләнә. Шуңа күрә бөтен гомере эш белән узган кебек тоелса да, Лилия ханымда кадерле әни, яраткан дәү әни рольләре дә бик җиңел үрелеп бара. Олы кызы Динара Сафина шулай ук гомерен шушы спортка багышлаган шәхес дисәм дә, арттыру булмас. Озак еллар дәвамында Татарстан җыелма командасының баш тренеры вазыйфасын башкара, халыкара категорияле хөкемдар. Кече кызы Наилә Сәйфетдинова Юлия Барсукова исемендәге спорт үзәген җитәкли.

– Наилә холкы белән миңа охшаган. Бернидән курыкмый, яңа эшкә теләп тотына, амбицияләре дә җитәрлек. Гимнастика буенча китмәсә дә, гомер юлы аны да шушы спорт төренә алып килде. Динара да, беркайчан тренер булмаячакмын, дип, катгый рәвештә әйтсә дә, бер адым да китә алмады. Язмыш дими, ни дисең. Бер ел буе репетиторлар белән юрист булырга әзерләнде. Очраклы рәвештә генә КАИда спорт менеджменты кафедрасы ачылуын күреп алды да, университеттан документларын алып, шунда укырга керде. Ире белән дә шунда танышты.

Ә Равил абый – сабырларның сабырыдыр, мөгаен... Иң беренче ярдәмчесе, таянычы ул Лилия ханымның. «Син үзеңә бик әйбәт хобби сайладың, мин сиңа ярдәм итәргә әзер», – ди. Спортка багышлаган өч дистә ел буена: «Нишләп йөрисең, сиңа нәрсәгә кирәк бу?» – дип, бер тапкыр да әйткәне булмый аның. Үзе лаеклы ялга чыгу белән



шәһәр читендәге йортларына күченеп китә. Лилия ханым исә эшен берничек тә калдыра алмый. Көн саен 50 чакрым араны узып йөрү уен эш түгел – шәһәрдә калырга була. Озакка җитми болай йөрү. Беренче тапкыр нәфис гимнастиканы икенче планга күчереп, Равил абыйны сайлый ул шул вакытта.

– Безгә бергә яшәргә күпме вакыт калгандыр, билгесез. Шушы көннәребезне бергә уздырырга кирәк дип уйладык. Яшьтән үк бер-беребезгә тавыш күтәрми идек. «Пшыкпшык» итеп алабыз да, дуслар: «Шафик»лар талашып алдылар, ахрысы, «пышылдашалар», – дип көләләр иде. Равил – үз эшенә, мин үземнекенә китеп югалсак та, беркайчан аерым ял иткән булмады. Һәр якшәмбе – гаилә көне иде. Кызлар белән иртәнге аш әзерлибез, Равил самавыр кайната. Төшке ашка шәһәргә чыгабыз, боулинг уйныйбыз. Атна уртасында иртәнге ашны да, төшкесен дә аерым һәм төрле җирдә ашасак та, кич белән табын артына бергә генә утыра идек. Әле дә бу традицияләрне сакларга тырышабыз. Хәзер оныклар да кушыла безгә.

Ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә әти-әни йортында җыелгач, бу гаиләдә кызлар ни турында сөйләшәләр дип уйлыйсыз? Әлбәттә, бары тик гимнастика турында. «Тагын башланды инде», – дип, ирләр кул гына селти, моннан котылып булмый, имеш.

– Мин Равилдән башка яши дә алмам кебек... Аннан башка бөтен тормышым җимереләчәк. «Син көчлерәк», – ди ул миңа. Ә мин газны да кабыза белмим бит! Без берберебезне алыштыра алмыйбыз, шуңа бер-беребезгә бик нык бәйле дә. Гаиләдә һәрвакыт Равил авторитет булды. Бөтен тәрбияне, әйтәсе сүзне аның аша әйттердем. Мине дә шулай үстергәннәр ләбаса. Әле генә аңладым – бик күп әйбер әнидән торган, әни тоткан гаиләне. Ләкин алга әтине куя белгән ул, – дип искә ала Лилия Планитовна.

Буыннар аша килгән бу зирәклек өчен Шәфиевләр гаиләсен 2016 елда «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медале белән бүләкләгәннәр. Уртак казанышлар, сүзсез генә аңлашулар, теләктәшлек, терәктәшлек, бер-берсенә хөрмәте тупланган бу исемдә. Бөртегенә кадәр...

– Тормышымнан бик канәгать мин. Һәрнәрсәне үз вакытында, баскычлап уздым. Авырлыклары да күп булды. Шуңа күрә үткән юлым кадерле дә. Артык татлы булмавы белән кадерле... Шөкер, хәзер безнең Республикада көчле яшь тренерлар үсеп чыкты, сәләтле балаларыбыз күп. Бүгенге көндә өч спортчы кызыбыз Россия җыелма командасы составына керә, Мәскәү янында урнашкан «Новогорск» спорт базасына йөреп шөгыльләнәләр. Безнең тренерларны шунда җыелма команда белән эшләргә чакыралар. Ләкин алар безнең үзебезгә дә бик кирәк әле! Хәзер үземә элеккеге кебек зур планкалар куймасам да, безнең кызлар бер яңгырашлы аккорд ясарлар әле дип хыялланам. Ә конкуренция бик көчле! Россия талантлы балаларга бай. Фигуралы шуу, спорт гимнастикасы, нәфис гимнастика, синхрон йөзү кебек спорт төрләренә үсәр өчен параллель зачет, ягъни ике регион өчен чыгыш ясарга рөхсәт кирәк. Бу зарурлыкны җитәкчеләребезгә җиткерергә, аңлатырга иде. Ә спортчыларыбызга гел җае килеп торсын, эшләре уң булсын иде!

Фотолар гаилә архивыннан

Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.

«Сөембикә» журналы «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!

САГЫНУ



Энҗе
ФӘЙЗРАХМАНОВА

Минем кайнанам Венера Фәез кызы Ихсанованың исеме «Сөембикә» журналы укучыларына яхшы таныш дип беләм: 1977–1988 елларда ул «Азат хатын» журналының баш мөхәррире булып эшләгән. Кемнәрдер аны әле дә яхшы журналист, әйбәт җитәкче буларак хәтерлидер, ә минем өчен беренче чиратта ул ӘНИ иде…

Әни бик йомшак телле иде: бер кешегә дә авыр бәрелмәс, башта тыңлап бетерер, аннары гына киңәшен бирер...

Минем әти белән әни дә, кайнатам белән кайнанам да – якташлар: Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы Түбән Шөн авылында туып-үскәннәр. Югары белем алганнан соң әтине Кукмара районы Олыяз авылына эшкә җибәрәләр. Әти мәктәп директоры иде. 1983 елда ул балалар белән очрашуга Казаннан язучыларны чакыра. Туфан ага Миңнуллин, Ләбибә апа Ихсанова һәм минем булачак кайнанам Венера Ихсанова кайталар. Укучылар белән очрашудан соң әти аларны өйгә кунакка чакыра – бездә кунып китәләр. Мин боларны төгәл генә хәтерләмим. Әти белән әнинең әйтүе буенча, без аларга энем белән концерт та куйганбыз. Кайнанам белән беренче күрешүем шул булгандыр.

Ә икенчесе... Анысы, әлбәттә, бүгенгедәй истә. Казан медицина институтының II курсында укып йөргән чагым. Февраль ае иде. Әти Казанга җыелышка килгәч, булачак кайнатам белән очрашкан, һәм ул аны үзләренә кунакка чакырган. Әтигә ияреп, аларга мин дә кердем. Рушан белән без шул көнне таныштык. Ул әле яңа гына армиядән кайткан иде – үзенең фотоальбомнарын күрсәтте, сөйләшеп утырдык. Ошатып калган булган икән – әтиләр аша кайда торганымны белешеп, яныма килде. Җәйгә кадәр без, күп булса, бишалты тапкыр күрешкәнбездер. Бер очрашуда мин аңа институтта кечкенә генә бер брошюраны русчадан татарчага тәрҗемә итәргә кушуларын, татарча яхшы белсәм дә, медицина терминологиясенең үзем өчен авыррак булуын әйттем. Рушан: «Мөгаен, сиңа әнием булыша алыр», – дип, мине шунда ук үзләренә алып китте. Ул баруда да бик ачык каршы алдылар. Сынап та караганнар бугай. Табын әзерләгәндә булышып йөрүемне дә яратып калганнар. Кыскасы, Рушанның әти-әнисе: «Бу бала безгә булырга тиеш», – дип хәл иткәннәр.

Сабантуйдан соң, алдан әйтми-нитми, кинәт өчәү безгә кунакка кайтып төште алар. Чәчәкләр, бүләкләр белән. «Кызым, алар ничектер үзләрен башкача тоталар. Бик иркенләп тә кайтканнар. Рушан берәр сүз әйтмәдеме сиңа?» – ди әни аптырап. «Мунчалар ягыйммы, куна каласызмы?» – дип сорагач та, «як, калабыз», дигәннәр. Әти эштән кайтып, барыбыз бергә табын янына утыргач, Рушанның әнисе җайлап кына сүз башлады: «Безнең шундый ният бар... Балаларның башлы-күзле булыр вакытлары җитеп килә, кавыштырыйк», – ди. «Минем бит әле укыйсым бар!» – диюемне сизми дә калдым! Алда – башланмаган дүрт ел, шуның янына тагын бер ел интернатураны да кушсаң... Читтән торып укый алмыйсың, эшкә урнашу турында уйларга да ярамый... «Кызым, кайгырма, бездә торып укырсың, фатирыбыз иркен», – диде әни исе дә китмичә.

Шулай итеп, мин аларның бусагасын атлап кердем... Утыз елга якын бергә тордык без. Аерым яшәргә дә була бит дигән уй башыма да килмәде.

Ничек яшәп киттекме? Без икебез дә студент. Дөрес, Рушан берьюлы ике-өч эштә эшләде, институттан лекцияләрдән кайта да йә 16 нчы заводка, йә мәктәпкә каравылга китә. Мин гел әти белән әни янында. «Әни» дип бик җиңел, җайлы әйтеп киттем мин. Сорарга кайткач ук: «Кызым, миңа ничек эндәшерсең икән?» – дип сорады ул. «Әни диярмен», – дидем. Бик күңеле булган иде шул чакта.

Өйдә нәрсә генә эшләсәм дә, ни генә пешерсәм дә, әни мине мактый иде. Яшь идем бит әле, тормыш итәргә тәҗрибәм юк – бөтен тотынган эшем килеп тә чыкмагандыр, әмма әни нindидер җылы сүзләр таба, үсендерә, булдырасың, ди... Аш-суга үзе бик оста иде ул. Сугыш елларында үскәнгә ризыкның кадерен белә иде. «Бернәрсәне дә әрәм итәргә ярамый», – дип кабатлап кына тора. Безнең балаларга да шуны сеңдереп үстерде.

Мин өйгә аларның барысыннан да иртәрәк кайтам. Аш куеп җибәрәм. Токмачны бик оста кисә идем. Авылда аш үткәрәсе булса, егетләрне армиягә озату кичәләре оештырсалар, токмач кисәргә мине чакыралар иде. Ә аларда башка тәртип – әти калынрак кискәнне ярата икән. «Нәзек токмач телгә дә йокмый бит», – дип шаярта иде ул. Әни аның өчен аерым – калынрак кисә иде.

«Менә минем кебек эшлә, миннән өйрән», – дигәне булмады аның. Карап торып барысына да үзем өйрәнә идем. Аларда «шөн пәрәмәче» пешерәләр. Камыры пилмәннекенә охшаган аның. Хәзерге тарталеткалар кебек, башта касәләр ясап аларны духовкага тыгасың. Үпкә, бавыр, йөрәк, эч маеннан эчлек әзерлисең. Әзер шулпаңны салып, мичтән алган касәләрне азрак җебетәсең һәм эчлеген тутырып, һәр кунакка аерым бирәсең. Бераздан минекеләр дә килеп чыга башлады!

Әни бик кунакчыл иде – бәйрәмнәрдә бездән кеше өзелмәде. Атна саен кемнедер кунакка чакыра иде ул. Җырчы Җәвәһирә Сәләхова, диктор Әминә Сафиуллина, артистка Асия Галиева, университет профессоры Йолдыз апа, «Сөембикә»нең ул чактагы редакторы Роза апа Туфитуллова белән дус иделәр. Алар киләсе булса, берничә көн алдан әни белән меню төзибез. Ул һәрберсенең нәрсә яратканын белә – табынга шуны алырга, шуны пешерергә тырыша. Икәү бергә әзерлибез. Шундый күңелле утыралар иде алар! Йә берәр яңа китап турында сөйләшәләр – барысы да аны инде укыган була. Йә яңа спектакльгә баралар – премьерадан соң очрашып фикер алышалар. Сәясәткә дә кереп китәләр...

Диплом алган елны авырга уздым. Әти белән әни өчен бик сөенечле хәбәр булды ул. Әле укыган вакытта, кухняда икәү утырганда әни: «И-и, кызым, күңелемә шулай килә, тиздән бер сабый кыз бала, тып-тып атлап, шушы борылыштан килеп чыгар сыман тоела», – дия иде. Барысы да нәкъ ул әйткәнчә булды. Беренчегә, чыннан да, кыз алып кайттык, аннан – ир малай. Балаларның аралары бер яшь тә өч ай гына. «Әле беренчесе дә нығып бетмәгән, әллә соң кире уйларгамы?» – дип озак икеләндем. Әнигә бик рәхмәтлемен, шул чакта бу яңалыкны белгәч, икәү утырып сөйләшкәндә ул миңа: «Кызым, бер дә борчылма, булышырмын. Алияне үзем алырмын, ә син кечкенәсен карарсың», – диде. Әмир туугa, Алия, чынлап та, әнигә калды – алар бергә йокладылар. Биш оныгының бишесе дә кадерле иде әнигә. Һәрберсе белән аерым утырып сөйләшергә, аларның проблемаларын игътибар белән тыңларга, киңәш бирергә

Фотолар: гаилә архивыннан.

Аллаһы Тәгалә безне ирем белән шулай әти-әниләр аша таныштырган, кавыштырган.



Иремнең гаиләсендә мине яраткан кызлары кебек кабул иттеләр.

вакыт таба иде ул. Әле менә әнинең вафатына өч ел тулу уңаеннан Коръән ашы уздырдык: оныклары барысы да: «Ул безгә җитми, сагынабыз», – диделәр...

Әни белән эч серләребез уртак иде безнең. Ирем белән кечкенә генә конфликтка килсәк тә, ул аз гына кыек сүз әйтсә дә, барысын да әнигә сөйлим. Болай булды, тегеләй, шуңа сүзгә килдек, дим. Әмма үзе нидер булганны сизенсә дә, беркайчан башлап төпченми иде әни. Хәзер уйлыйм – бөтенесен шулай аңа сөйләү дөрес тә булмаган бит инде. Ул бит аның улы, Рушан аңа барыбер якынрак – кызы Ләйсән туып, 15 ел үткәч кенә тапкан аны әни, бик көтеп алган... Әмма шулай булса да, ул һәрвакыт мине яклап чыга, тынычландыра, араларыбызны көйли... Рушан, бөтен хәрбиләр кебек үк, өйгә гел соң кайта иде. Аның эше никадәр җаваплы булганын хәзер аңлыйм, әлбәттә. Ә яшь чакта ирем гел вакытында кайтырга тиеш дип кенә саный идем. Билгеле инде, әнигә зарланам. Ул тыңлап тора да: «Нигә шулай соңга калып йөри инде, ачуланырмын әле мин аны», – ди. Бәлки, әни аны ачуланмагандыр да, әмма аңа әйткәч, минем ярсуым сүрелә, тарала, онытыла бит – анысы әни өчен мөһимрәк булган, күрәсең.

Берсендә өйдә телефон шалтырады. Барып алдым. Дәшәргә өлгермәдем, телефонның икенче башында ирем: «Света!» – дип, нидер сөйли дә башлады. Тыңлап тордым да: «Ярар, ә хәзер Светага шалтырат инде», – дип, трубканы куйдым. Кәефем китте инде, билгеле. Рушан кайтты: минем авыз турсайган, ул да үзен уңайсыз хис итә. Кемнеңдер сәркатибенә шалтыраткан булган икән. Шул вакыт әни: «И-и, кызым, номерны җыйганда ялгышкан бит инде ул, андый хәлләр барыбызда да була», – димәсә, тавыш, бәлки, зурга да китәр иде...

Мин кайнатам белән кайнанамның тавышланганнарын түгел, сүзгә килгәннәрен бөтенләй дә белмим. Кайчакларда сөйләшмичәрәк йөрүләреннән генә үпкәләшүләрен аңлый идем. Алар гаиләсендә, гомумән, аз сөйләшәләр иде: ымлар, күз карашлары белән генә аңлашалар. Өй тулы китап – күбрәк китап укыйлар. Кайнатам Васил Фәйзрахманович Президент Аппаратында хатлар бүлеге мөдире иде. Эше җаваплы – арып кайта. Ә мин сөйләшергә яратам! Әти белән әнигә институтта булган хәлләр, аннан больницадагы яңалыклар, пациентларым турында сөйлим. Ирем соң кайта – аның мине тыңларга вакыты юк. «Син килгәнче без бик аз сөйләшкәнбез», – дия иде әни.

Алия белән Әмирне тәрбияләүдә әнинең өлеше бик зур булды. Берара балаларны рус мәктәбенә бирү гадәте китте бит. Ирем белән без дә нишләргә белмичә аптырабрак калдык. Әни: «Шәһәрдә яшәгәч, рус телен дә, чит телне дә алар болай да беләчәк, татар мәктәбендә укысалар, телне тирәнтен өйрәнсәләр, югалмаслар. Бер тел белү – икенче телне аңлауга ярдәмче генә», – диде. Кызыбыз да, улыбыз да 2 нче гимназиядә укыды. Гимназия директоры Камәрия Зиннуровна белән әни дуслар иде – аны бик хөрмәт итте.

Әни балаларны бездән артык яратты дисәм дә арттыру булмастыр. Ул вафат булгач, архивыннан бер дәфтәр табып алдым. Алия белән Әмирнең кечкенә чакта әйткән сүзләрен язып барган. Шулкадәр зур ярату ул юлларда! Берничәсен генә мисал итеп китерим әле: «Әтиләре ятып телевизор карый. Алия дә, Әмир дә аның өстенә менеп кунаклаганнар. «Мин дә утырыйммы?» – дип сорыйм. «Юк, син зур, әтине ватасың», – ди Әмир». «Кичә Алия белән Зөһрә Сәхәбиева концертын карап утырабыз. Мин елыйм. «Әбием, нигә елыйсың?» – ди ул. «Елыйсым килә...» Алия мине кочаклап, яшьләремне сөртә башлады: «Әниең кайтмыймыни? Елама, хәзер кайта ул!» «Беркөнне Алиядән: «Кызым, бәбине базардан алып кайталармы?» – дип сорыйм. «Юк, бәбиләр әниләрнең йөрәгендә үсәләр!»

Балаларга гел: «Әти-әниегезнең сүзен тыңларга кирәк!» – дип әйтеп торды алар. Мин эштән кайтып керсәм, әни шунда ук: «Алия! Әмир! Әниегез кайтты, арып кайткан!» – дия иде. Улым шунда ук килеп итегемне салдыра, кызым сумкамны элеп куя, чәй куярга йөгерә... Әни кешене шулай хөрмәтләргә өйрәткән аларга әбиләре. Өйгә кайсыбыз кайтса да, бүлмәдән чыгып каршы алу гадәтен сеңдергән – кемнең нинди эше булса да, ишек төбенә килеп каршылый, кочаклаша. Бу гадәт бездә хәзер дә яши.

Минем дә инде улым үсеп буй җитте, озакламый безнең бусаганы да киленебез атлап керер. Кабат-кабат тагын әнине искә төшерермен... Аның нинди сыйфатларын үземдә булдырыр идемме? Сабырлыгын һәм кешене тыңлый белүен, ашыкмый нәтиҗә ясавын. Аллаһыга шөкер, утыз ел буена бер тапкыр да сүзгә килгәнебез булмады. Беренче елларда моңа, әлбәттә, әнинең сабырлыгы аша ирештек. Башта бик кызу идем. Тиз булсын миңа! Җитезлегем дә бар иде – көн саен идәнне сөртеп алам. Әнигә яңа юган идәннән яланаяк йөрү ошый иде. «И-и, ничек чиста!» – дип куана иде. Чисталыкны, бар җирдә тәртип булуын ярата иде ул. Мин берәр эш эшләсәм, әни гел: «Кызым, арыгансыңдыр инде, ятып тор», – дия иде. Ятып торганымны хәтерләмим, әмма аның

шулай диюе гел истә! Бөтен кайнаналар да әни кебек булса, матур гаиләләр күбрәк булыр иде тирә-юнебездә.

Без аның белән бергә концерт-театрларга, язучыларның юбилейларына йөри идек. Әни анда танышлары белән аралашып, рухланып кайта – бу җанлануы аннары берәр атнага сузыла.

Әни үзе дә бик матур, зәвык белән киенә, минем дә шулай киенгәнне ярата иде. Яңа кием алсам, иң элек аңа киеп күрсәтәм. «Мондарак бас әле... Тегендәрәк бас... Менә булган!» – дип сөенә иде. Нинди кайнана улының хатынына кием алганын мактап утыра әле?!

Безгә дә, оныкларына да әни гел: «Теләкне белеп теләгез һәм шул теләк-ниятегезгә омтылыгыз», – дия иде. Аннан үзен сөйли иде: «Мин гел өйдә нидер эшләгәндә, идән юганда, мәктәпне тәмамлагач, Казанга китсәм, укырга керсәм, зур кешеләр белән танышсам иде, дип тели идем. Барысы да чынга ашты менә!» Әйе, әнигә Мәскәүләргә барып, съездларда катнашырга, Гагарин, Терешкова, Пахмутова кебек шәхесләр белән очрашырга, бергә фотоларга төшәргә, союздаш республикаларда чыгучы хатын-кыз журналларының редакторлары белән аралашып яшәргә, эшләргә насыйп булган. Ул моның белән бик горурлана иде. Үзенә шундый мөмкинлекләр биргән «Азат хатын» («Сөембикә») журналын бик ярата, һәр яңа санын көтеп ала иде. Үзе укып чыга, аннары: «Кызым, менә бу язмаларны һичшиксез укы!» – дип миңа бирә...

Гаиләнең дус-тату яшәвендә исә кода-кодагыйлар арасындагы мөнәсәбәт тә бик зур роль уйный диясем килә. Безнең әти-әниләр бер-берсен бик якын иттеләр. Көнаралаш телефоннан сөйләшеп торалар иде. Әти Казанга җыелышка киләсе булса, әниләргә кермичә китми. «Кодагый, мин кереп чыгам», – дип шалтырата. Әни бу вакыт лаеклы ялда иде инде – шунда ук нәрсә булса да әзерләргә керешә. Әтием белән сүзләре бик туры килә иде аларның.

Кукмарага әниләргә кайтасы булса, бик нык әзерләнәләр иде алар: нинди күчтәнәч, кайдан аласын алдан ук хәл итәләр. Олыязда да шулай әзерләнеп көтәләр. Кич буе, хәтта иртәнгә кадәр сөйләшеп утыралар: уртак темалар, танышлар, хатирәләр күп... Әтиләрнең берсе – баянда, икенчесе гармунда уйный. Күңелле итеп җырлашып утыралар. Әни – кайнанам турында әйтүем – бик матур җырлый иде. «Җидегән чишмә», «Олы юлның тузаны» көйләрен яратып башкарды. Сабантуйга бер атнада Кукмарага кайталар, икенче атнада җыелышып Түбән Шөнгә китәләр... Кода-кодагыйлары белән ул күрешү-очрашуларны әти белән әни бүгенгәчә сагынып яшиләр.

Әти – кайнатам – кинәт китте. Бер көн дә ятып авырмыйча. Өйдән гаражга машинасын төзәтергә дип кенә чыгып киткән иде... Сиздермәскә тырышса да, әни аны югалтуны бик авыр кичерде. Әйтмәсә дә, күзләреннән күреп була иде моны... «Бер-берегезнең кадерен белегез. Мин әтиегезнең кадерен белмәдем дия алмыйм, әмма барыбер үкенечләр күп», – дия иде ул. Алар икесе бер авылда туып-үскәннәр, бер мәктәпкә йөргәннәр, гомер буе бергә булганнар.

Әни Рушан белән кочаклашып, битен биткә куеп утырырга, озаклап сөйләшергә ярата иде. Бигрәк тә әтине югалткач. Андый минутларда аларны борчымаска тырыша идем: гел булмый бит алар. Әнинең мондый чакларда бәхетле икәнен күреп сөенәм. Нинди көнләшү ди?! Әгәр ир-ат әнисенә карата ягымлы икән, аны яратуын, аның белән горурлануын яшерми икән, хатынына да шундый ук мөнәсәбәт күрсәтәчәк. Бу бит күптәнге хакыйкать.

Табиб буларак, әни миңа ышана, белгеч буларак дәрәҗәмне күтәрергә тырыша иде. Олыгая-олыгая, кеше арасында авырулар турында сөйләшүләр күбәя. Әни телефоннан берәр танышы белән сөйләшкәндә, нинди дә чир турында сүз чыкса: «Ярый, киленем табиб бит минем, аннан сорармын», – дип бетерә иде. Һәм чынлап та сорый! Аннан әлеге танышына: «Менә шул белгечкә күренергә кирәк дип әйтте», – дип хәбәр итә. Шундый зурлап җиткерә моны! Үзенең дә күңеле була, теге кешенең дә.

Бәйрәмнәрдә ешрак бездә җыела идек. Ләйсән апаларга да барабыз. Табынга утыргач, иң беренче сүзне гел әнигә бирә идек. «Туганлыкны бездән соң да дәвам итегез, берберегезгә терәк булыгыз», – дия иде ул. Нәкъ шулай яшибез хәзер дә... Әни сөйләргә бик оста иде. Ә мин үзем нидер сөйли башласам, күңелем тула, елыйм... «Кызым, синең күңел чишмәсе якынрак, шуңа елата», – дия иде әни.

«Кайнана белән ничек шулай тату яшәп була, серләрен өйрәт әле», – дип киңәш сорап килүчеләр булды. «Иреңне яратасыңмы? Әнисе булмаса, ул да булмас иде бит, һичьюгы шуның өчен кайнанаңны якын итәргә кирәк, – дия идем. – Ә бу яхшылыгың барыбер үзеңә әйләнеп кайтачак».

Без шәһәр читенә йорт салгач, әни күченергә теләмәде – балалар белән фатирда калды. Кунакка килсә дә, бер атнадан озак тормады – үзенә кайтырга ашыкты. Көнаралаш аның янына керә идем: җылысын тоярга, сөйләшеп утырырга... Ул сөйләшүләр шундый җитми миңа бүген. Сагынам...

Әни авырып киткәндә, Рушан Мәскәүдә иде. Операциягә кергәндә әнине мин озатып калдым. «Рәхмәт, кызым, без бергә бик рәхәт яшәдек», – диде ул... Иртән: «Кан басымы төшә, тиз килеп җит», – дип шалтыраттылар. Реанимациягә янына кердем. Мине күргәч, әни елмайды. Куллары салкын иде инде. Һәм шул минутта ул китте дә... Бер нәрсә өчен җаным тыныч: әнинең җеназасы моргтан түгел, өйдән китте, төне буе аның янында туганнары булды, догалар укылды. Ул бит мулла кызы – боларның барысы аның өчен никадәр әһәмиятле икәнен белә идем. Әгәр моны эшли алмаган булсам, үземне гомер буе гаепле санар идем.

...Безнең кавышу тарихын ишеткәч: «Син бит егетләр белән дә йөрмәгәнсең, кияүгә дә яратып чыкмагансың – сезне ярәшкәннәр генә», – дип әйтүчеләр булгалады миңа. Хәтта жәлләп карыйлар иде. Ә мин алай уйламыйм! Без Рушан белән бер-беребезгә бик туры киләбез. Электән әти-әниләр балаларына парны үзләре сайлаган. Барысы да исәкә алынган: нәселе, туганнары, авырулары... Һәм мин моны дөрес дип саныйм. Безнең әти-әниләр дә аек акыл белән, уйлап эш иткәннәр һәм ялгышмаганнар.

«Кайчак нәрсә дә булса эшләгәндә янымда әни торган сыман тоела», – дип әйтә иде әни. Мин дә шундый хисләрне еш кичерәм хәзер. Әле менә аның рухына Коръән укытырга җыенганда, табын әзерләгәндә дә шулай булды: әни янымда – аш бүлмәсендә басып тора, борылырмын да, аны күрермен кебек...

PRESSA

ЗӘР-ЗӘР-ЗӘРӘГӘ!



Лилия
ГӘРӘЕВА









Кешеләр табигатькә булган мөнәсәбәтләрен борын-борыннан йолалар һәм гореф-гадәтләр аша чагылдырган. Алар ярдәмендә югары көчләргә мөрәҗәгать итеп, үз тормышларына җиңеллек, уңыш сораганнар. Игенчелек, терлекчелек белән көн күргән халкыбыз язга һәрвакыт зур өметләр баглаган – алда башланмаган бер цикл. Карга боткасы, Нәүрүз кебек бәйрәмнәр яз килүенә, тереклекнең уянуына шатлык белдерү ул. Яңа циклны гадәттә Карга боткасы башлап җибәргән.

«Карга боткасы» – авыл кешеләрен берләштергән, күмәклек хисен уяткан. Авылның һәр кешесе бу йоланы үтәүдә үзенең мөһимлеген тойган.

Карга боткасы

«Карга килсә, яз килә», ди безнең халык. «Кара карга яз китерә», дигән әйтем дә бар. Кара каргалар канат очларында яз алып кайта дип ышанган борынгылар. Аларның җылы яклардан әйләнеп кайтуын бөтен авыл белән бәйрәм иткәннәр.

Карга боткасы – татар халкының борынгы йолаларының берсе. Иртә язда, кара каргалар килгән вакытта уздырылган ул. Әлеге йоланың нигезендә кыр эшләре башланганчы, югары көчләрдән мул уңыш сорау яткан.

Фольклор белгече Марсель Бакиров фикеренчә, «Карга боткасы» халык арасында яшәгән кара карга культы белән бәйле булырга мөмкин. Кайчандыр, бик борынгы заманнарда, карлар эреп, кара җирләр ачыла башлаган вакыт кара каргалар кайту белән бәйләп каралган. Төгәлрәк әйтсәк, кара төстәге тотемлы әлеге кошның рухы белән. Алар кыш белән яз арасында арадашчы булып саналган. Кара каргалар безнең яклардан бик соң, кышка кереп барганда гына китә. Борынгыларга алар җирнең җанын да үзләре белән алып китәләр кебек тоелган. Күчмә кошлардан иң беренче булып кайтучылар да – алар. Шулай ук кара карга яшәү белән үлем арасын бәйләүче кош буларак та каралган. Кыш – үлем, яз – яшәү.

«Карга боткасы» төрле җирдә төрлечә атала. Кайсыбер якларда аны Карга туе (Башкортстанда), Зәрә боткасы (Мамадыш тирәләрендә), кайдадыр Бәрмәнчек боткасы (керәшеннәрдә) диләр. Тел галимнәре «зәрә» сүзенең «зерно», ягъни орлык мәгънәсендә кулланылуын фаразлый. Этнограф Рәүфә Уразманова Киров районының Түбән Шөн авылында шундый легенда язып ала: «Ташу вакытында мари милләтеннән булган бер байның Дәрә исемле кызы ташуда бата. Кызы истәлегенә ул һәр елны авылдашларына ярма өләшә. Әлеге ярмадан күмәкләшеп ботка пешерә торган булалар».

«Бәрмәнчек боткасы»н керәшеннәр Пасхага бер атна кала уздырган. Бу көнне балалар урманнан тал песиләре алып кайткан һәм аны ярма бирүчеләргә бүләк иткән. Юлларында очраган кешеләргә әлеге тал чыбыклары белән сугып: «Бәрмәнчек, бәрмәнчекәй, Олы көнгә бер күкәй!» – дигәннәр. Кайсыбер авылларда әлеге йолада катнашучылар саламнан бау ишеп, боткадан авыз итүчеләргә шуның белән суга торган булганнар.

Казан татарларында исә «Карга боткасы» Сабан туена бер әзерлек булып саналган. Җир кардан ачыла башлаган бер матур көнне иртән авылның бала-чагасы ботка пешерергә дип урам буйлап ярма җыярга чыккан. Һәр йорт үзеннән өлеш чыгарган – кем ярма, кем май, кем сөт, кем йомырка, тоз биргән. Соңыннан авылдан читтәрәк зур казан асып, җыелган ризыклардан ботка пешергәннәр. Ботка ашарга һәркем үз кашыгын, үз тәлинкәсен ала килгән.

Авылның зурлыгына, кеше санына карап, бер, ике яки өчәр казан да асканнар. Саф һавада, учак исләрен сеңдереп пешкән ботка бик тәмле килеп чыккан. Һәркем үзеннән өлеш кергәнен белеп, кинәнеп авыз иткән аннан. Ә ботканың бер өлешен кошларга сыйланырга калдырганнар.

Ярма җыйганда әйтә торган үз такмазалары да бар:

Зәр-зәр-зәрәгә!
Иртә торып, берсекөнгә – сөрән!
Абыстайлар, түтәйләр,
Чыгарыгыз күкәйләр!

Хай, хай, хай, диләр,
Гали абзый бай, диләр,
Бер-ике гөрәнкә май, диләр,
Май өстенә сөт, диләр,
Сөт өстенә май, диләр!

Менә тагын берсе:
Карга әйтә: кар, кар,
Туем житте, бар, бар,
Ярма, күкәй алып бар,
Сөт, маеңны алып бар
Бар, бар, бар!

Чиләбе, Златоуст якларында яшәүче татарлар җәйнең беренче матур көннәрендә, кыр эшләре беткәч, «Карга туе» уздырган. Анда авылның хатын-кызлары гына – бәләкәй кызлардан башлап, өлкән яшьтәге әбиләргә кадәр катнашкан. Күрше авыллардан да кунаклар чакырылган. Кайбер авылларда хатын-кызларны чираттан сыйлаганнар – карга туе бер көнне бер авылда узса, икенче көнне инде кунаклар хуҗаларны үзләренә чакырган. Табынга куясы ризыкларны бәйрәм алдыннан күмәкләшеп җыйганнар. Гадәттә берәр тау битенә чыгып, казан асканнар, анда ботка пешергәннәр. Күп очракта тары боткасы булган ул. Сыйланганнан соң, төрле уеннар, күңел ачулар да уздырылган. Җиңүчеләргә өйләреннән әзерләп алып килгән бүләкләр – сабын, яулык, тастымал, йомырка биргәннәр.

Йомырка – «Карга боткасы»ның иң мөһим элементы саналган. Ул Җиһанны гәүдәләндерүче символ буларак кабул ителгән. Ботка белән тамакларын туйдыргач, балалар таудан пешкән йомырка тәгәрәтеп уйнаганнар. Берәүләр тәгәрәтә, икенчеләре тау астында әлеге йомыркаларны тотарга тырыша. Бу уенның магик эчтәлеге булган. Йомырка тәгәрәтү җирне орлыкландыруны аңлаткан, мул уңыш алуга йөз тотып эшләнелгән ул.

Хәзер, билгеле, уеннар заманчарак. Шулай да әлеге йоланы башкару балаларда кечкенәдән коллективлык хисен, дуслыкны ныгытуга булыша.

Безнең көннәрдә Карга боткасы күбрәк май башында уздырыла. Әлеге бәйрәмдә авылда яшәүчеләр генә түгел, кайткан кунаклар да катнаша. Таң атып, кояш бераз күтәрелү белән, авыл урамнары балаларның шат тавышларына күмелә. Ярма, тоз ише коры азык-төлек – аерым бер капчыкка, ә сөт, май ишеләр чиләкләргә салына. Кесәләргә конфет, печенье ише баллы

Советлар чорында күп кенә йолаларыбыз тыелган булса да, алар онытылмаган. Бүген кабаттан искә төшерелеп, киләчәккә тапшырылалар.

кучтәнәчләр тутырыла. Балаларның капчыкларына ризык салганда әбиләр күңелдән генә теләкләр дә тели, «Елларга тынычлик бир, тормышыбызга бәрәкәт иңдер!» – дип, Аллаһка ялвара. Еракларадан кайткан кошларны шулай искә алу, балаларның күңелен күреп, аларга бирелгән бу ярмалар сәдака булып санала, бәрәкәт, муллык, тынычлык китерә дип ышанила.

Кырда учак асып, ботка пешерүне гадәттә берәр тәҗрибәле апага йөклиләр. Аңа ярдәмче беркетелә. Ул ярманы юарга су китерә, ярмаларны юып, әзерләп куя. Шул ук вакытта үзе дә казанда ботка пешерү серләренә төшенә тора.

«Карга боткасы» турындагы мәгълүматны беренче булып этнограф И. Ляпидевский 1848 елда тасвирлый. Мамадыш өязының Ядегәр авылында (хәзерге Кукмара районы) яшәүче керәшеннәрнең әлеге бәйрәмне уздыруларын күзәтә ул. Иртән балаларның авылда йорттан йортка йөреп ризык җыюлары һәм кичен казан асып ботка пешерүләреннән тыш, бу көнне ат чабышлары да уздырылуын язып калдыра. Моның «сабанга» әзерлек булуын әйтә.

«Карга боткасы» һәрвакыт ачык һавада гына да пешерелмәгән. Кайбер якларда аны авылдагы берәр йортта әзерләгәннәр. Бәйрәмнең ботка пешерелмәгән варианты да яшәгән. Рәүфә Уразманова үз хезмәтләрендә аның берничә үрнәген китерә. Мәсәлән, Лаеш районында балалар яз көне Дәрә тавына менеп, «Дәрәгә, дәрәгә, ипи чумарына, кызыл күкәйгә!» дип кычкыра торган булган. Ә Малмыж районының Мәмәшир авылында балалар Сабан туе алдыннан кырга чыгып салам яккан. Аларның «Дәр, дәр, дәрәгә, иртә – пешкән боткага, соңга калган – шулпага», дип сөрән салганын ишеткән өлкәннәр: «Дәрә кычкырдылар, Сабан туе җитә», – дигәннәр.

Нәүрүз

Төрки дөньяда язгы бәйрәмнәрнең иң зурысы – Нәүрүз. Ул фарсы сүзе. «Нау» – яңа, ә «руз» көн дигәнне белдерә. 21 мартта – көн белән төн тигезләшкән көнне уздырылган бу бәйрәмнең төп мәгънәсе – яңа елны каршы алу. Үзбәк, төрекмән, азәрбайҗан, кавказлыларда нәүрүз кыр эшләре башлануын да белдерә.

Нәүрүз татарларда алай ук киң таралыш тапмаса да, язма чыганакларга караганда, советлар чорына кадәр аны бездә дә бәйрәм иткәннәр. Бу көнне шәкертләр өйдән өйгә йөреп ярма, тәм-том җыйган. Хуҗаларга әйтә торган үз такмаклары да булган:

Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез,
Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый көтеп торабыз,
Нәүрүз мөбарәкбад!

Нәүрүзне бәйрәм иткәндә төрле уеннар да уйналган.

Әстерхан һәм Себер татарларында көн белән төн тигезләшкән вакытта уза торган «Әмәл» бәйрәме бар, ул хәзерге телгә тәрҗемә иткәндә «март» дигәнне аңлата. Бәйрәм вакытында кояш формасындагы төче күмәч пешереп, аны балаларга өләшкәннәр, өй алдыннан капка аша тышкы якка атканнар.

Йомырка бәйрәме

Язның иң истәлекле, күңелдә кала торган көннәренең берсе – балаларның кызыл йомырка җыйган көне. Чынлыкта, бу бәйрәмнең төгәл генә бер атамасы юк. Күп җирдә аны «Кызыл йомырка бәйрәме» дип йөртәләр. Идел буенда һәм Уралда яшәүче татарларның барысына да хас булса да, үткәрелү вакыты шактый аерылган. Казан татарлары аны гадәттә Сабан туе алдыннан уздырса, керәшеннәрдә, мишәрләрдә Пасха алдыннан үткәрелгән.

Бу көнгә хуҗабикәләр алдан ук әзерләнеп, йомыркаларны суган кабыгы суында кызыл төскә буяганнар. Кечтән бавырсак, вак күмәчләр пешерелгән, конфет-чикләвек әзерләнгән. Казан татарларында балалар йорттан йортка кереп буялган йомырка, кучтәнәчләр генә җыеп йөргән, ниндидер теләкләр теләү гадәте булмаган. Керәшеннәрдә исә өйгә беренче кергән баланы «Аягың җиңел булсын, тавык-чебеш күп булсын», – дип мендәргә утырткannar.

Кызыл йомырка бәйрәмендә өйгә беренче булып җиңел аяклы кеше үтсә, ел уңышлы, терлек-туар, кош-корт үрчемле була дип ышанганнар. Керүче кеше идәнгә йомычка сипкән – ишегалларыгыз буш булмасын, янәсе. Кайсыбер авылларда идәнгә ярма сибү гадәте булган. Бу да тавык-чебешләрнең күп булуын теләп башкарылган.

Ульяновск өлкәсендә яшәүче татарлар бу көнне Патша бәйрәме дип атаган. Пасха алдыннан үткәргәннәр аны. Балаларның өй саен кереп, такмак әйтеп йөрүләрен «чип-чип әйтү» дигәннәр.

«Чип-чип, ак тавыгың утырсын,
Алтмыш чеби чыгарсын,
Алтмышы да зур үссен,
Миңа күкәй бирмәсәгез,
Артыгызда күлегез,
Шунда батып үлегез».
«Чиби-чиби, чип, тавык,
Куначага мен, тавык.
Куначага меналмасаң,
Чебешеңне җый, тавык.
Әби-бабай үдәмесең,
Бер җомырка бирәмесең.
Бер җомырка бирмәсәң,
Тимерчегә барырмын,
Тимер тукмак алырмын,
Башын сугып ярырмын».

Такмакларда янаулы сүзләр булса да, әлбәттә инде, моңа беркем дә үпкәләмәгән. Йомырка җыю бәйрәме кичкә кадәр дәвам иткән. Бу көнне бер йортта 60–70 йомырка әзерләп куелган.

Әлеге йола республикабызның күп кенә районнарында, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә әле дә үтәлә.

Фотолар Татарстанның Чистай муниципаль районы «Иске Роман урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе һәм Бөгелмә муниципаль районының Старое Исаково авылы мәдәният йорты архивыннан.

«ИРЕМ БАЛА КАРАУДАН КАЧА»

Хөрмәтле «Сөембикә»! Сезнең киңәш безнең гаиләгә дә ярдәм итә алыр иде дип уйлыйм. Яшь әни буларак, минем дә бер соравым бар иде. Беренче балабызга – кызыбызга әле кырык көн генә тулды. Бөтен вакытымны аңа багышлыйм. Ә ирем... Бала белән аралашудан кача кебек. Елаганда кулга алып торса, киемнәрен алыштырырга ярдәм итсә, унбиш минут булса да һавада йөртсә, юындырырга булышып, сөлге тотып кына торса да җайлы булыр иде. Ә ул бер эштә дә катнашырга теләми. Бу хакта турыдан әйтмәсә дә, сизеп торам. Кайвакыт юындырыр вакыт җиткәч, юктан да сәбәп табып, әниләренә чыгып китәргә дә мөмкин. Төнлә, бер торып, баланы тирбәтү йә безнең янга күчереп салу турында сүз дә юк... Белмим, баласын әле кабул итеп бетерә алмыймы, куркамы? Иремне балага якынайту өчен нишләргә? Хәзер бу мәсьәләне җайламасам, соңыннан кызыбызга бөтенләй битараф булыр дип куркам.

Галия, Казан.

Азат АБИТОВ,
җырчы

– Бу гаиләне тулысынча белмәгәч, киңәш бирүе авыр. Ләкин үземнән чыгып шуны әйтә алам: мин бу ирне бөтенләй аңламыйм. Бәлки ул, дөрестән дә, әлегә куркадыр, бәлки, бу җаваплылыкка әзер түгелдер. Бераз вакыт узгач, баласына якынаер дип уйлыйм. Әтилек хисләре табигатьтән салынган бит, ул көчәер генә, аннан качып булмый. Киңәшем шул: бөтен вакытыгызны, игътибарыгызны балагызга бирегез, аның киләчәге, саулыгы турында уйлагыз. Ә ирегез белән ачыктан-ачык утырып сөйләшергә кирәк. Бөтен борчыган сорауларны уртага салып хәл иткәндә генә проблеманың чишелешен табарсыз.

Гөлсирин АБДУЛЛИНА,
җырчы

– Дөресен генә әйткәндә, миңа бу ситуация бер дә таныш түгел. Беренчедән, безнең кызыбызга 12 генә көн әле. Икенчедән, күз тимәсен, Азат безнең янга эштән ашыгып кайта, миңа ярдәм итәргә генә тора. Бергәләп юындырабыз, хәтта төнлә күтәреп йөрисе булганда да булыша ул миңа. Ә бу иргә килгәндә: ул куркып калгандыр, мөгаен. Кайбер кешегә үзен яңа рольдә тояр өчен күбрәк вакыт кирәк булуы да бар. Шулай да бала белән контактка керүдән качуны мин бөтенләй аңламыйм... Бала – Аллаһның бүләге бит ул. Бәлки, ул ир бик яшьтер, бала әтисе булуын кабул итеп бетерә алмыйдыр. Бала бик зур җаваплылык, өлгергәнлек таләп итә бит. Сабыр булыгыз, тиздән әти булуына ияләшер ирегез.

Белгеч фикере



Солтания ГАТАУЛЛИНА, психолог

– Бала туу белән яшь гаиләнең гадәти тормышы тамырдан үзгәрә. Үзгәрешләр көн режимына гына түгел, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләргә дә кагыла.

Ир-атларда аталык хисләре төрлечә туа. Кайберләрендә алар бала тугач та барлыкка килә, ә икенчеләрендә бераз тоткарлана. Хатын-кыздан аермалы буларак, ирләргә бу сәләт тумыштан бирелми. Аларның психологиясе башка – алар табигатьтән табышчылар. Әмма хатын-кыз үзенең тапкырлыгы, зирәклеге белән иренең балага булган мөнәсәбәтен үзгәртергә, араларын якынайтырга сәләтле. Моның өчен берникадәр вакыт һәм сабырлык кирәк. Әгәр ир-атка психологик басым ясап торсаң, әлбәттә, капма-каршы нәтиҗә килеп чыгарга мөмкин. Ирегезнең вакыты һәм теләге булмаган килеш, аның бала белән булуын таләп итүнең мәгънәсе юк. Моңа әти кешенең теләге булганда гына ирешеп була, шул рәвешле генә мөнәсәбәтләр җайга салына. Вакытны бергә үткәрү, саф һавада йөреп кайту, гади генә булса да уеннар уйнау бала белән ата арасында күңел күперен салырга мөмкинлек бирер. Бала карау, вакытны аның белән уздыру – авыр йөк түгел, чын бәхет икәнен ирегез дә аңлар.


Сания ӘХМӘТҖАНОВА

Танылган шагыйрә, популяр җырлар авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һади Такташ премиясе лауреаты. «Пар алма», «Кура җиләк», «Өч Пошалым – өч игезәк», «Әниемнең туган көне» җырларын да искә төшерсәк... Әйе инде, Сания Әхмәтҗанованы шундук танып алачаксыз! Күңелләрне айкап алырлык сагыш та, хатын-кыз күңеленең сихри назы да, бөтен дөньяны ямьгә күмәрлек мәхәббәт тә бар аның лирик-фәлсәфи шигырьләрендә. «Арча йолдызлыгы» лиро-эпик триптихы, Нурсолтан, Сөембикә, Мөхлисә Бубый кебек шәхесләребезне укучыларга тагын да якынайткан гаҗәеп поэмалары, җанга ятышлы җырлары аша аны нечкә күңелле, әмма горур, дәрәҗәсен белеп, үз сүзен кистереп әйтә торган затлы-зыялы шагыйрәбез дип беләбез һәм яратабыз. Бу көннәрдә күркәм юбилеен – 60 яше тулуны билгеләп үтүче Сания Әхмәтҗанованы гомер бәйрәме белән котлыйбыз.
Иҗат уңышлары телибез!

СОҢЛАГАН СӨХБӘТ

Беренче милли актрисабыз Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская истәлегенә багышлыйм.

Сәхибҗамалның ак шәле
Ерак еллар томанында,
Киек Казлар Юлы сыман,
Сузыла якты кыйблаларга...
Роберт Әхмәтҗанов. «Сәхибҗамал» дастан-поэмасыннан.

1

«Утыр әле, Сәхибҗамал Туташ,
Бер сөйләшик дөнья хәлләрен», –
Дияр идем, идем... Булса икән
Вакыт агышларын кире борып,
Очрашуның табып әмәлен.

«Бу егетлек сиңа кайдан килде,
Курач буйлы нәфис туташка?»
...Көзге төннең җелегенә үтеп,
Бозлы яңгыр койды тоташтан.

Ефәк шәлдән, юка пәлтәдән мин
Чыгып чапмак булдым урамга.
Мин, янәсе, Сәхибҗамал кебек,
Чыдармынмы җилгә-буранга?
Үзем булып, төп-төз калырмынмы,
Йолыксалар килеп як-яктан,
Сәхибҗамал була алырмынмы? –
Тән өшүе бер хәл... кан каткан.
Кемгә... әйтмим...
Ә бүгенгә минем йолдызым бар –
Табынырлык булып җан аткан.

2

– Нинди максат сине әйдәп барды,
Ачлык тырнагыннан аралап;
Чор вөҗданы, алтатарын төбәп,
Чатта торган чакта сагалап?

Сәхибҗамал Туташ шәле кебек,
Кыйблалардан иңә ак томан.
Колагыма килә көр тавышы,
Һәрбер сүзе,
актрисаның гаярь холкы кебек,
Үзе кырыс, үзе хак, туган:

– Театр, сәхнә, иҗат! Әйе, сәхнә –
Тормышымның бөтен мәгънәсе.
Максатымнан кире боралмады
Бай кияүнең купшы вәгъдәсе...

Күз алдыма килде:
Тормыш-сәхнә диварында бии
Замананың залим шәүләсе.
Каһкаһәләп көлә...
Әмирханнар фатихасы белән
Милли сәхнә җылысына сыена
Япь-яшь кызның җыйнак гәүдәсе.

– Мин уйнадым...
әмма чынбарлыкны...
Уйнамадым, юк... мин яшәдем...
Урамнарга чыгып, шәрран ярып
Кычкырасы килгән чагымда да
Ирен тешләп түздем... дәшмәдем.

Милләт «аһ»ын илттек без меңнәргә,
Бәгырь тыны аша үткәреп.
Зобанидан зекер теләнмәдек,
Заманадан хәер соранмадык,
Кулда йөртегез, дип, күтәреп.

Ачлык нәрсә?!
Ничек аңлатыйм соң
Төн күзеннән кургаш бакканын,
Бер «кыек» сүз өчен, цензураның
Бәгыреңә төбәп атканын...
Татар аңы яктырудан куркып,
Сәхнә белән халык арасына
Шымчы-шәүлә сузылып ятканын...

– Дисең дә бит, әмма соравымнан
Син, Туташым, никтер качасың...
Шул ачлыкта сезнең яшьлек үткән,
Җан асралган ничек акчасыз...

– Акча белән шыр тиле дә эшли,
Ә син көн ит сукыр тиенгә.
Шулай көрәшеп тә яшәмәгәч,
Яшьлек, димәк, узган тигенгә.

– Ник әйтмисең: горур актрисабыз
Соң калфагын салган ломбардка,
Иптәшләре ачтан үлмәсен дип...
Бер чынаяк чәйлек тиеннәрнең,
Чарасыздан саткан киемнәрнең
Хакы тиң бит миңгә-миллиардка.

3
– Онытыгыз...
– Юк, онытмас тарих.
...Ә бит аңа ул чак булган икән,
Тулган икән бары унтугыз.

Миңа да бит өч кат... нәкъ унтугыз,
Шигъри сәхнә яулыйм, эш тыгыз.
Калфак киеп, челтәр шәл япкач та,
Кем әле без? Ипләп алкышлагыз...
Чү, туктагыз, зурдан куптыгыз.

4
Гөрли Казан, неон утлар яшьни,
Эчтән генә әйтеп уй-теләгем,
Акча атам җырлы фонтанга...
Тукай аның исемен ташка уйган,
Исәнбәтләр «Гөлҗамал»ны куйган...
«Ябык» тарих ачкычларны җуйган –
Чор – безнеке диеп мактанма.

Чор безнеке, әмма җыр кемнеке?
Беренчеләр бага Күк багыннан,
Киек Казлар Юлы ягыннан...
«Сәхибҗамал» сәхнә даулый кабат,
Көлдән калкып, Хәтер кабынган.

5
– Әби, әби! Кемнәр бу рәсемдә?
Аларны син түргә элдеңме?
– Менә монысы – Сөембикә, улым,
Сәхибҗамал монысы, күрдеңме?

Беренчеләр, бердәнберләр болар,
Ханбикәләр, асыл бикәләр.
Без онытсак әгәр элгәрләрне,
Алар рухы безгә үпкәләр.

Таркатмаган алар үз ханлыгын,
Һәм сатмаган иман-байлыгын,
Ир-егетләр күтәралмас йөкне,
Иң каһәрле юлны сайлаган.
– Мондый ак шәл, әби, синдә дә бар,
Калфагың да шуңа охшаган...
– Бу ханбикә, сирәк бикәләргә,
Милләт кызларына чорлар әле
Бәя бирер, улым, ышанам.

Якты кыйблаларга җәелә таң,
Челтәр шәл күк тоела томаннар.
Киек Казлар Юлы – сәйярләргә...
Сөембикә, Сәхибҗамал кебек
Ил кызларын әле бәяләргә
Акыл җитеп, бер көн кыярбыз.

Нурлар белән чигеп исемнәрен,
Йолдызлардан коеп хәр сыннарын,
Меңьеллыклар чиген кичеп чыгып,
Мәңгелеккә һәйкәл куярбыз.

МОҢЗАДӘ

Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллинага багышлыйм.

Шушма буйларының таллыгында
Таң атуга бер кош уяна.
Әй өздерә кошчык, әйтерсең лә
Күкрәгендә дөрләп моң яна.

Әй өздерә, җырга салган гүя
Ул халкының бәгырь авазын.
Дала җиле әрнеп чиртә сыман
Өзгәләнгән йөрәк-кубызын.

«Нурҗамал»лар, «Дим-дим»,
«Юксыну»лар
Офыкларга иңрәп агыла.
«Әниемә хат»ның һәрбер юлы
Үкенеч ярасына кагыла.

Шекә пәриләрен оетырлык
«Бәдавам»ның дога-тылсымы.
Билле камзул кияр өчен генә
Яратылмыш гүя буй-сыны.

Арчабикә – горур Гөлзадә ул,
Җырчы кошы туган ягының.
«Ай киң төрки далалары»н иңләп
Оча гүя канат кагынып.

Бер йодрыкка төйнәп газиз халкын,
Гафләт йокысыннан кубарып,
«Әй татарлар!» җырын яңгыратып,
Барган кебек алдан юл ярып.

«Сөембикә варислары»н туплап,
Дәвам-алмаш бирү теләге.
Гаделлекне яклап, ярсый-ярсый,
Халкым, диеп тибә йөрәге.

Яңа заман Сөембикәсе дип,
Йөртә аны кыю уйлылар.
Нәфис сынын калкан итеп баса,
Чигенгәндә алып буйлылар.

Милли мәгариф дип янып йөргән
Нык иманлы Мөхлисәбез ул!
Бәйсез рухлы Сәхибҗамалыбыз,
Ил батыры Нәфисәбез ул!

Һиндстанда, Мисыр, Төркиядә,
Күз күрмәгән ерак илләрдә
Әләм итеп ачып татар моңын,
Җилфердәтә гыйсъян җилләрдә.

Рәхмәт сиңа, халкым, батыр кызлар
Үстергәнсең милләт багында.
«Шаһзадә»ләр дөнья яулаганда,
Гөлзадәләр иман сагында.

Әлфияләр, Вафирәләр алар,
Меңнән берләр – йөзек кашлары.
Ил-йортымның асыл бикәләре,
Милләтемнең асылташлары.

Бер җырчы кош ирек даулап сайрый,
Ватанына, газиз халкына.
Җан авазын мөнәҗәтләр итеп
Әйтеп калыйм диеп талпына.

Канатларын җилләр каерганда,
Туган оясына сыена.
Тынгы белмәс җанын имләр өчен,
Кайта очып Шушма буена.

Бәхете дә, тәхете дә шулдыр –
Үз ягының имин таңнары.
Халкы йөрәгендә канат яра
Җырчы сандугачның моңнары.

PRESSA





Ләбиб ЛЕРОН

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ләбиб Лерон – шагыйрь, журналист, мөхәррир, юмористик хикәяләр язучы, пародияләр остасы. Республиканың Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Шулай ук язучыларның А. Алиш, Ф. Хөсни, Ш. Маннур премияләре иясе. «Ләбиб иҗатындагы төрлелек сәләтенең колачын күрсәтеп тора», – дип язган Шәүкәт Галиев. Ә Рабит Батулла аңа болай бәя бирә: «Ләбиб ул – миһербан иясе, кече күңелле кеше; әдәбиятны, кайберәүләр кебек, мин-минлек күрсәтү мәйданы итеп түгел, җигелеп, авыр йөк тартыр өчен сайлаган егет...» Әйе, ул сәнгатьчә тәэсир итүнең күптөрле алымнарын тоеп яза: елмайта да, көлдерә дә, уйландыра да...

ЮЛ ЧИТЕНДӘ

(Хикәя)

– Малаеңны яратсаң, яртысыз кайтма! Кара аны!

Күкрәгенә яман каты килеп төшкән йодрык авырлыгыннан Ләйсирә кинәт чайкалып китте дә уң як җилкәсе белән ишеккә килеп сыланды.

– Ул синең дә малаең бит! – Аның дерелдәгән иреннәре арасыннан чыккан хәлсез, зәгыйфь сүзләре һавада эленеп калды – кара дерматин белән тышланган каен ишек аның артыннан шапылдап ябылды.

Сумаладай кап-кара төн кыйналган хатынны шыксыз салкын кочагына алды.

Ул, кая барганын да белмичә, башта авыл йортлары тәрәзәләреннән ара-тирә төшкәләгән ут яктысында – урам уртасыннан, аннары юл читеннән атлады...

Авыл бетте. Караңгылык отыры каралгандай булды. Кая бара ул? Ләйсирә үзе дә белми. Колакта ире Фидаилнең сүзләре яңгырап тора: «Кара аны! Яртысыз кайтма!»

Бер-ике адым атлаган иде, ниндидер тимер торбага килеп бәрелде Ләйсирә. Ә-ә-ә, авыл исеме язылган тимер багана икән – әнә бит, авыл беткәнлекне белдереп, «Якты елга» исеменә сызылган аркылы сызык төн карасында да шәйләнә. Кызыл төсе генә күренми...

* * *

Ишекне каты итеп ябуга, Фидаил, өй эчен күздән кичерә-кичерә, эзләнергә тотынды. Махмырдан интеккәндә кирәге чыгар дип, кечкенә шешәләргә аракы салып яшерә торган гадәте бар иде аның. Бер ул гына түгел, эчәргә хирыс бөтен бәндә шулай яшерәдер инде аны. Шунсыз булмый да ул, чөнки махмыр дигәнең галәмәт явыз нәрсә бит – андый чакта чатнап авырткан башыңны таш диварга орырдай буласың...

Матрас астын карады Фидаил, сервантның пыяласыз ишегеннән генә кулын тыгып, чите кителгән фарфор чәйнекне селкеп алды (кайвакытта аңа да аракы салып куйгалый иде), шифоньердагы кием-салымның кесәләрен актарды, хәтта чоландагы кадакларга бау бәйләп эленгән киез каталарны да барлап, тикшереп чыкты.

Шулай бөтен өйне бетереп, ду килеп, җенләнеп аракы эзләп матавыкланганда, өстенә җәелгән япмасы тишкәләнеп, кискәләнеп беткән өстәл астында, куркудан дер калтырап, әллә кайчаннан бирле бөрешеп утырган малаен шәйләп алды ул.

Дөньясына булган бар ачуын улыннан алып:

– Ух сине! Анаң кайтканчы, тыныңны чыгарасы булма! – дип бармагын янады, аягы белән тибәргә итенде. Малай, тагын да куырылып, таяныч эзләгәндәй өстәл аягына ябышып, аны каты итеп кочты да күзләрен чытырдатып йомды.

Фидаил: «Кеше малаен үстереп ят инде! – дип дулый-дулый, өй буйлап йөренә-йөренә, әле тегендә, әле монда актарынырга тотынды. Кеше әйткәч, дөрестер, читтәгеләргә яхшы күренә дип уйлады ул. Һәркемнән көләргә яраткан Шәрипҗан гел төрттерә: «Синең малаең түгел ул», – ди. Югыйсә баштагы мәлләрдә улын тач үзенә охшата иде Фидаил: малаеның башы да, борыны да, ияге дә, күзләре дә нәкъ үзенеке кебек иде...

Бераздан ул баз капкачын ачты да, идән астындагы утны яндырып, башын аскарак суза төшеп, уңгасулга каранып алды. Моннан гына берни табып булмый инде, дип, баздагы баскычка аягын сузды. Ул да булмады, баскычның шарт итеп сынганы, нәрсәнеңдер дөбердәгәне, җимерелеп төшкәне, Фидаилнең исә үгез кебек үкергән котсыз тавышы, баз эченнән кинәт күтәрелеп, бөтен өйгә яңгырады...

Әшәке, куркыныч тавыштан кинәт тураеп, бераз артка чүңкәеп киткән малайга юеш күлмәкле аркасы диварга ябышып калгандай тоелды...

* * *

...Әллә кайнанасы, әллә каенсеңлесе Рәфидә котырттымы, әллә берәрсе «Малаең бер дә үзеңә охшамаган!» – дип шаяртып әйттеме шунда, ару гына барган җирдән кинәт: «Малай минеке түгел!» – дип чыгымлый башлады Фидаил. Баштагы мәлләрдә ара-тирә – бәйрәм-сәйрәмдә генә капкалаган ире тора-бара көн саен эчеп кайтуны гадәткә кертте. Уллары туганчы да, икесе дә көтеп алган шатлык төенчеге Вәсим унбер ай дигәндә тәпи йөреп киткәч тә, яше тулуга аны сөннәткә утырткач та, сабый исәя төшеп, инде 3 яшенә җиткәч тә моңарчы хатынына кул күтәрүне белмәгән ир заты көннәрдән бер көнне кинәт кенә моны көндәлек бер шөгыльгә әйләндерде. Хәтта идәндә егылып яткан хатынына вакыт-вакыт типкәләп алудан да тайчанмады.

Икенче баласы вакытыннан алда төшкән Ләйсирәгә табибның: «Бүтән балагыз булмаячак!» – дигән сүзләре хөкем карары кебек яңгырады. Шул хакта ул Фидаилгә әйткән иде, исерек ирнең тамчы да исе китмәде: «Әрәмтамаклар үстереп беркемнең дә баеганы юк әле!» – дип кенә җибәрде...

Юлдагы эреле-ваклы ташларга абына-сөртенә бара торгач, Ләйсирә Уфа–Казан трассасына килеп чыкты. Юл читенә чыгып баскач, әле уңга, әле сулга каранып алды. Нигә чыкты соң ул бу юлга? Үзе дә аңламый. Аяклары кая атласа, шунда карусыз барырга әзер иде ул. Бары тик кансыз ирennән еракрак кына китәргә кирәк иде аңа. Бөтенләйгә үк китсә дә, үкенмәячәк. Үкенмәячәк, дип... Бөтенләй


Рәсем: Наталья Васильева



кистереп әйтеп тә булмый. Ул бит Фидаилне яратты. Аңа яратып кияүгә чыкты. Юк, яраткан – беткән. Бүтән түзәрлеге калмады. Китәргә, кая да булса китәргә!

Күңелендәге ярсуы, иренә карата булган ачуы ташып түгелергә торган хатын, сөекле баласы барлыгын да онытып, дөньяның читенә үк китеп югалырга әзер иде бу минутларда...

* * *

Фидаилнең үкергән тавышы ничек кинәт яңгыраган булса, шулай кинәт тынды да. Ара-тирә генә аның ыңгырашканы ишетелде.

Шактый вакыт өстәл аягын кочаклап, сулыш алырга да шөлләп утырган малай, ниһаять, аркасын дивардан аерып алырга җөрьәт итте.

Менә ул, 5 яшьлек малай, өстәл астыннан мүкәләп чыкты да, баз авызына килеп, аска карады: әтисе (аның яраткан әтисе!), сакал баскан йөзен чыткан хәлдә, ыңгырашып, суыктан бөкшәйгән кеше шикелле, баз төбендә бөгәрләнеп ята иде. Өстендә дә, янында да – агач баскычның чәрдәкләнгән кисәкләре. Яшел төсе уңа төшкән күлмәгендә коймак хәтле кызыл тап барлыгы да күренә.

Кайгыруы, әтисе өчен борчылуы йөзенә үк чыккан малай, берара уйланып торганнан соң, тавык кетәклегендәге баскычны (ул шул баскычтан печәнлеккә менеп, йомырка җыя торган иде) исенә төшереп, әле базда яткан әтисенә, әле ишек тарафына карап алды да, урыныннан тора башлады...

* * *

Вәсим! Ләйсирәнең йөрәге жу итеп китте. Ул бит йөрәк пәрәсен – газиз улын онытып җибәрә язды лабаса! Үз балаңны ничек онытырга мөмкин? Ана түгелдерсең син, Ләйсирә! Хатын беравык нишләргә белмичә торды. Буш кул белән кире кайтса, Фидаилдән эләгәчәк тә эләгәчәк. Бу юлы сине исән калдырамы әле ул, юкмы? Кая барырга, каян, кемнән акча табарга? Ул юкта Вәсимгә бер-бер хәл булмагае. Күзе-башы тонган, акылы томаланган ирдән барысын да көтәргә мөмкин – үз баласына кул күтәрергә дә күп сорамас. Минем балам түгел, дип, болай да Вәсимгә талпан шикелле кадалырга гына тора...

Үткән-сүткән машиналарның кайберләре сигнал биреп узды. Бәласеннән башаяк, дип, хатын юлдан тагын да читкәрәк китмәкче иде, кинәт якында гына бер машинаның тәгәрмәчләрен чыелдатып туктаганы ишетелде.

– Утыр, әйдә, төн кызы! Кая телисең, шунда илтеп куям!

Ләйсирә, алдына-артына карамыйча, кирегә – килгән юлына таба җан-фәрман чабарга тотынды. Ул да булмады, нәрсәгәдер абынып, җиргә мәтәлде, әйләнә-әйләнә, юл читендәге иңкүлеккә килеп төште.

Юк, озак ятарга ярамый. Тизрәк торырга кирәк! Торырга да йөгерергә кирәк! Улына бер-бер хәл булмагае! Күпме куркып яшәргә була! Кайтырга да, Фидаилгә ябышырга, баланы алып качарга кирәк!

Ул шул ният белән җирдән торды да, авырткан тез башларын бераз угалап алгач, иңкүлектән өскә таба үрмәләп менә башлады...

* * *

Ничек кирәк алай өстерәп, малай баскычны өйгә алып керде, тырышып-азапланып, аны базга төшерде. Аннары иске диван-караватта яткан ике мендәрнең берсен эләктереп, баскыч буйлап шуып дигәндәй аска төште. Әтисенең башын сак кына күтәреп, мендәрне җайлап куйды. Шул вакыт Фидаил күзләрен ачты.

– Әти! Әтием! – диде малай, әтисенең шомырт кара күзләренә тутырып карап. – Авыртамы? Кайсы җирең авырта? Хәзер әни кайта...

Фидаил уң ботына һәм аркасының аскы өлешенә нәрсәдер кадалганын аңлый, ләкин аны берни дә эшләтә алырлык хәлдә түгел иде.

– Су бир... – диде ул. Аннары бераздан:

– ...улым! – дип өстәде.

Малай җәлт итеп баскыч буйлап үрмәләде.

* * *

Ләйсирә ишегалдына кайтып кергәндә, өйләрендә дә, болдырда да ут балкып яна иде. Ул өй тәрәзәсе янына килеп, бераз тыңлап торды. Эчтә тавышмазар ишетелмәде. «Йоклый!» дигән нәтиҗәгә килде ул. Вәсим ни хәлдә икән?

Хәзер ничек өй эченә үтәргә соң, дип, Ләйсирә ишекне тартып карады. Хикмәти Хода! Ишек ачылып китмәсенме!

– Улым! Вәсим!

Өйгә атылып килеп керде ул. Өйдә беркем дә юк, баз авызы гына ачык иде.

– Улым!

Ләйсирә баз авызына капланды.

– Улым! Вәсим!

Баздагы күренешне күреп, ул катып калды.

Малай әтисенең күкрәгенә башын куйган килеш йоклап ята, аның ут яктысыннан тагын да ялтыра төшкән йөзенә елмаю кунган иде.

Бертуктаусыз улының башын йомшак кына сыйпап яткан Фидаил исә, Ләйсирәнең кайтканын гына көткән кебек, күзләрен ачты. Ир белән хатынның карашлары очрашты...

Фидаилнең ирексездән бәреп чыккан күз яшьләре, мәңге туктамас сыман булып, яңагы буйлап акты да акты, акты да акты...



Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

Соңгы вакытта әдәбият дөньясында Лилия Гыйбадуллина исеме аеруча еш кабатлана. Бик талантлы кызыбыз ул! Чаллыда яшәп иҗат итә.
Саҗидә Сөләйманова, халыкара «Бэлла» премияләре лауреаты.
Ел ахырында Лилия Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе инициативасы белән оештырылган ябык әдәби конкурста «Шигырь» номинациясендә – I һәм II, «Поэма» номинациясендә – I, «Балалар өчен повесть» номинациясендә I урыннарга лаек булды. Иҗатына фәлсәфә дә, тирән психологизм да хас.
Ул күңел кылларында уйный. Аны иң талантлы шагыйрәбез дип атыйлар, шигърияткә яңа алымнар алып керде дип бәялиләр. Сезне ымсындырып куябыз: редакциябез папкасында Лилиянең тиздән дөнья күрәчәк өр-яңа шигырьләре ята. Ә бүген укучыларыбызны шигъри хикәясе белән сөендерәбез.

АК ТУФЛИЛӘР

(Хикәя)

Кай арада көзләр җиткән... Әле генә май аеның ихлас җилләре дөньяны иркәли, бакча түрендәге алмагач ак чәчкәгә төренгән иде. Чәчәкләре язгы назлы кояшта, җылы җилләрдә назлана, дөньялыкның иркә чоры, якты чоры иде. Бүген исә эленке-салынкы болытлар менә-менә тәрәзгә яңгыр булып ишелергә тора. Алмагач алма коя. Балланып өлгергән әчкелтем-сусыл алмалар шып та шып көз ишеген шакый. Һай, кай арада көзләр җиткән соң...

Халидә, тәрәздән күзләрен ала алмый, шулай дип уйлады. Көз шул инде. Итәк-чабуларны җыя, кышка әзерләнә торган чор. Сары көзләрне хуҗалыктагы мең мәшәкать белән үткәрү яхшы ла ул. Юкса тирәлеккә күз салып озаграк юандыңмы, күңелне әллә нинди әче сагыш чеметеп ала. Җанга да көзге әрсез җилләр кереп тулган сыман була. Менә бүген дә уйларына чумып озак юанмады хатын. Кырык эше кырык якта ярылып ята ич, өлгер генә. Кызлары Ләйсәннең туена атна-ун көн генә калып бара лабаса. Аңарчы бакчаларны тәртипкә китерәсе, капка-коймаларның уңа башлаган буявын яңартасы, өйне юып чыгасы, тагын әллә ниләр эшлисе бар. Пөхтәлек сөйгән Халидәнең бу олы бәйрәм көненә йорты ялт итеп, тузан бөртеге дә калмаска тиеш иде.

Менә сөмсез болытлар яңгыр тамчыларын тәрәзә пыяласына ыргыта да башлады. Көзге көннең кәефе гел китек шул. Бакча эшләре калып тора болай булгач. Халидә җәһәт кенә чиләк белән су хәстәрләде дә, тузан сөртергә кереште. Хуҗабикәнең үткен күзеннән кызы кичә алып кайткан төргәк-төенчекләр дә читтә калмады. Кара инде, киштәләргә әштер-өштер генә өеп куйган. Ашыгалар шул, ашыгалар, дөнья куып чабулыйлар. Уянмас борын, тагын иртүк эшкә чыгып чапты бит бала. Әни кеше кызының туй көненә кирәк- яракларын үзенчә тәртипләп, пөхтәләп тезәсе итте. Тузаннарын сөртеп, матурлап куйсын әле. Кияүгә китәсе кызына сүз әйтеп, әреплэп тору да ярамас. Иркәләнеп калсын әйдә.

Үз эченнән шулай сөйләнә-сөйләнә, бисмилласын әйтеп, кызының шкафын тәртипләргә тотынды. Кинәт җайсыз куелган бер тартма идәнгә шапылдап төште. Алыйм дип иелгән хатын имәнеп китте – идәндә ап-ак туфлиләр ята иде. Киелмәгән, тузан кунмаган, биек үкчәле, ялтырап торган өр-яңа туфлиләр. Туй күлмәгенә иш ак туфлиләр...

Мондый ак туфлиләрне Халидә дә киде, аның да кызыл туйлары шаулап узды ла. Янәшәсендә – сөйгәне, урамда чәчәкле яз иде. Әйе, алмагач чәчәкләренең сукмакларга коелырга өлгергән керсез таҗларын таплап, алар да парлап уздылар. Аннан алма кебек ике кыз бала алып кайтты Халидә. Кызлар алсу алмалардай тәгәрәшеп үстеләр. Хәләле Харис белән икәүләп сөеп туя алмады алар кызларын. Хәер, иренең бала-чаганы итәгенә утырткан, хаты-



ны белән чөкердәшкән чаклары сирәк булды анысы. Көн-таң атса, колхоз эше белән чапты. Тырыш, сәләтле яшь ирне күмәк хуҗалыкта икътисадчы булырга кыстый башладылар. Озак уйлап тормастан ризалашты Харис. Халидә дә иренең бу эшкә алынуына каршы булмады. Экономистларның акчага интеккәнен күргән юк әле, бала-чага үсә барган саен, чыгымнары да артып тора. Хуҗалыкта да сиплисе, ямыйсы, яңартасы нәрсә шактый. Кыскасы, иренең бу һөнәрен хуп күрде хатын.

Харисны белем эстәргә Казанга җибәрәселәрен алдан чамаласа да, ризалашты. Кирәк-ярагын тутырып, ирен калага озатты. Харис киткәч, өйнең яме беткән кебек булса да, сабыйлары белән юанды. Сагынуын эш белән, балалары белән басарга тырышты. Харис та җай чыгу белән гел кайтып йөрде. Ул кайткан көннәр – чын бәйрәм иде инде.

Тора-бара ирнең кайтулары сирәгәйде. Кайбер атнада «уку торган саен кыенлаша, язма эшләр дә күп бирәләр, бу атнада кайтып булмас», – дигән хәбәрләре генә килә торды. Шулайдыр, уку – энә белән кое казу дип тиккә әйтмиләрдер. Андый хәбәр алган саен, Халидә үз эченнән генә шулай сөйләнә, үз-үзен шулай юата иде. Балалары да: «Әттә тайчан тайта?» – дип, туктаусыз тәтелди ичмаса. Аларны да юатып, сөеп сабыр иттерәсе. Юкса Ләйсәне: «Әттәне тагынды-ы-ым..» – дип, мышкылдап елап җибәрергә дә күп сорамас менә.

Шулай сабыр итә-итә өч ел үтеп тә китте, Харис колхозга укымышлы белгеч булып кайтып төште. Өс-баш – шәһәрчә, кыяфәт – ыспай. Еллар буе өй мәшәкатен үз җилкәсендә сөйрәп, куллары сөялгә каткан, буй-сыны да калыная төшкән, төсе уңа башлаган халат кигән хатын үзен хәләле янәшәсендә ничектер уңайсыз хис итеп куйгалый. Әллә ничек кенә шунда, Харис аңа ят, чит сыман. Аерым яшәгән айлар эчендә барыбер арага нинди дер таныш түгел бер хис кадакланган шикелле иде.

Шулай әле сөенеп, әле пошынып йөргән көннәрнең берсендә Халидә почта тартмасыннан ак конвертлы хат алып керде. Пөхтә, тигез хәрефләр белән иренең исем-шәрифләре язылган конвертны эчке бер тоемлау белән, бармаклары калтырый-калтырый ашыгып ачты. Ачты да, аяк астыннан җир шуышканын тоеп, мич янагына сөялде.

«Харис, кадерлем!

Сине никадәр сагынганымны белсәң! Төшемдә күрми калган төнем юк. Үзең соң? Бер хәбәрең дә юк никтер. Бәгырем, мин түзмәдем, туебызга киярге ап-ак туфлиләр алдым инде. Алар шундый матур! Ә туй күлмәген икәү бергә сайларбыз, яме. Тизрәк кил Казанга. Сагынып-сагынып көтәм. Сине яратып, Фәйрүзәң.»

Аннан соңгы көннәр – төш кебек кенә. Яшәсә – яшәде, яшәмәсә – юк Халидә. Дөньяга бер ышанычы да, гаме дә калмады дияр иде, итәгендәге ике сабые – ике канаты көч куйды, тормышка кайтарды аны. Теге ак конвертта килгән кара, шакшы хәбәр хатынның иренә булган ихлас сөюен таптап, изеп ташлады, кара дегет белән сылагандай итте. Алай да, балаларны ятим итмим дип, бөтенләй чит-ят бәндәгә әверелгән Харис белән бер түбә астында яшәүне дәвам итәргә үзендә көч тапты. Ир, акланып, гафу сорап маташты, икмәк тотып антлар эчте. Ләкин Халидәгә инде бу төчелек бар ни дә, юк ни, аның күңеле бүтән мәңге эремәслек булып каткан иде.

Ә хатны җавапсыз калдырмады ул. Җанындагы бөтен рәнҗү-әрнүләрен кәгазь битенә бушатып, теге кызга хат язды. Үскәнем, оятсыз син, диде. Кеше гаиләсен бозучы дип гаепләде. Харисның өйләнгән ир икәнлеген, ике баласы барлыгын да язды. Бөтен ачуын салып, ярсып – елый-елый, хәрефләрен каты басып язды. Их, күңел әрнүләрен, хыянәт газабын шушы хатка бушатып, конвертка салып ерак-еракка җибәреп кенә котылып булса икән лә...

Инде гарасаттан соң дөнья тынып калган кебек, күңел дә үз урынына бераз утырып, әрнүләр басылып, җан җәрәхәте төзәлеп килгәндә, Халидәнең күңеленә тагын да тирән яра салган бер вакыйга булды. Почта тартмасына яңа хат килеп төште. Нәкъ шул язу, төз хәрефләр. Әмма хат бу юлы хатынның үзенә адресланган иде. Еллар буе әледән-әле төшләренә кереп йөдәтәсен, исенә төшеп, күзләренә яшьләр китерәсен белгән булса, Халидә бу конвертны ачып та тормыйча, ертып ташлар йә булмаса утка ягар иде дә соң.

«Халидә апа, исәнмесез. Сез миңа бик нык рәнҗегән булгансыздыр. Гафу итегез мине. Мин бит ул ак туфлиләрне инде беркайчан да кия алмаячакмын. Аларны киеп, табаннарым янганчы тыпырдатып бии дә алмаячакмын. Аякларым юк бит минем хәзер, апа. Трамвай астында калып, өзелде бит минем аякларым. Сезнең рәнҗешегез төшкәндер...»

И елады Халидә. Иренең йөзенә шушы хат белән бәрә-суга, акылдан шашкандай ярсып-ярсып елады... Менә хәзер дә, ничә еллар үтсә дә, йөзеннән яшь тамчылары тәгәри. Ничекләр гомер итте икән ул бичара кыз? Кайларда икән ул? Гомере буе Хариска рәнҗеп яшәдеме икән? Бәби табу, багу бәхетләре тәтедеме икән бичаракайга? Ә Харис барыбер гомере буе хатын-кыз белән чуалды. Ак туфлиле кыз язмышы да, хатынының күз яшьләре дә киртә булмады аңа. Бөкрене кабер генә төзәтә дигәннәре хактыр.

Идәндә ялтырап яткан ак туфлиләргә карап тын калган хатынның авыр уйларын юмакчы булып, тәрәзә артында көзге яңгыр бәргәләнә. Тәрәз каккан яңгырга кушылып, көз ишегән шакып алмалар коела. Кай арада көзләр җиткән соң? Гомер дигәнең дә яз белән көз арасы кебек кенә үткән дә киткән. Җырласаң да үтә, еласаң да үтә икән лә ул... Көз – җимешләрне җыяр чак. Халидә белән Харисның алма төсле кызлары да үсеп буй җиткергән. Ләйсәннәре менә үз тормышын корырга җыена инде. Туйда киярене ап-ак туфлиләр алып кайткан. Бәрәкәте белән булсын. Кеше бәхетен таптап үтәргә, сикәлтәле гомер юлларыннан кеше рәнҗеше җыеп атларга язмасын берүк ак туфлиләр кигән яшь кызларга. Халидә, эченнән генә шулай якты теләкләр тели-тели, туфлиләрне бик кадерләп, сак кына күкрәгенә кысты.

И-и, әнкәй...



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

Әнәйләр безнең... белмим инде хәтта... Без аларны кемебез дип кенә атап бетермәдек икән. Ул аларга мактау яудырулар, ул метафоралар... Ну, чагыштырулар инде... Кояш кебек тә, тагын әллә нәрсәләр кебек... Оҗмах – әнкәйләрнең аяк астында, диюләр. Берсе дә калмаган...

Әнкәйләрнең дә төрлесе бар.

Менә мин үземнеке белән җиңелчә генә талашып яшәп ятам. Бар инде ул «әнием», «әтием» дип кенә сөйләшүчеләр. Шундыйлардан гомер буе көнләштем. Тик әни белән минем арада андый сөйләшү булмады. Менә кыш инде, мәсәлән. Элек без, елганы чистартып, хоккей уйный идек. Уенның иң кызган чагында гына, бөтен дөньяңны ташлап, инәй янына фермага китеп барасың. Сине колач җәеп: «И-и, балакаем, килдеңмени. Рәхмәт инде, шулай ярдәм итеп йөргәнеңә!» – дип каршыламыйлар. Болай дип әйтәләр:

– Тагын соңга калып килдең! Бар, әнә теге яктан башла.

Синең теге якны яратмаганыңны белеп торалар инде. Анда – таналар. Алар тибеп тә очырырга мөмкин, өстәвенә, сыртларына кадәр пычранып яталар. Сыер дигән дөньяның яши белми торган кавеме инде. Вәт син шуларның астын алып, өстен чистартып чыгарга тиеш. Чистартасың инде... Башта тарткыч белән асларын алып чыгасың, аннан кыргыч белән сыерларны тазартасың. Начальство килеп кергәндә, синең сыерлар ялтырап торырга тиеш. Синең сыер түгел инде, әнкәңнең сыерлары. Әнкәңнеке дә түгел инде, колхозныкы. Ялтырап, матур булып торса, ул сыерларны мактыйлар инде. Әнкәңне дә, сине дә мактамыйлар. Сыерларны мактыйлар. «Вәт, әйбәт сыерлар!» – диләр. Пычракка батып ятсалар, начальство әнкәңне сүгә. Әнкәң башын иеп тыңлап тора да, начальниклар киткәч сине тиргәргә тотына: «Вәт, әйттем бит сиңа шулай-шулай ит дип!»

И-и, эш аның белән генә бетми әле. Сава башлыйсың хәзер. Теге башбирмәс сыерларның берсе сине чиләгеңнием белән тибеп очыра. Тирес тарттыргычка барып төшәсең. Чиләгеңнең буш икәнен сиздермәскә тырышып сикереп торасың... «И-и, балакаем, берәр җиреңне авыртмадымы?» – диюче юк.

– Имчәге ярылган аның дип әйттем бит сиңа! Нәрсә дип вазелин җәллисең? Бар, әнә теге сыерга күч, монысын үзем савармын... – диләр. Һәм өстәп куялар: – Ярый, кулың да арыгандыр инде. Сөт кенә илт, лутшы...

Сөт илтү ул берни аңламаган кешегә генә рәхәт тоела. Син унбиш литрлы ике чиләк күтәреп үрге яктагы сыер абзарына барырга тиеш. Юлы баткак, кайчагында итегеңне дә тартып чыгара алмыйсың. Язлы-көзле инде монысы. Кыш булса йә көрт баса, йә тайгакка әйләнә. Сөтең түгелә инде, кайчагында ярты чиләккә кала. Тик син дә ахмак малай түгел, якындагы аулаграк сыер улагына басасың да су өстәп тутырып куясың. Тик кайвакыт тикшерүгә эләгәсең: сөтеңнең мае да, куелыгы да туры килми. Әнкәңне тиргиләр. Ул сине әрли: «Аһ, иманы качкан малай!.. Тагын су куштыңмыни?»

Имансыз булсаң да, син бөтенләй үк башсыз түгел бит инде. Син бит бишенче сыйныфта физика укыган кеше. Вәт! Су кушасың да сөтеңә, тоз чәпәп куясың. Аны тикшереп утыручылар синнән дә һушлырак түгел – өч класс белемнәре белән начальник булып йөрүчеләр. Баш ваталар хәзер: сөтнең куелыгы яхшы, ә майлылыгы чамалы. Су кушылган дип әйтеп булмый...

Ул чакларда ярыш бар иде бит. Менә шул ысул белән әнине беренче урынга чыгардым. Ниндидер ситсы бүләк иттеләр, ул күлмәк тектереп киде. Үзем күлмәк алып биргәндәй горурланып йөрдем. Соңыннан әйткәч, бик ачуланды: «Әй, каһәр суккан малай, шунда да адәм булмагансың инде...»

Ул мине әле дә гел тиргәп кенә тора. Ниндидер җырны тыңлый да: «Җыр язам дип шуны язып утырдыңмы инде?» – ди.

Кайчагында китапларны тәнкыйтьли: «Шушы яшеңә җитеп бер юньле китап чыгара алмадың инде...»

– Әни, әйбәт бит алар, – дип акланган булам.

Ул үзенекен итә: «Хәрефләре кечкенә. Укырга күз күрми».

Ул миннән бервакытта да канәгать түгел. Кайвакыт үпкәләп тә куйган булам: «Яратмыйсың син мине. Яраткан әни алай булмый ул...»

Ә ул үпкәләми.

– И-и, бала... – дип елмая. – Малайлыктан чыга белмәдең инде...

Әле менә уйлап утырам... Йөзеңдә малайлар елмаюы балкый икән, димәк, син – бәхетле. Әнкәйләр исән вакытта без малайлыктан чыга алмыйбыздыр инде ул. Әнкәйләр исән вакытта без бәхетле. Нинди сүзләр әйтешүең түгел, ә ниндидер сүзләр әйтешүең мөһим. Әнкәйләр янында без дә, сүз дә бәләкәй. И-и, әнкәй...



Фото: Анна Арахамия

ЙОЛДЫЗ



Эльмира
ЗАКИРОВА

Космос эрасына кучкән бер чорда, Гагарин елмаюыннан бөтен Җир шары яктырып киткән апрельдә дөньяга аваз салган ул. Һәм Йолдыз иseme кушылган бу кызга, мөгаен, әдәбиятта, тормышта йолдыз булып балку, бар дөньяны яктырту вәкаләте тапшырылгандыр. Йолдызның беренче тапкыр Казанга килгән көнен хәтерлим. Шигырьләр язучы бер кыз бала, таләпчән-кырыс укытучы әнисенә ияреп, «Ялкын» редакциясенә килеп керде. «Мин Җамалетдинова Йолдыз булам. Буа районы Яңа Тинчәле мәктәбен «биш»кә генә тәмамладым. Университетка укырга керергә юллама алырга кердем сезгә», – ди. Үзе оялчан, шул ук вакытта үз дигәнен итә торган мишәр үҗәтлеге дә бар иде анда. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә соңгы елын укыганда «Ялкын»га эшкә килде. Котлауларны шигырьләтә генә яза, командировкаларда бала-чагалар белән дуслашып кайта, шуларга бик якын апалары булып хатлар яза... «Яшь ленинчы» газетасында эшли башлаганда инде ул чын балалар журналисты булып өлгерә. Танылган балалар шагыйре булып китә. Аны татарның Агния Бартосы дип йөртә башлыйлар. Йолдыз булмаган мәктәп Татарстанда юктыр ул! Кызлар-малайларның кумиры, әти-әниләрнең акыллы киңәшчесе. Режиссер булсам, аның турында «Йолдыз» исемле фильм төшерер идем. Йолдыз исемле гап-гади Җир кызының йолдызлар югарылыгына күтәрелүе турында булыр иде ул. Күкләрдән аңа талант та, олы йөрәк тә, шәфкатьлелек тә, ихласлык та бирелгән. Әнисе белән генә үскән хыялый моңсу кызның бар тормышын колачлар иде ул кино. Әнә ул – студент, Казанны яулый. Әнә Йолдыз – журналист, әле редакциядә, әле мәктәпләрдә, әле командировкада... Кызыклы маҗаралар да, көлкеле хәлләр дә, күзләргә яшьләр килерлек вакыйгалар да җитәрлек тормышында. Менә ул, билеты булмагач, самолетта бер егетнең алдына утырып оча. Ә ул егет кызның насыйбы булып чыга!.. Бер-бер артлы малайлар туа дөньяга!.. Әнә балалар йортыннан бер кызны, бишенче балалары итеп, үзләренә сыендыралар... Менә ул балалар белән шыгрым тулы залда антенналы бәрәңгеләр, колаклы коймаклар, татарча өйрәтә торган этләр турында шигырьләрен укый. Андый китаплары дистәдән артык Йолдыз Шәрапованың! Ул – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, язучыларның Абдулла Алиш премиясе лауреаты, журналистларның «Бәллүр каләм» конкурсы лауреаты, күренекле балалар шагыйре. Ул һаман юлда, очышта. Ә Йолдыз ШӘРАПОВА сөйләгәннәр кинокадрлар кебек күз алдыннан йөгереп уза.

Хәтта: «Авырганда больницага ук алып баралар синең китапларны», – дип әйткәннәре бар.

Кемдер такмак, кемдер шакмак дияр, бәлки...

Шигырьләремне әйтәм. Мин әллә нинди зур шагыйрь дә түгел инде. Ләкин халыкның яратуын тоям. Уйлап-уйлап тордым да... Мөгаен, әйбәт, ихлас оеткы салынган-гадыр аларга, һәм алар бөтенесе балаларны әйбәт итәсе килүдән туган. Әни шигырьләре, ягъни мәсәлән. Әни-шагыйрә дип, мине Шәүкәт абый Галиев әдәбиятка алып керде. Роберт абый Миңнуллин белән бер редакциядә эшләдек. Ул мине сеңелкәше кебек якын итте. Тырышканымны да күрде. Без бер телдә – шигырь телендә сөйләшә идек. Ул да миңа хәер-фатихасын бирде. Бер елны Түбән Новгородта Россия халыкларының Бөтенроссия фестиваленә барган идем. Анда 150 телдә шигырь укыдылар. Якуты да, кырым татары да, карачае да, бөтенләй дүрт-биш кенә калган милләтләр дә бар иде анда. Мин дә чыгыш ясадым. Шигырьләремне шунда «Мамины стихи» дип атадылар. Әниләрнең фикере белән туры килгәндер инде ул шигырьләр. Әти-әнинең бит баласын бик тәртипле, акыллы итеп үстерәсе килә! Минем дә бөтен теләгем шул иде! Тезелеп тора очрашулары. «Йолдыз апа, киләсезме безгә? Көтәбез!» – дип чакыралар. Ничек «юк» дип әйтим! Кире кага белмим мин. Чит өлкәләргә дә чыгып китәм. Пенза, Пермь, Ульяновскилар... Берчак Чабаксарда зу-у-ур итеп минем кичәмне үткәрделәр. Таныш чуаш теле укытучысы бөтен шигырьләремне үз телләренә тәрҗемә итеп, балаларны кызыксындырып, матур бәйрәм оештырды. Ул балалар, чыпы-чыпы килеп, шигырьләремне чуаш телендә сөйләделәр. Һәр балага Грамоталар тапшырып кайтып киттем. Мин очраша торган балаларга әйбәт энергетика салынган ул... «Сезнең китапны мендәр астына салып йоклый кызым», «Шигырьләрегезне концертларда ятлап сөйлиләр», – диләр. Хроник авырулы бер бала һәр елны дәваланырга кергәндә «Колаклы коймаклар»ны үзе белән ала икән. «Мин шул китап белән терелəм», – ди икән әнисенә. Безнең күршедә бер дәү әти белән дәү әни яши. «Тәмле сүзләр» китабымны аларга да кертеп бүләк иттем. Берничә көннән әйтәләр: көлдек тә, еладык та, диләр. Оныклары татарча сөйләшми икән. Әби белән бабай менә шуларны туган телебездә сөйләшергә өйрәтмәкче хәзер! Җаннар җанга барып җитә шулай.

Мин начарлык эшләргә сәләтле түгел. Дөрес, кайберәүләр аны күрмәскә тырыша. Андыйлар да булды. Миннән начарлык эзләргә теләүчеләр, мине каралтырга тырышучылар... Ләкин һәркем күңеле белән үлчи бит аны. Һәрнәрсәдән яктылык, яхшылык күрергә тырышканмындыр... «Казан утлары»на бер хикәя биргән идем. Бигрәк наив дигәннәр. Соң, аны бит балалар язучысы язган! Мин бит үзгәрә алмыйм!

Әнием Миңненур университетның мехматына укырга кергән булган. Укытучылар җитмәгәч, аларны мәктәпләргә җибәргәннәр. Яңа Тинчәледә ул Мәкбүлә әбигә фатирга урнашкан. Әти белән озак яшәмәгәннәр, миңа бер ай да 13 көн булганда аерылышканнар. Үсә төшкәч, 43 көнлек бала нинди була икән дип, бишектәге сабыйларга карый идем. Үз балаларымны, 43 көнлек булгач, фотога төшерә башладым. Әни, лампа куыгы чаклы гына баласын күтәреп, әби фатирына кире кайткан. Ул – тол әби, ире сугыштан әйләнеп кайтмаган. Бердәнбер кызы 2 яшендә вафат булган. Менә шул фатир хуҗабыз Мәкбүлә әби Пушкинның Арина Родионовнасы кебек булды минем өчен. Күп нәрсә алдым аннан. Ул – халыкның үзе. Балачак бит ул – киптергеч: аның мәкаль-әйтемнәр белән сөйләшүләре әле дә хәтердә.

Миндә «экспромтом мышление». Ике уйлап тормыйм, яшен тизлегендә хәл итәм дә атам. Тәвәккәллектер ул, бәлки? Лампочка кабынган кебек баш миендә, яктылык гөлт итеп ялтырап китә. Шигырьләр дә шулай туа. «Эшләдем бер яхшылык, дөнья китте яктырып...» – дигән бер шигырем дә бар минем. Юктан гына чыккан сүзләр түгел инде болар: чын-чынлап офыклар киңәя.

Французларның бер мәкале бик ошый: «Караңгылыкны сүгеп яшәгәнче, бер шырпы булса да кабыз!» Үземне шырпы итеп хис итәм. Начарлык эшләргә куркам. Елмаеп, бүләк өләшеп, китап таратып яшәп ятыш.

Казан–Сарман арасы

«Яшь ленинчы» газетасында эшләп йөргән чагым. Ел башыннан мине командировкага җибәрделәр. Әллә ничек сәер башланды ул: бер сәгать алдан ук килдем автовокзалга. Юл шактый озын, Сарман бик ерак икән. Пионерлар йорты директоры Венера мине авылларга алып барды, мәктәпләрдә булдык. Ә кайтканда Ләке белән Александровка арасын сөйләшә-сөйләшә җәяү атладык. Егетләр турында да сүз булмый калмады... «Комсомол райкомында Сирин исемле бер шәп егет бар, бөтен нәрсәне булдыра, үзе артык тыйнак, бер кызга да карамый», – дип, Венера ниндидер егет турында сөйләп бара. «Мактама инде шулкадәр! Кайчан күрәм мин аны!» – дип, адымнарны кызулыйм. Миңа бит Казанга очасы әле! Ләкин бер сәгатькә соңга калдык: расписаниесе үзгәреп, Казанга очып киткән иде инде самолёт. Икенче көнне аэропортка килсәк, шул Сирин басып тора! Аның билеты бар, минеке – юк. Ул комсомолда эшләгәч, аларга бронь калдырыла. Хәлне аңлаттык. Ул минем «Пресса» документымны алып кассага китте. «Билетлар юк. Алай да бер урын бар... Алдыңа утыртып очсаң», – дигәннәр. Шулай итеп, Сириннең алдына утырып очтым Казанга. Без шулай таныштык. Ул Казанга эш белән килгән чакларында күрешкәлибез. Миңа ошый да үзе. Тик ул миңа егылып китмәде алай. Күзлекле, артык тыйнак, гап-гади кыз нигә инде бу егеткә? Ә бер килүендә ул үзләре ягына командировкага чакырды. Җаең булса, әйдә, диде. Мин ул яктан җитез: алдын-артын уйлап тормыйм. Азнакай белән Сарманга баруны хәл итеп тә

Хәйриячелек белән шөгыльләнгән кешеләрнең балалары да башкаларны кайгыртырга җан ата.

куйдым. Сирин шунда әти-әнисе янына Җәлилгә дә кереп чыгарга чакырды. Ә инде өйләренә кайтып кергәч: «Ошатсагыз да, ошатмасагыз да, шушы кызга өйләнәм!» – дип шаккаттырды. Минем өчен бу көтелмәгән яңалык булды! Барысы да очраклылыктан башланды бит. Бөтенесе закончалыкка буйсынган.

Соңрак кайнанам: «Бу киленне ничек инде яратмыйсың! Ул бит минем бер улымны дүрт итте!» – диде.

Балалар үстермәсәң, алар өчен язып булмый

Беренче улыбызга Сәйдәш дип исем куштык. Нәрсә кигәнемә кадәр бүгенгедәй хәтеремдә. Мин ул көнне бантиклы ал кофтадан идем. Авырым беленми дә әле. 7 март көнне хатын-кызлар бәйрәменә багышланган концертка чакырдылар. Алып баручы бик аһәңле тавыш белән җаннарга үтәрлек итеп: «Сәйдәш музыкасы!» дип, җырны игълан итте. Болай да нечкәргән күңелем әллә нишләп китте. Карындагы балам – малай, һәм ул, һичшиксез, Сәйдәш исемле иде минем өчен! Сирин ул вакытта әле Сарман районында хуҗалык рәисе урынбасары булып эшләп йөри. Аңа язып салдым бу яңалыкны. Улыбыз Шәрапов Сәйдәш Сиринович булачак, дидем. «Сәйдәш ничек? Һавага алып чык Сәйдәшне!» – дип яза башлады Сирин дә. Икенче улыбызга Ядкарь исемен әнием кушты. Арабыздан китәсен сизенеп, шул исемне ядкарь итеп калдырасы килгән инде аның... Өченчесе – Айнур. Исемен Сирин тапты. Улыбыз туганда айның тулган вакыты, яп-якты төн иде! «Ул яктылык минем Айнурымнан, Айнур була улым», – диде. Дүртенчесен үзем Газиз дип атадым. Чөнки өч абыйсы бар инде. Бу бала, минем кирәгем дә булмаган, кыз көткәннәр инде, дип уйламасын өчен, сабыемны беренче тапкыр кулыма алу белән: «Газиз улым минем», – дип, кочаклап күкрәгемә кыстым. Ул инде безнең йөрәк даруы, минем корвалолым булды. Әни үлгәндә аны кочакладым да еладым, кочакладым да еладым. Әдилә белән ун гына көн аермалары. Газиз 7 июньдә туды, Әдиләнең туган көне – 17 июнь.

2007 елда Әдиләнең документларын күргәч, каз тәннәре чыкты минем. Тегермәнлектәге «Акчарлак» приютыннан алып кайттык аны. Андагы ятим балалар турында мин «Канатсыз «акчарлаклар» дип язып та чыктым. Ул балага игътибар итү үзе бер тарих. Миңа инде 45 яшь. Бүтән бала табып булмый бит инде. Тапсаң да шул – тагын малай булачак! Бабамнарның җиде малай булган әнә. Нәселдә – җиде малай! Ә мин һаман кыз турында хыялланам. Бер кыз алырга кызыгып йөрим. Мин үземә юбилейга бер бүләк ясыйм дип әйттем дә әле. Авылга кайткач, укытучылар: «Бер кызны детдомнан гына алабыз инде, диде әниең», – дип әйтмәсеннәрме! Димәк, әнием үлгәнче үк фатихасын биргән булган инде! Документлар әзерләп йөрдек. 2007 ел Хәйриячелек елы дип игълан ителеп, ятим балаларга зур игътибар күрсәтелгән иде ул чакта. «Тегермәнлек приютында бер кыз бар. Әтисе үлгән, әнисеннән ана хокукы алынган», – дип, Земфира Гыйльметдинова әйтте миңа. Ул ятим балалар белән эшли иде. Бу кызны берничә тапкыр алып, кире китергән булганнар инде. Берсендә гаиләдәге балалар белән тыныша алмаган, икенчесендә никтер кире уйлаганнар... Безгә насыйп булган – шуңа! Аннары баланы уллыкка-кызлыкка алу үзәгенә шалтыраттык. Компьютерга фотосы да куелган иде. Карадык та, «И-и миңа охшаган бит бу! Авызы минеке кебек зур: минем кыз бу! – дидем шундук. *(Көлә.)* – Әйдә барып карыйбыз», – дим Сиринга. «Хәзер, барып карап йөрдең ди! Ул бит товар түгел сиңа! Барабыз да алып кайтабыз!» – дип, җыена да башлады Сиринем. Күчтәнәч, бүләкләр төядек тә, Газизне үзебез белән алдык та, киттек Тегермәнлеккә. 1 июнь – Балаларны яклау көне иде ул. Кара-чутыр матур бер кызны алып килделәр. Алдыма утырттым да: «И кызым, син монда булгансың икән! Ә мин әллә кайлардан эзләдем», – дидем, үземнең күзләремнән яшьләр акты да төште! Битемне нәни учлары белән и сыйпый инде!.. Юлда кайтканда ук «әни» дип дәште! Абыйлары йөгереп төшеп, курчакны күтәргәндәй алып менеп киттеләр. Шундый матур иде ул! Бәләкәй чагында гел күтәреп кенә йөрделәр инде. Чын исеме Мария булган, бер гаилә үзенә алгач, анда Әдилә дип йөртә башлаганнар. Безнең өчен дә шул исемдә калды ул. «Балага көн дә исем кушмыйлар. Әдилә кала», – дидем. Газиз белән Әдилә игезәкләр кебек үстеләр: бер бакчага йөрделәр, бер класста укыдылар. Аллага шөкер, без бик рәхмәтле язмышка! Мәктәпне ул үз фамилиясе белән укып чыкты. Аннары, паспорт алгач, Шәрапова Әдилә Сирин кызы дип яздырды. ЗАГС ишегеннән чыкканда: «Мине хәзер алар белән бернәрсә дә бәйләп тормый!» – диде. «Кызым, фамилияң бик билгеле хәзер, аны каралтмас өчен тырышырга туры килә! – дип әйттем шунда. Быел Газизебез белән Әдиләбезгә 20 яшь тула!

Мине танырга теләмәүчеләр дә булды. Дан-дәрәҗә өчен тәрбиягә бала алды дип сөйләп йөрүчеләр дә... Сез дә тәрбиягә бала алыгыз. Ятим балалар белән дөнья тулган, дим андыйларга. Ләкин ничек тәрбиялисең бит!

Беркөн Газиз елап шалтырата: «Әнием, монда өч эт баласы. Өшегәннәр, елыйлар, – ди. – Әни, аларны алып кайтыйм инде өйгә!» – дип өзгәләнә. Ничек «юк!» дим инде! Мин аларга беркайчан да юк димәдем. Менә шулай җәлләп, өч көчек алып кайттылар.

Икенче көнне Айнур шалтырата. Бензоколонкада тора идем, бер малай килде, ди. Ятим бала икән. Каяндыр эшеннән җибәргәннәр. Әти, эшкә ал әле шуны, ди. Сирин – «Татарстан ашлык технологияләре» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры – тәки эшкә алды ул егетне.

Солдат әнисе дә булырга туры килде. Ядкарь армиядә хезмәт итеп кайтты. Ул Энергетика университетының экология факультетын тәмамлады, Гранд Отельдә баш инженер. Айнур авыл хуҗалыгы академиясендә, механика факультетында укыды. Белмәгән эше юк: эткә оя да ясап куйды, эретеп ябыштыруларны да үзе башкара. Бездән аермалы буларак, ул – җир кешесе. Җитмәсә, лидер үзе. Газиз халыкара сервис колледжында белем ала, повар-кондитер булачак. Кечкенә чагында ук: «Бу таба яндырмый, монысының капкачы бар», – дип, кибеттә таба, кәстрүлләр карап йөри иде. Ул кыз буласы булгандыр инде, Әдиләне аласы булганга гына малай булып тугандыр, дим. 1 яшеннән, урындыкка басып, раковинада савыт-саба юа иде, 5 яшеннән идән юды. Аш-суга осталык – аның таланты ул. Әдилә юридик колледжны тәмамлады. Тренажер залында администратор булып эшли. Үз дәрәҗәсен бик белә, үзен бик ярата.

Бүген кайнана да, килен дә инде мин, Аллага шөкер! Айнурның – Регинасы, Ядкарьнең Айсылуы бар хәзер. Оныклар көтәбез. Кайнанам да килгәч, табын артында унау утырабыз: ишле без. Арабыздан киткәненә шактый булса да, әнием барыбер күрәдер, сөенәдер тормышыма, дим. Алар безнең арада йөриләр, үзләрен генә күрмибез, диләр бит.

Әти белән көрәшеп хушлаштым

Әти белән әни икесе ике кеше булган. Туры килә алмаганнар. Әти – күк кешесе, романтик, хыялый булган. Район газетасына да язып торган. Шигырьләр иҗат иткән. Исеме дә Әдип бит. Гармунда уйнаган. Сәйдәш тә аңа охшагандыр: гармунда, курайда, гитарада уйный. Ә әни ул җир кешесе: аныкы тоткан да йолыккан. Кискен, таләпчән, коры. Генерал шикелле.

Әтинең тагын ике кызы бар: Айгөл белән Лилия. Аралашып торабыз. Лилия Ульяновск өлкәсендә яши. «Йолдыз апам» дип яза миңа. Аларның бер гаебе дә юк. Минеке шикелле үк. Аларны гафу да итәм, әмма минем балачагым гафу итми бу хәлне. Алар әтиле үсте, мин – әтисез! Аңлатып булмый аны! Бер елны май аенда ике малайны алып Тинчәлегә очрашуга кайткан идем. Әти белән очраштырыгыз әле безне, дидем укытучыларга. Мин бит элегрәк башка кешеләрне дә, минем әти түгел микән бу, дип йөри идем. Бөтенләй аралашкан булмады. Мин – әтисез бала! Керсеннәр, дигәннәр. Авыл мәчетендә күрештек без. Ул анда мөәзин иде. Башта балалар керде. Бергәләп намаз укыганнар. Ядкарь азан әйтә безнең. Күчтәнәчләр, бүләкләр алып кайткан идем. «Башларыннан сыйпа. Алар бабайсыз үстеләр», – дидем. Шаккаттым: ул әни ягыннан бөтен туганнарны хәтерли, берәм-берәм сорап чыкты. Казанга кайтканда юл буе шул хакта сөйләштек. Малайлар: «Бабай калтырый иде», – диләр. Елагандыр. «Менә, балакайларым, картлыгында калтырамас өчен яшьлегегеңдә хаталарны азрак эшләргә кирәк», – дидем аларга. Ул алар өчен тормыш дәресе булды. Без бәхилләштек. Мин аны гафу иттем. Чөнки әгәр минем язмышым шундый булмаса, мин – мин булмый идем. Шулай язган, димәк. Шулай кирәк булган. Әнигә тотынган бер кулым, ә әтигә тотынасы кулыма мин каләм алдым. Мин хәзер бер әйбернең дә юктан гына бар булмаганын беләм. Бернәрсә дә юктан гына булмый. Ул нәрсәнеңдер нәтиҗәсе, нәрсәнеңдер сигналы, ниндидер билгесе. Игътибарлы гына булырга кирәк. Хәтта иң начар дигән әйбер дә сине нәрсәдәндер саклый. Ходай шулай кушкан икән, димәк, бу – хәерлегә. Язмышка каршы барып булмый, аңа каршы барырга кирәкми дә. Күкләр безгә караганда акыллырак.

ЙОЛДЫЗНЫҢ БЛОКНОТТА КАЛГАН КАЙБЕР ФИКЕРЛӘРЕ

■ **Энергетикага бик ышанам.** Шигырьгә дә, эшләгән бөтен эшкә дә әйбәт энергия салырга тырышам. Начар кешеләр янында йөрмим дә. Нигә әле мин аларның начар энергиясен өйгә алып кайтырга тиеш?!

■ **Дөньяны, кешеләрне яратып яшим.** «Синдә бар кеше дә әйбәт инде!» – ди торган иде әни. Менә шул ал күзлек кию һәрбер кешене матур итеп күрсәткәндер инде ул. Тик ул күзлекләр күптән ватылды инде. Аллага шөкер, үзебез исән-сау калдык.

■ **Мин – пружина, мине эткән саен, ныграк сикерәм.** (*Көлә.*) Кысылган саен, потенциаль энергия арта.

■ **Авырлык кешене көчле итә.** Башыннан сыйпап, борынын сөртеп үстергән кешеләрдән бер дә әлләкемнәр чыкмый.

■ **Шигырь язмаган кешене табибка күрсәтергә кирәк.**

■ **Һәрбер эштән иҗат табарга була.** Бәйләм бәйләгәндә дә, чигү чиккәндә дә, хәтта идән юганда да...

■ **Коронавирус белән авырганда, мин ул чир белән договор төзедем.** Нишләп йөрисең? Бар, кайтып кит, йөрмә минем янда! Минем балаларым бар», – дидем. Аллага шөкер, балаларым терелтте. Авырганда кешеләрнең сине тоюы, синең кирәклекне аңлавы бик мөһим!

■ **Бертөрле уйлап, икенче төрле эшләп, өченче төрле сөйләп йөргән кешеләрне җенем сөйми.**

■ **Яхшылык эшләсәм, медицина анализларым да әйбәтләнә.** Кызыл кан тәнчекләре – эритроцитлар күп миндә. 200 гемоглобин белән йөрим. Кайсыгызга кирәк, бүлеп бирәм, миндә күп, дим. (*Көлә.*) Аллаһы Тәгалә миңа күп итеп биргән өләшергә.

■ **Балалар ялганны кабул итми.**

■ **Балаларны яклап, аларны саклап язам.** Бүгенге көндә «Шәһри Казан»ның «Язмыш» газетасында шундый мәйдан бирделәр.

■ **Бу тормышта бернәрсә дә тиктән генә булмый.** Паровоздан алда чапкан да бар. Ләкин күкләрнең үз канцеляриясе. Югарыдагы көчләр ничек хәл итсә, шулай була. Мин ышанам шуңа. Дингә генә түгел, Галәмгә ышанам! Без галәмнең бер бөртеге – бер тузаны гына!

■ **Ябык конкурсларны яратам.** Кемнең кем икәнен белмичә генә, иҗатына карап кына бәя бирәләр.

■ **Мин ничек бар – шундый.** Бизәнмим дә, булганы белән. Эчке дөньяң матур булсын!



ТОРМЫШНЫ ҮЗГӘРТКӘН БЕР КӨН

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА

1961 елның 12 апреле. Кешелек тарихында беренче мәртәбә космик корабльдә Җир тирәли әйләнеп чыккан Юрий Гагарин 10 сәгать 55 минутта Саратов өлкәсе Смеловка авылы янына – Шевченко исемендәге колхозның сөрелгән кырына төшә. Үзенең «Дорога в космос» китабында Җиргә кайтуын ул болай дип тасвирлый: «Мин, ниһаять, җиргә төшәргә әзерләндем. Ун мең километр... тугыз... сигез... җиде... Аста тасма булып сузылып Идел елгасы күренде. Ахыры яхшы тәмамланган романнарда гына шулай була-дыр: Галәмнән әйләнеп кайтуым беренче тапкыр очкычта күккә күтәрелгән урынга туры килде.
Аяк астымда каты җир тоюга, чуар бозау янында кызы белән басып торган бер хатын-кызны күреп алдым – алар икесе дә куркып һәм кызыксынып мине күзәтәләр иде. Җиргә әйләнеп кайткач очраткан беренче кешеләрем алар – урман каравылчысы хатыны Анна Акимовна Тахтарова һәм аның оныгы Рита булды».

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахиим!» Җирдә Гагаринга карап әйтелгән беренче сүзләр шушы булды.

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахиим…

Үзләренә таба атлаган сәер затка карап, ул чакта Әнихәят апа бисмилласын укый башлый. Әйе, бернинди дә Анна түгел, ә Әнихәят Аким кызы була ул, янындагы оныгының исеме дә Рита түгел, чынлыкта – Румия. Кызчыкка ул вакытта әле алты да тулмаган. Кечкенә булуына карамастан, ул бу көнне мәңге онытылмаслык итеп истә калдыра, һәм әлеге якты хатирәләрен гомере буе үзенең меңнәрчә чыгышларында, әңгәмәләрендә яңарта. Әйе, аның бөтен тормышын үзгәрткән көн була ул… Без аның белән шушы язманы әзерләгәндә очрашырга тиеш идек. Кызганыч, узган елның җәендә, 30 июнь көнне Румия ханым Нурсканова арабыздан китте. Аның ягымлы тавышы, мөлаем йөзе, игелекле күңеле, хатирәләре… барысы да видеоязмаларда гына сакланып калды. Шулардан өзек:

«…Ул көн бик гадәти генә башланып китте. Әбиемә ияреп бакчага чыктым һәм аңа бәрәңге утыртырга булыша башладым. Ул җир казый, ә мин әбием ясаган чокырларга бәрәңге салам… Көн гаҗәеп җылы һәм кояшлы иде. Бераздан эштән туйдым – бәрәңге утырту мине ялыктырды. Уйныйсым килә… Кечкенә идем бит әле. Тирә-юньдә – кыр гына, бүтән карар нәрсә булмагач, башымны күккә күтәрдем. Һәм кинәт җиргә таба кызыл төстәге ике әйбер очып төшүен күреп алдым. Шунда ук әбиемә: «Кара әле, кара, әбием, күктән ике кызыл баш төшә!» – дидем. Ул чакта мин әле бары тик татарча гына сөйләшә идем. Ләкин әбиемнең исе китмәде, мине уйлап чыгара дип белде, ахрысы. Ачуланып диярлек: «Күккә карап басып торма, бәрәңгеңне утырт!» – диде. Әмма минем теге шарлардан аерыласым килми иде. Алар белән бераз уйнап та алдым: кыр буйлап йөгерсәм, шарлар да артымнан бара кебек; туктап торсам, алар да туктый… Бер мизгелдә аларны мин хәрәкәткә китерәм төсле тоелды хәтта. Тагын шунысы да истә: көчле шартлау тавышы да ишетелде ул көнне. Күкнең яртысы кызыл төскә кереп, яктырып та китте… Әби чын-чынлап ачуланмасын дип, тагын аңа бәрәңге утыртыша башладым. Теге шарларны беразга онытып та тордым. Исемә төшеп, әйләнеп карасам: кырда бик күп баулар ята. Һәм шулар арасыннан җирдән кызыл-сары төстәге нидер күтәрелә… Менә ул торып басты һәм кыр буйлап безгә таба килә башлады. Кызыл-сары киемле нindидер бер нәрсә, куркыныч, кем икәне аңыма сыймаслык зат! «Күктә очканда карарга теләмәгән идең, менә хәзер кара инде! Ул үзе безгә таба килә!» – дим куркып әбиемә. Аякларын киң итеп куеп, аяккулларын сәер хәрәкәтләндереп, авыш-түешрәк адымнар белән безгә таба атлап килүче затны күргәч, әбием кулымнан кысып тотты да, догаларын укый башлады: «Бисмилләһир-рахмәнир-рахиим…» Әйе, әбием ул чакта Юрий Гагаринга туп-туры итеп карады һәм догаларын укырга кереште. Әбием догаларын пышылдый башлагач, күңелгә шом керде. Миңа ул аларны куркыныч булган очракта гына укый кебек тоела иде… Аннан әбием мине кулымнан ычкындырмыйча гына кире борылды, без өйгә таба йөгерә башладык. Бу урында шуны әйтергә кирәк: әби белән бабай өендә телевизор да, радиоалгыч та юк, газета-журналлар килми, хәтта ут та кермәгән иде – кичләрен керосин лампасы кабызабыз. Смеловка авылы бездән шактый ерак, тирә-юньдә бары тик колхоз кырлары гына… Бабаем Ибраһим белән әбием Әнихәят икәү генә яшиләр, ә мин аларга кунакка кайтарып кына куелган идем. Бабаем ул көнне агач үсентеләрен карарга дип китте. Без дә, бик күпләр кебек үк, бортында кеше булган беренче космик корабльнең Галәмгә очуы турында ишетмәгән идек, билгеле. Гомумән, илдәге яңалыкларны гел соңрак белә идек.

Юрий Гагаринны күргәч: «Бу – кеше түгел», – дип уйладым. Ул киемнәреннән гомер күрмәгән затка охшаган иде бит. Без йөгереп киткәч, ул нәкъ кеше тавышы белән артыбыздан: «Мамаша, стойте, я свой!» – диде. Мин аның әйткәннәрен ишетүгә, әбиемнең кулыннан тарттым: «Әбием, тукта әле, ул русча сөйләшә. Кешедер, бәлкем?!» – дим. Әбием, йөгергән җирдән туктап, кире борылды, ләкин без артыбыздан килгән ул затка таба бер адым да атламадык – аның яныбызга кадәр килеп җиткәнен көттек. Тавышы тонык булып, кисмәктән чыккан кебек ишетелсә дә, аңардан инде беренче мәлдәге кебек курыкмый идек бугай.

Ниһаять ул безнең янга килеп җитте. Әбием аның үтенече буенча гермошлемын ычкындырырга булышты. Шуннан соң безгә аның йөзе күренде. Бик арыган, ләкин шундый сөйкемле кеше йөзе иде ул. Тавышы да матур, йомшак, бәрхет кебек тавыш, елмаюы да җылы иде. Инде курыкырга бер сәбәп тә калмады. Юрий Алексеевич әбиемнән:

– Как вас зовут? – дип сорады.

– Я Анихаят Акимовна Тахтарова, жена лесника. А это моя внучка, – дип җавап бирде әбием.

Шуннан соң ул миңа карап:

– Ә аның исеме ничек? – диде.

– Румия!

Юрий Гагарин исемемне кабатлап сорады – татарча исемем аңа ят тоелды, ахрысы.

– Рита! Мәктәп өчен русча исеме дә бар аның!

Гагарин соңыннан үзенең барлык интервьюларында да диярлек мине «Рита» дип искә алды – бу тарихка шушы исем белән кереп калдым. Инде сорау бирергә әбиемнең чираты җитте:

– Ә син кем? Кайдан килеп чыктың?

– Мин корабльдә идем… – дип җавап бирә башлаган Гагаринны әбием шунда ук бүлдерде:

– Нинди корабль турында сөйлисең? Безнең бит монда су юк!

Аның сүзләренә ышанып бетмәвен әбием яшермәде дә.

– Мин – күктән… Хәзер сезгә кабинаны күрсәтәм!

Әбием белән алар капсула янына таба киттеләр. Мин дә ияреогә теләгән идем дә, ләкин шул вакыт бозавыбыз утыртырга дип ярган бәрәңгене чиләктән ашый башлады. Моны күргән әбием бозауны куып җибәрергә, бәрәңгене ашатмаска кушты. Шулай итеп мин бәрәңге саклап калдым.

Фотолар: гаилә архивыннан.

Мәктәптә класстан класска йөртеп, тарихи вакыйга турында һәр ел саен кабатлатып сөйләтәләр иде.



Румия Нурсканова очучы-космонавт Алексей Леонов белән.

Әбием соңыннан болай дип сөйләде. Капсула янына барып җиткәч, ул аның төзелеше белән кызыксынган. Мин инде капсуланың макетын бик күп тапкырлар күргән кеше. Шуңа күрә әбиемә аның эчендәге кнопкаларга иелеп, кулы белән күрсәтү, чыннан да, читен булган дип уйлыйм. Беренче космонавттан рөхсәт сорап, читенсенеп тормыйча, капсула-кабина эченә әби кәлүшле аякларын тыккан һәм төртә-төртә күрсәтеп: «Ә бу нинди кнопка? Ә монысы нәрсә өчен кирәк?» – дип сорашырга да өлгергән. Юрий Гагарин әбиемнең сорауларына бик теләп җавап биргән.

Аннан соң ул әбиемнән: «Миңа үзем турында хәбәр итәргә кирәк. Сездә кайда телефон бар?» – дип сораган. Әбием исә: «Смеловка авылында гына телефон бар. Ләкин анда кадәр машина белән барырга кирәк. Машинабыз юк, әмма атыбыз бар. Әгәр дә җигәргә булышсаң, ат белән Смеловкага илтеп куярмын», – дигән. Ә Юрий Алексеевич: «Мин, әлбәттә, ат җигә беләм. Ләкин болай озак булыр, миңа үзем турында тизрәк хәбәр итәргә кирәк», – дигән.

Күктән нидер төшүен күреп калган кешеләр булган икән – безгә таба халык йөгерешә башлады. Мәнә шулчак мин бик курыктым, еладым, чөнки аларның нигә йөгерүләрен аңламадым. Бөтенесе әбием янына килә, хәзер, мөгаен, нидер булыр дип уйладым... Әбиемнәрне кешеләр уратып алды. Бәрәңге саклавымны онытып, мин дә аларга таба йөгердем, халык төркеме арасыннан үтеп, уртага кердем. Карыйм: Гагарин инде җирдә, парашютлар өстендә ята, бар да аңа скафандрын салырга булыша, кулларыннан нидер ычкындыралар... Ә аннан соң вертолет очып килде, тирә-юнь хәрбиләр, машиналар белән тулды...»

Әнихәят апа Тахтаровага ул вакытта 44–45 яшьләр тирәсе була. Галәмне урап кайткан Гагарин өчен Җиргә төшүгә аларны күрү иң бәхетле мизгелләр булган, билгеле. Китабында да Әнихәят Тахтарованы, Румияне күргәч, үзен бик тә бәхетле итеп сизүе, хәтта дулкынлану хисе кичерүе турында яза ул.

«...Ә без барыбер әле моның нинди зур вакыйга булуын аңламаган идек, – дип дәвам итә Румия ханым. – Әти белән әни Энгельс шәһәрендә эшлиләр һәм аена бер тапкыр безнең янга кайтып китәләр иде. Бу хәлләрдән соң өч көн үткәч, алар кайтып төште. Үзләре белән газеталар да алып кайттылар. Фотосурәтләребез урнаштырылган газеталарны күрсәтеп, әти белән әни безгә: «Менә нинди тарихка кердегез! Кемне күрдегез!» – диделәр».

Румиянең әнисе Агильшира белән әтисе Әбдрәшид Кудашовлар гаиләдә өч бала үстергәннәр: Румия, Нурия һәм Шамил. Кызганыч, хәзер инде аларның өчесе дә исән түгелләр. Ул чакларда балалар барысы да әби-бабайларында бик еш кунак булганнар.

Кабат Румия ханымның хатирәләренә мөрәҗәгать итәбез.

«Җир шары тирәли орбиталь очыш ясап кайткан Гагарин нәкъ яныбызга төшкәннән соң, безгә бик күп журналистлар килә башлады. Аларны күрүгә, әбиемнең кан басымы күтәрелә, ул өйдән чыкмаска, алар белән очрашмаска, аралашмаска тырыша. Ә журналистлар сүзләрен: «Без сезгә бүләкләр дә алып килдек», – дип башлыйлар иде. Әбиемнең бүләкләргә исе дә китми. Аларга без – балалар гына сөенә идек. Безнең сөенүләребез хакына гына әбием өйдән чыга да иде инде.

...Үземне гел Рита дип таныштыра идем. Чөнки бу исемне миңа Гагарин бирде бит! Шуңа да ул минем өчен кадерле иде. Өйдә дә, мәктәптә дә: «Миңа Рита дип дәшегез», – дия идем. Без гаиләдә татарча гынә сөйләшә идек. Юрий Гагарин турында бик еш чыгышлар ясарга кирәк булганга күрә әтием белән әнием мине русча яхшы итеп сөйләшергә өйрәттеләр».

Әнихәят апага һәм аның иренә Юрий Гагарин белән тагын бер тапкыр күрешү насыйп булган әле. Беренче космонавт 1962 елда Саратовка килә һәм Әнихәят апага, Румиягә һәм Саратов очучыларына мөрәҗәгать итеп, аудиоязма яздыра: «Ул истәлекле көнне мине Җирдә каршылаган беренче кеше Анна Акимовна Тахтарова булды. Олы рәхмәтләрем сезгә, Анна Акимовна! Оныгыгыз Ритага да сәлам. Котлавыгыз өчен рәхмәт. Хат юлладым, алгансыздыр инде, мөгаен. Ә хәзер, Саратов аэроклубы очучылары һәм курсантлары, сезгә мөрәҗәгать итәм. Инде күп тапкырлар әйткәнем булды: бернәрсә белән дә чагыштырып булмаслык очу халәте шатлыгын сездә – Саратов җирендә татыдым. Мондый вакыйгалар гомерлеккә истә кала. Беренче тапкыр миңа күккә күтәрелергә булышучыларның һәммәсенә тирән рәхмәтләремне җиткерәм». (Индустриаль техникумда укыганда Юрий Гагарин Саратов аэроклубына да йөри башлый һәм 1955 елның июнендә беренче мәртәбә күккә күтәрелә. «Як-18» самолеты хәзер Саратов өлкә музеенда тора.)

1965 елны Юрий Алексеевич Галәмнән әйләнеп кайткач Җиргә төшкән урынын тагын бер мәртәбә барып күрергә ниятли һәм Смеловкага килә. Бу хакта Румия ханымның ире Амангали Кайрадинович миңа менә ниләр сөйләде: «Җитәкчеләр Әнихәят апага очрашу алдыннан чәй әзерләргә кушканнар, табынга куярга бөтен нәрсәне алдан китергәннәр. Юрий Алексеевич алар белән утырып чәй

эчкән. Аннары Ибраһим абыйны якын итеп кочаклаган, Бөек Ватан сугышы ветераны буларак, аңа җылы рәхмәтләрен әйткән. Ибраһим бабай каһарман кеше иде. Харьков, Ростов янындагы каты сугышларда катнашкан, өч тапкыр яраланган, әмма хәле бераз яхшыруга, кабат фронтка, алгы сызыкка киткән. Муенында, терсәгендә һәм уң тезендә үлгәнче өч кыйпылчык йөртте.

Әнихәят апага Юрий Гагарин алсу төстәге кофта бүләк итә. Мин аны күрмәдем инде, киеп туздырган булгандыр. Ә менә Румиягә бүләк иткән портфельне күрдем. Кызгылт-көрән төстә, буеннан-буена замогы да бар иде. Румия аны 14 нче мәктәпкә бүләк итте. Ул портфель укучы бала өчен түгел иде, укытучыга күбрәк туры килгәндер. Гагаринның аларга язган дүрт хатын, котлауларын, фотоларын – барысын мәктәпкә бүләк итте Румия. Беренче космонавтыбыз бик ихлас кеше булган, үзенә килгән меңнәрчә хатларны үзе укыган, күбесенә җавап язарга да тырышкан.

Шул килүендә Юрий Гагаринның Румия-Ританы да бик күрәсе килгән. Аның артыннан мәктәпкә машина да җибәргәннәр. Тик укытучы гына Румиягә кайтырга рөхсәт итмәгән. Бик нык еладым, дип сөйләгән иде Румия».

Кабат Румия ханымның хатирәләренә әйләнеп кайтабыз: «Әбием әлеге вакыйгалардан соң озак гомер итмәде, 1968 елда дөнья куйды. Бу хакта әнием Юрий Гагаринга да хәбәр итәргә теләде, аңа телеграмма сукты. Юрий Алексеевичтан җавап килде. Ул үзенең очышка әзерләнүе, шул сәбәпле генә әбиемне күмүдә катнаша алмавы, ләкин мөмкинлек булу белән, һичшиксез, безгә кайтачагы турында язды. Ни кызганыч, шуннан соң күп тә үтмәде, ул үзе дә һәлак булды. Нибары 34 яшьтә... Бу авыр хәбәрне ишеткәч, бик нык кайгырдым, озак еладым. Ул чакта аны кызганып бар халык елады бит. Илдә матәм көне игълан иттеләр. Хәер, аны хәзергәчә искә алалар һәм сагынып елыйлар...»

Румия ханымга башка космонавтлар белән дә очрашып, алар белән әңгәмәләр корырга насыйп була. 2011 елны Звездный шәһәрчегендә Космонавтикага багышлап үткәрелгән академия укуларында да катнашкан ул. Шунда очучы-космонавтлар А. Леонов, В. Горбатко, В. Джанибеков һәм башка очучы-космонавтлар белән күрешкән. Үзе дә чыгыш ясаган. Зал көчле алкышларга күмелгән! Ел саен Саратовка барып, анда җыелган халык алдында да чыгышлар ясарга туры килгән аңа. Мәктәпләргә очрашуларга да гел чакырып торганнар. Юрий Гагаринның космоска очуына 50 ел тулу уңаеннан медаль белән дә бүләкләнгән.

«Юрий Гагарин кешелек тарихында иң истә калачак шәхес дип саныйм, аның каһарманлыгы гасырлардан гасырларга күчә барачак, – ди ул үзенең хатирәләрендә. – Үсеп буй җиткәч, кияүгә чыгам да, ир бала табам һәм аңа Юра дип исем кушам дип хыялландым. Кызым туды, Оксанам... Үз-үземә сүз бирдем: малай туганчы табачакмын, барыбер Юра дип исем кушачакмын. Улыбыз туды, мин аңа, әлбәттә, Юрий дигән исем кушарга теләдем. Тик ул безнең Виталий булып китте... Кызымның улы – беренче оныгым тугач аңа Юра дип куштырмакчы булдым. Киявем белән кызым Рәсим була, диделәр».

Амангали Кайрадиновичтан бу хакта сорамый кала алмадым. «Улыбызга Юрий дип кушкан да булыр идек, бәлкем, – диде ул. – Тик нигәдер берара космос темасы ерактарак калды. Космонавтика көне дә формаль рәвештә генә билгеләнеп үтә башлады... Улыбызга батырларча һәлак булган гражданнар сугышы каһарманы Виталий Бонивур хөрмәтенә Виталий исемен куштык».

Ә мин кабат Румия ханым хатирәләренә әйләнеп кайтам: «Һәр язны, Космонавтика көненә багышлап, гаиләбез белән бәрәңге утыртабыз. 1961 елны ук әнием: «12 апрель – зур бәйрәм!» – дигән иде. Ә әбием Әнихәят: «Мин һәр ел саен 12 апрель көнне, хәтта кар яуса да, бәрәңге утыртачакмын», – дип белдерде. Бу инде хәзер безнең гаиләнең традициясе. 12 апрель көнне буразнага бәрәңге салабыз да, күккә карап алабыз... Бәрәңге утыртып бетергәч, бәйрәм өстәле артына җыелабыз. Мин бары тик бер елны – әтием үлгән елны гына Космонавтика көнен бәйрәм итмәдем. 2018 елны гаиләбез бик ишәйде – унау булдык. Якын туганым үлде дә, ирем белән аның берсеннән-берсе кечкенә алты баласын тәрбиягә алдык. Лаеклы ялда идем инде, тик бу карарны бер генә дә авырыксынмыйча кабул иттем. Ул чакта балаларның иң олысына – 11, ә иң кечесенә нибары 2 яшь ярым иде. Алар миңа әбием, дип дәшәләр.

Өебезнең иң түрендә, диварда Юрий Гагарин портреты эленеп тора. Аның портретларын, аңа багышланган әйберләрне гомерем буе җыям. Беренчесен мәктәптә укыган чакта ук алган идем. Юрий Алексеевич күгәрчен тотып төшкән фотосын үзе җибәрде. Аны да хәзер мәктәпкә бүләк иттем. Балаларыма, оныкларыма да Юрий Гагарин турында еш сөйләдем, аның якты мисалында тәрбияләп үстердем. Оныгыбыз Рәсим дә кечкенәдән үк беренче космонавт турында чыгышлар ясады. Уллыкка, кызлыкка алган балаларыбыз да Гагарин хакында яхшы белә, гел сөйләвемне сорыйлар. Минем өчен ул гыйлеме, тәвәккәллеге, игелеге белән Җирдә иң олы ихтирамга лаек зат. Беренче космонавт булу батырлыгы шушы бик тә яхшы күңелле кеше язмышына туры килгән!»

Румия ханым үзе дә якыннары күңелендә хатирә булып кына яши инде. «Ул яшьтән югары кан басымы белән интекте, бу чир аларның нәселендә бар, – ди Амангали Кайрадинович. – Шуның белән китеп тә барды... Без аның белән 1973 елны гаилә кордык. Мин Энгельс индустриаль-педагогика техникумын тәмамладым, армиядә хезмәт иттем. Румия аш-су остасына укыды. Берара Энгельс телефон станциясендә телефонист булып та эшләп алды. Әти-әнием Әстерхан өлкәсенең Харабали шәһәрендә гомер итәләр иде, без дә шунда яшәдек. Бер кыз, бер ул үстердек. Кызганыч, улыбыз инде күптән вафат... Румия микробиолог курсларын тәмамлады, сөт-май заводында лаборант булып эшләде. Ә инде авыл хуҗалыгы таркалгач, сәүдәгә күчте. Космонавтика көне уңаеннан аны гел төрле чараларга чакыралар, ә ул бер дә авырыксынмыйча бара, чыгышлар ясый иде.

Румиянең бертуган сеңлесе Нурия үлгәч, аның дүрт кызын һәм ике улын тәрбиягә алдык. Аларның берсе – Ваня, Румия тырышлыгы белән, Әстерхан кадет корпусының 5 нче сыйныфында белем ала. Яңа гына хәлен белеп кайттым әле менә. Кызым һәм оныгым минем янда яшиләр. Оныгыбыз Рәсим Әстерхан дәүләт университетының I курсында укый. Химик булачак. Билгеле, Румияне барыбыз да сагынабыз...»



ДӨМ-ДӨМНЕҢ ЗИРӘК КЫЗЫ



– Кызым туса, Зирәк дип кушам. Ул бик акыллы, зирәк булачак. – Беренче балаларын җирләгәннән соң, икенчесен көткән Саниясенә шулай ди Хәсәнҗан. Исеменә җисеменең никадәр туры килүен мең кат раслаячак кызлары туа. Зирәкләре!

Лилия ГӘРӘЕВА

Кызының да, улы Тукайның да (әйе, кечкенәдән ятим калса да, үзлегеннән укып белем алган, русча, гарәпчә иркен аралашкан Хәсәнҗан улына бөек шагыйребезнең исемен куша) үскәнен күрергә насыйп булмый әтиләренә. Аның батырларча һәлак булу хәбәре 1944 елны килә. Ышанмый Сания.

– Исән! Берәр поляк хатыны белән яшәп ятадыр әле! – Иренең бу дөньяда юклыгын соң сулышына кадәр кабул итә алмый ул.

– Алайса, мин шунда барам, әтине табам да алып кайтам! – дип юата аны кызы. Һәм чынлап та бара, таба... 1944 елның 5 августында – үзенең туган көнендә – 28 яшендә һәлак була Хәсәнҗан Закиров. Гади солдаттан өлкән лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелгән пехота батальоны командиры, замполит, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры Польшаның Седльце шәһәрендә 234 нче хәрбиләр каберлегендә җирләнә...

Әле узган гасыр башында ук бабасы Хаҗи бай (1921 елгы ачлыкта авылдашларын ач үлемнән алып калган кеше!) үзенең оныгы Хәсәнҗанга дип салган йортта әнисе Сания, энесе Тукай белән үсә Зирәк. Әтисенең белемгә сәләте балаларына да күчкән – тырышып укыйлар. Тик менә авыр тормыш кына җитди карарлар кабул итәргә этәрә япь-яшь Зирәкне.

– Әни, мин Лубянга, урман кисәргә китәм! – ди беркөн сиге-

зенчедә генә укучы кыз. Әнисенең, барма, укып бетер, дигәненә карамый, тәвәккәлле Зирәк. Түзми ана йөрәге, ике айдан кызын алып кайтырга дип Лубянга үзе килә. Арып-талып йоклаган, ябыккан, агач сөйрәп, иңбашлары суелган кызны битенә тамган кайнар яшь тамчысы уята.

– Кайтыйк, балам... Синең үз хыялың бар бит, – дип юмалый әнисе.

Бар шул! Бик тә җырчы буласы килә аның. Тик менә унынчыны тәмамлап, Алабуга мәдәни-агарту училищесына килсә, инде имтиханнар тәмамланган. Нәкъ «Приходите завтра» фильмындагы кебек! Ярый әле миһербанлы кешеләр бар җиһанда. Сеңлем, елама, әйдәле, тыңлап карыйк, дигән абыйга ияреп, рояль торган залга үтә Зирәк. «Кара урман»ны акапелла гына башкарса да, икенчесен – үзе бик тә яраткан, кечкенәдән үк авыл сәхнәсеннән җырлаган «Сагыну» җырын рояльгә кушылып башкарырга туры килә. Авылдан килгән кызның әле чын рояльне дә беренче күрүе ләбаса. Ошата аның мелизмнарын имтихан алучылар. Кабул итәләр укырга. Әмма... Училищеның бик абруйлы укытучысы тамагы шешеп еш авырган кызга беркайчан да җырчы була алмаячагын әйтә. Бу сүзләр аның хыял канатларын кискәндер дисезме? Юк! Җырчы булмаса ни?! Җырчы булмау әле ул җыр-көйдән аерылу дигән сүз түгел бит. Зирәкнең күңелендә яши ул халык моңы, аның күңеле җыр ярата, күңеле җырлый...

Диплом алгач, Әтнә китапханәсенә эшкә юллыйлар Зирәк Хәсәнҗан кызын. Алабуганың Татар Дөм-Дөмендә туган кызның язмыш сукмаклары әнә шулай Әтнә якларына килеп чыга. Монда берәр еллап эшләгәч, күңелендә яшәгән хыялы, әйдәкләп, аны Дөбъяз районының (хәзерге Биектау районы) Өлә-Казаклар авылына алып килә. Авыл яшьләреннән театр оештыра, аларны җырларга өйрәтә. Хәтта Казанга кадәр барып спектакльләр куялар. Үзе чибәр (әтисенекедәй кап-кара тирән күзләр!), җырлый башласа, дөньяңны оныттырырдай матур тавышлы, кулына гармун алса – өздерепләр уйнаган яшь кенә клуб мөдире күпләрнең йөрәген яндыргандыр ул чакта. Ә ул зәп-зәңгәр күзле Абдуллаҗанны сайлый. Өйләнешү белән шартын кабыргасы белән куя ир: клубта эшләмисең, башка эш тап! Башлангыч сыйныфларны укытырга урнаша яшь ханым. Үзенең беренче укытучысы – яраткан Зәкия апасы кебек булачак ул! И-и, ничек кызык итеп уздыра иде бит Зәкия апалары дәресләрне! Зирәк тә аның кебек булырга тырыша. Читтән торып Алабуга педагогика институтының филология факультетына укырга керә.

Күпмедер вакыттан яшь гаилә үзе дә Алабугага күченә. Югары класслы шофер булган Абдуллаҗанга эш шунда ук табыла, ләкин Зирәкнең генә эшлисе мәктәбе шәһәрдән ераграк. Аның каравы, әнисенә якын! Шүрнәк белән Дөм-Дөм арасын җәяү узып, көн дә туган йортына кайтып йөри ул. Берсендә РОНОдан килгән кырыс тикшерүче Зирәк ханымның (бу вакытта инде Садыйкова) дәресенә кереп утыра. Баштарак каушаса да, тиз кулга ала үзен укытучы. «Ник куркам соң? Планнарым тәртиптә. Дәрестә ни сөйлисен беләм...» Укучыларының куллары «биеп» кенә тора: «Апа, мин беләм!» «Апа, үзем әйтәм!» Тезә генә «бишле»ләрне Зирәк апалары. Бер дәрес уза, икенчесе... Өченчесе – җыр дәресе. Исе китеп чыга дәрестән тикшерүче. Икенче елны килгәч тә, Зирәк Хәсәновнаның дәресенә керәм, ди... Ә бу вакытта инде Зирәк Алабугага ире янына киткән була.

1962 елның җәендә Зирәк ханымның биографиясендә яңа сәхифә ачыла. Шушы елларда якын-тирә районнарны берләштерәләр. «Вперед» һәм «Алга» газеталары «Новая Кама», «Яңа Кама» исемнәре белән чыга башлый. Соңгысы рус телендәгесенең дубляжы, ягъни тәрҗемәсе.

– Газетада язмаларны машинкада җыючы кыз, мин, һәм миннән башка бер корректор, ике тәрҗемәче – сугыш ветераны Шамил абый Гарифуллин һәм Җәрьәт абый Фатыйхов эшли иде. Редактор урынбасары Вәгыйз Вәлиев шулай ук сугыштан кайткан кеше, – дип искә ала үзенең истәлекләрендә 40 ел гомерен шушы газетага багышлаган Зирәк ханым Садыйкова – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Газеталар кулдан җыелып, атнасына дүрт тапкыр чыккан көннәр. Компьютерлар да, интернет та юк заман. Иртәнге алтыда радиодан яңалыклар тапшыралар. Бер кулына сабый баласын тоткан килеш, диктор артыннан тиз-тиз генә язып калсаң каласың, өлгерә алмасаң – юк! Сигездә башланган эш кичке тугызларга кадәр сузыла. Башта материалларның рус телендә әзер булганын көтәсе, аннары аларны тәрҗемә итәсе, җыясы... Машинкада җыючы кыз авырып киткән, алмашка кеше юк – аның урынына Зирәк утыра. Линотипта җыючылар өлгерә алмый – анысына да үзенә өйрәнергә туры килә. Ул елларда инде Сания апа да кызы белән кияве янына килеп яши. «Җансыз Микулай! – дип, шаяртып әрләгән була ул кызын. – Шул гомердән бирле эштә булалар димени?» Зөбәрҗәт белән Алмазны үстерү дә күбрәк дәү әниләре – сабыр, эшчән Сания әбиләре өстендә була.
Ул оныкларын да тырыш, кешелекле, ярдәмчел итеп тәрбияләргә тырыша, аларны үзләренең эш-гамәлләренә гадел бәя бирергә дә өйрәтә. Гадел, сүзе туры, киңәше үтемле булганга күрә, авылдашларының аның үзен дә кайчак шаяртып, кайчак җитди итеп «прокурор» дип атаулары бер дә гаҗәп түгел.

Башта корректор, аннары тәрҗемәче булып эшләгән Зирәкне 1979 елда «Яңа Кама» газетасының дубляж редакторы итеп билгелиләр. Җаваплылык та, эш тә арта. Кайчандыр, әле сугышка кадәр авыл советы рәисе булып эшләгәндә этисе Хәсәнҗанның да мәкаләләре басылган газетада инде кызының язмалары дөнья күрә. Районның тырыш, булдыклы кешеләре, тыл ветераннары, иген үстерүчеләр, илне туендыручылар – менә кемнәр була аның геройлары.

PRESSA

Анның музыкага сәләте балаларына да күчкән. Оныгы Артур «Визит» джаз оркестры солисты, музыкант.

Ничә еллар күңелендә бер хыялы яши редакторның – Алабугада татар телендә чыккан мөстәкыйль газета булуын тели ул. Моның өчен талантлы яшьләрне үз тирәсенә туплый, заманча әйтсәк, потенциал булдыра.

Ниһаять, ул көн дә килә. 1991 елның февралендә Алабугада татар телендәге мөстәкыйль газета – «Алабуга нуры» чыга башлый. «Тырышлыгың күп керде, үзең җитәклә», – дисәләр дә, редактор вазыйфасыннан баш тарта Зирәк ханым. Тыйнаклыкмы? Бәлки. «Баш мөхәррир ир-ат булырга тиеш. Алай газетаның абруе зуррак булачак», – ди. Ләкин соңрак аңа барыбер бу вазыйфага алынырга туры килә. Лаеклы ялга чыкканчы журналистикага тугрылык саклый ул. Юк, гомеренең ахырына кадәр, дип әйтү дөресрәк булыр.

Югары бәяләнә анның хезмәте. 1987 елда ТАССР Югары Советы Президиумы Указы белән «Хезмәт ветераны» исеме бирелә. «Правда» газетасына – 100 ел» һәм «ТАССР төзелүгә – 100 ел» уңаеннан истәлекле медальләр тапшырыла.

– Әнием тыныч кына өйдә утыра торган кеше түгел иде, – дип, хатирәләре белән уртаклаша кызы Зөбәрҗәт ханым. (Сүз уңаеннан әйтеп үтик, Зөбәрҗәт Абдуллаҗан кызы – музыкант, композитор. Алабуга гимнының авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.) – Лаеклы ялга чыкканнан соң да яраткан коллективы белән тыгыз элемтәдә торды. Алабуга мөселманнарының җәмәгать эшләрендә актив катнашты. Шәһәребезнең Җәмигъ мәчетенә йөреп, гарәпчә укырга, язарга һәм дин нигезләренә өйрәнде. Гомере буе сагынып яшәгән әтисе Хәсәнҗан да гарәпчә укый-яза белгән ич!
Дәү әнием Сания дә муллалар нәселеннән, коммунист булса да, яшереп кенә намазын да укыды, уразасын да тотты. Әнием Коръәнне шулкадәр матур мәкам белән укый иде...
2012 елны әни тагын бер хыялын тормышка ашырды – хаҗ сәфәренә барды. Аннан кайткач, шундый бер хәл сөйләгәне истә. Иртәнге намазга кадәр мәчеткә кереп, акрын гына Коръән укып утыра торган була ул. Укыганда әле берсе килеп утыра янына, әле икенчесе. Намазга җыелышалардыр дип уйлый әнием. Коръән укуын тәмамлап, башын күтәреп караса, үзен әйләндереп алганнар да, бар да анның мәкаменә оеган икән. Әниемә һәркем үз телендә хөрмәт белән соклануын белдергән. Алабугада да, Дөм-Дөмдә дә әниемнең шәкертләре күп булды. Бер дә авырыксынмыйча, мәчеткә килеп укый алмаучыларның өйләренә үзе барып укытты.

Сабыр кеше иде әни. Беркайчан да зарланмас, гел шөкер итәр. Энем Алмаз авариядә вафат булгач та, хәсрәтен, күз яшен дөньяга күрсәтмәде. «Мин еласам, сезгә тагын да авыррак булачак», – дияр иде.

Кешеләргә ярдәмчел булу сыйфаты аны гомере буе озата барды. Үзе кайчандыр «Сагыну» җырын җырлап елаткан тол солдат хатыннарына үз вакытында пенсияләрен арттыру, өстәмәләр ясау артыннан архивларда күп йөрде, хөкемдарларга күп тапкырлар мөрәҗәгать итте. Анның бар уе кешеләргә игелек кылуда иде. «Яхшылык аунап ятмый, яхшылык эшләгез!» – безне шулай өйрәтеп үстерде ул.



«Яңа Кама» газетасының коллективы. Зирәк Садыйкова (уңнан – беренче).

2021 елның Рамазан ае апрельгә туры килде. Аллаһның барлыгына чын күңеленнән инанган Зирәк ханым уразасын калдырамы соң?! Зөбәрҗәт иртәдән үк әнисенә шалтыратып, хәлләрен белешә. «Авыру әтине карый, йончыгандыр инде», – дип, үзенчә юрый ул әнисенең тавышындагы хәлсезлекне. Ә бераздан ашыгыч ярдәм табиблары аңа авыр хәбәрне җиткерә...

16 апрельдә – җомга көнне, уразалы килеш, өйлә намазына кадәр күзләрен мәңгегә йома ул... «Изге кеше иде!» – милләтенә, диненә карамастан, алабугалар зур ихтирам белән анның турында шулай ди.

Әтисенең: «Зирәк булачак», – дип әйткәне рас килә. Исемен аклый анның кызы – тормыш һәм хезмәт юлын зирәкләрчә уза.

Фотолар гаилә архивыннан

БУРЫЧ ДУСЛЫКНЫ БОЗМАСЫН



Ләйсән ХАЛИКОВА, финанс белгече

«Бурыч ашаганчы борыч аша», ди татар халык мәкале. Ә кайвакыт әҗәткә керми чара юк. Кемдер, кредит сорап, банкка мөрәҗәгать итә, ул бирмәсә, микрофинанс оешмасына бара яисә туганнардан, дуслардан алып тора. Акча алына, ә шуның белән туганлык җепләре өзелеп, дуслык бетәргә мөмкин.

Акча алганда расписка язарга кирәк – барыбыз да белгән, ләкин бик сирәкләр генә куллана торган кагыйдә. Туганың яки дустың белән нәрсә өчен алдым-бирдем кәгазе төзеп торырга инде дип уйлыйбыз. Бурычка алуны документлаштыру киләчәктә авызың пешмәсен, мөнәсәбәтләр бозылмасын өчен мөһим. Этика ягыннан караганда, расписка язуны акча алып торучы үзе тәкъдим итсә яхшырак. Документ аның кулы белән языла. Интернеттан теләсә нинди бер үрнәк алып, шуның буенча расписка төзеп куючылар бар. Ләкин акча кайтарылмаса, һәм эш судка барып җитә калса, бурычка бирүне исбатлап булсын өчен, алдым-бирдем кәгазен бөтен нечкәлекләрен истә тотып әзерләргә кирәк. Башта документның исеме, ягъни расписка икәне күрсәтелә, кайда, кайсы көнне, сәгать ничәдә төзелгәне языла. Аннары акчаны алып торучы үз исемен, паспорт мәгълүматларын куя, шулай ук кемнән күпме бурычка алып торуын, аны кайчан кайтарасын күрсәтә. Нинди процент белән алынганын әйтә ала. Вакытында кайтармаган очракта ниндидер штраф яисә процентлар түләү турында килешү булырга мөмкин, ул да аңлатып языла. Ахырда расписканы язган кеше имзасын куя һәм «бу расписка аек акыл һәм сәламәт хәтер белән язылды, аны төзегәндә миңа әхлакый һәм физик басым ясалмады», дип өсти. Монысы шулай ук эш судка барып җитә калса, бурычка алучы җаваплылыктан качарга теләп, «мине мәҗбүриләп яздырдылар», дип әйтмәсен өчен кирәк.

Әҗәткә алганда төзелә торган икенче документ – займ килешүе. Анысында инде ике якның да мәгълүматы, шулай ук акча алуның бөтен шартлары языла: нинди вакытка алына, нинди процент белән. Нәрсә өчен икәнен дә күрсәтергә була. Бурычка биргәндә янда шаһитлар булса, займ килешүендә аларны да язарга ярый. Документта «бу килешү акча алуны раслый» дигән аерым пункт та өстәргә онытмаска кирәк. Килешү төзелүен төзелгән, әмма акча шул ук көнне бирелмәскә дә мөмкин бит, бу очракта кыенлыклар килеп чыгуы ихтимал. Әлеге пунктны яздыру – акча биреп торучы мәнфәгатендә, чөнки эш судка барып җитә калса, бурычка бирүегезне исбатлый торган берәр нәрсә бармы, дип сораячаклар. Әгәр инде килешү төзелгән, ә бу пункт өстәргә онытылган икән, акчаны алу турында аерым расписка язарга мөмкин.

Документларда процент ставкасын да күрсәтергә була, дидек. Монысы – бурычка бирүче мәнфәгатендә. Әйтик, ярты елга әҗәткә алып торалар икән, тиешле вакыт эчендә акчаны кайтармасалар, соңга калган һәр көн өчен гомуми бурыч суммасыннан бер процент «неустойка» өстәлеп бара, дип килешергә мөмкин. Кичектергән очракта нәрсә буласы расписка яки займ килешүендә күрсәтелмәсә һәм дәгъва судка барып җитә калса, «неустойка» процентларын түләтү Гражданлык Кодексының 395 нче маддәсе нигезендә карала. Анда Үзәк Банкның төп ставкасы исәпкә алына. Мәсәлән, хәзерге вакытта ул – 20 процент.

Цифрлаштыру заманында яшибез. Бурычка алганда да кулдан-кулга бирү түгел, картадан картага күчерү ешрак күзәтелә. Икенче мисал: эштә хезмәттәшебез: «Банкоматка чыгып торасым килми, син миңа кулга бир, мин сиңа банк картаңа күчерәм», – дип сорый. Өченче мисал: базарда җиләк-җимеш алабыз, ә кулда акчабыз юк, картада гына, әмма базарда аның белән түләп булмый икән. «Онлайн банк аша күчерим?» – дип сорыйсың яисә сатучы үзе шулай тәкъдим итә. Санап киткән барлык бу очракларда да риск бар. Һәр очракта да алу-бирү килешүен шикаять итәргә мөмкин. Әйтик, берәү дустының картасына акча күчерде, тегесе аңа кулына бирде, ди. Акчаны картага күчергән кеше бер-ике ел үткәч уйлый: нәрсәгә күчергәнемне дә, кире кайтардымы-юкмы икәнен дә хәтерләмим, мин моны судка бирим, ул акчаны кайтарып алыйм әле. Әгәр синең яктан ул акчаны кулына бирүең турында берәр дәлил юк икән, суд карары акчасын таләп итүче кеше файдасына булачак. Шуңа өстәп, аның әле «неустойка» да алырга хокукы бар, анысы, әйткәнемчә, төп ставка буенча исәпләнә. Шушындый кыен хәлгә калмас өчен, берәрсе банк картасына акча җибәргәндә, «нәрсә өчен җибәрүеңне күрсәт, бер сүз белән булса да яз әле», дип сорарга киңәш ителә.

Фәнзилә МОСТАФИНА әзерләде.

PRESSA

ЯШӘҮ КӨЧЕ КАЙДА?



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Гадәттә, сәхнә кешеләрен күбәләккә тиңлиләр. Имеш, бер кайгысыз матур тормышта көн итәләр. Сәхнәгә чыгып, тамашачы мәхәббәтен, энергиясен яулыйлар, алкышлар җыялар да рәхәтләнеп яшиләр. Аларның курчак түгел, кеше икәнен онытып җибәрәбез кайчак. Артистларның да үз тормышлары, шатлык-кайгылары, яшь аралаш елмаеп уйнаган вакытлары бар. Әмма бу хакта тамашачы белергә тиеш түгел. Әнә шундый зур көч сорый ул сәхнә. Ләкин сәхнә белән бер сихерләнгәннәр аны ташлый алмый, ташласа да кире әйләнеп кайта. Һәм тормышында нинди генә авырлыклар булса да, тамашачылары каршына елмаеп чыга. Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры актрисасы, Татарстанның атказанган артисты Рәмзия ЗАКИРҖАНОВА да – әнә шундыйлардан. Аның белән ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Минем белән авырлы әни 1 май көнне, мотоциклга утырып, Ютазыдан әбиләргә – Азнакайдагы авылга кайткан. Юлда кайту ярамагандыр, туарга ашыкканмын. Өйдә туган бала мин. Биләүләргә әйбер булмагач, эти күлмәгенә төргәннәр. Менә шул эти күлмәге мине гомерем буе саклады, әле хәзер дә саклый! Эти мине бик ярата иде. «Кызым» дип кенә торды. Әни кырыс булды. Олы бала бит! Элек болай да иткәкә алып, сөеп-назлап утырмаганнар. Әнидән «кызым» дигән сүзне егерме яшем узгач кына ишеттем. Шул вакытта ялардай булдым. Әни яратмады дигән сүз түгел бу. Без дип яшәде, эшләде. Өч кыз без, өчебезгә дә ярдәм итте. Тормышны өстери торган хатын иде ул. Артык сөйләшми, бөтен нәрсәсе – эчендә. Хәзер үземдә аның чалымнарын күрәм... Мин дә артыгын сөйләмим, нәрсәдер даулап йөрмим. Зарланырга да яратмыйм. Ә нәрсәгә? Мин бит яшим. Бүген яшим! Ә бит төрле вакытлар булды...

Казанга театр училищесына укырга керергә баруымны әни белми дә калды. Эш белән Уфага киткән иде ул. Җыендым да чыгып киттем. Эти белән әбигә генә әйттем. Актриса булу кечкенәдән килгән хыялым иде. Театр училищесын тәмамлагач, Марсель абый Сәлимҗанов Камал театрына чакырды. 12 ел эшләдем анда. Кызым Динара белән декрет ялына киттем дә башка кайтмадым. Һәр актер гөрләп уйнап йөргән җиреннән тукталып кала – арттан яшьләр басып килә, алга әле бара алмыйсың, анда өлкән актерлар. Сине күтәрә торган режиссерың булмагач, театрда нишләп йөрергә инде?! Үпкәләп китмәдем. Театр дөньясыннан мәңгелеккә китәм дип, хушлашып киттем. Аннан башка да тормыш барлыгын белдем. Һәм анда тынычлык һәм рәхәтлек тойдым. Үземне балаларга, иремә багышлармын дип уйладым. Ирем Ленар да эшләвемә каршы булды. «Балаларны кара», – диде. Үсмер балалар өчен куркыныч чор иде ул. Урам төркемнәре вакыты. Улыбызны шулар әләктереп алырга тырышты. Ярый укытучысы, өебезгә килеп, хәлләрне аңлатып бирде. Ярты ел буе коляска этеп, Альбертны мәктәпкә кадәр илтеп куйдым, барып алдым. Безнең арттан карап калган урам малайларына йодрык күрсәтеп китә идем. Алар, мин булгач, якын килергә курыкты. Ул вакытта йөрәк бертуктаусыз җилфердәп торды. Бик авыр хәл ул. Беркемгә дә язмасын. Театрдан китеп иң элек улымны саклап калдым. Аның сыйныфташлары күбесе юк инде, йә наркоманнар... Улым нәрсәнең ак, нәрсәнең кара икәнен аңлап калды. Соңрак та булды бугай төркемнәр белән «очрашу» – йөзе күгәреп кайткалады. Әмма аның сыгылмаячагын, үз-үзен яклаячагын белә идем, шуңа әллә ни борчылмадым.

Театрдан китәм дип китсәм дә, аерыла алмадым. Шул тирәдә генә яшәгәч, көн саен безгә керми калмыйлар, һәр премьерага йөрим. Ул чорда театрны сагынып утырырга вакытым да булмады. Киноларга төшә башладым. Әхтәм абый Зарипов Тәлгать Галиуллинның «Кияү» әсәре буенча сценарий язган булган. Мине шул кинода уйнарга чакырдылар. Анда чишенергә кирәк иде. «Юк», – дидем. Рушан Шәриф башта ирем белән сөйләшкән, аннан соң икәүләп мине үгетли башладылар. «Съемка мәйданында син булсаң гына төшәм», – дидем иремә. Ул ризалашты. Башка съемкаларда да – ул гел минем янда. Шуңа башкалар риза булмаган рольләрдән курыкмадым. Сөяркә, явыз хатын рольләрен уйнадым. Ышандырырлык итеп уйнаганмындыр инде, бервакыт кибеттә бер әби килеп, «Кабахәт», дип, йөземә төкереп китте. Кеше фикеренә беркайчан да исем китмәде, якыннарым мине белә. «Дилемма» дигән кинода Ленар белән икәү ирле-хатынлы булып уйнадык. Бер йортта яшәгән күршеләребез: «Алар аерылышканнар, кызлары үлгән икән», – дип сөйләгәннәр. Киноны безнең тормышка күчергәннәр. Димәк, бик яхшы уйнаганбыз! Кинода күп төштем, әмма миңа барыбер театр якын. Кино ул фейерверк кебек бер мизгел – төшәсең дә онытасың, ә спектакльдәге ролең белән еллар буе яшисең. Театр ул – тере организм. Бөтенләйгә дип китсәм дә, кире кайттым бит менә. Күрше подъездда гына яшәүче Кариев театры режиссёры Ринат Әюпов гаиләсе белән аралашып яшәдек. Ул мине театрга чакырды. Балалар инде үз-үзләрен карый башлаган, җитмәсә, театрдан еракка – Казан читенә күчендек. Миңа кешеләр белән аралашу җитмәде, күңелсез була башлаган иде. Бәлки, күченмәгән булсак, театр дөньясына кире кайтмаган да булыр идем. «Әмма мин актриса булмыйм, гастрольләргә йөрмим», – дидем. Труппа мөдире декретка киткән иде, шуның урынына килдем. Җәй көне труппа гастрольләргә чыгып китә башлады. «Көзебезнең язы» спектакле белән Нуриәхмәт Сафин, Халидә Сөнгатуллина да китәргә җыеналар. Гөнаһ шомлыгына каршы, Халидә авырып китте бит. «Керәсең дә, үзең уйныйсың», – диде режиссёр. Кердем дә уйнадым. Шул спектакльдән, гастрольләрдән башланды театр сәхнәсенә кире кайту тарихым. Бер суга ике кермиләр дисәләр дә, мин тоттым да кердем. Ничек бардым бу адымга, әлегә кадәр аңламыйм. Язмышым шулдыр инде. «Нигә кайттым икән», – дип үкенгән чакларым да бар. Ачу килгән саен, шул уй килми калмый.

(Рәхәтләнеп көлә.)

Фото: Анна Арахамия



Ул вакытта үлем турында уйламадым да. Төзелә башлаган йортыбызга күчеп, гаиләм белән матур итеп яшисе килү теләгем көчле иде.

Инде тормышым җайланды, балалар үсте, мин – актриса, дип, тынычлап яши башлагач кына, Аллаһы Тәгалә кабат сынау җибәрде. Уйламаганда!

2014 елның ноябре иде ул. «Нигез ташлары» спектакле белән Апас районы Балтай авылына киттек. Клублары катып үлмәле, ә без җәйне уйныйбыз. Ике көн шул сәхнәдә спектакль куйдык. Шунда салкын тидердем. Корык-корык ютәллим, әмма авырырга вакыт юк. Дару эчәм дә театрга чабам. «Казан ятиме» дигән спектакль чыгарабыз. Андагы Серафима Семеновна ролен Ркаил Зәйдулла махсус минем өчен язган иде. «Бу спектакльне чыгарыйм инде», – дип йөрим. Февральдә инде сулый алмый башладым. Сөйләшкәндә сүз саен тын алам. Дару эчкәч җайлана кебек, бераз йөргәч тагын тын алу кыенлаша. «Үпкәм ялкынсынгандыр инде, уколларсыз булмас», – дип, ниһаять, репетициядән соң табибка киттем. Ул рентгенны ошатмыйча МРТга җибәрде. Икенче көнне: «Тиз арада килеп җит!» – дип шалтырата. Ничек шунда ук чыгып йөгерәсең инде – репетицияләр бар бит. Алар тәмамланганнан соң гына киттем. Кабинетына килеп керүгә үк: «Сезгә тиз арада онкологка барырга кирәк!» – ди. Күңелемә шунда гына шом керде. Әтием дә үпкәдәге яман шеш авыруы белән китеп барды. Әтинең сеңлесен дә шул елны гына әлеге авырудан җирләгән идек. Әти ягында бар бу чир. Өйгә кайткач, малаема да, иремә дә әйттем. Малай МРТ нәтиҗәләре яздыртылган дискны барып алды да, Республика клиник хастаханәсендә баш диагност булып эшләүче туганыбызга җитәкләп алып китте. «Тиз арада операция ясатырга кирәк», – диделәр. Ул вакытта онкология хастаханәсе Кремль астында иде, диск тотып шунда бардым. Табиб карады да: «Үпкә ялкынсынудан калган таплар бу, «Исландский мох» эчегез», – диде. Тынычланып кайттым да, дөнья бетереп ул мүкне эзли башладым. Эшем дә бар бит әле. Спектакль чыгарасым бар, җитмәсә. Улым тынычланмады, мине тагын Республика клиник хастаханәсенә алып китте. Анда да башта берни күрмәделәр. Бронхоскопия ясагач кына белделәр. Ул шеш күренми торган җирдә урнашкан булган. 7 мартка операция билгеләделәр. Ризалашмадым. Бәйрәмне гаиләм белән үткәрәсем килде. Табыннар корып, бәйрәм ясадым. Хәлемне белгән ирем шок халәтендә иде, улым нык торды. Ә мин тыныч булдым. Үләм икән дигән уй башыма да килмәде. Авыру башлангыч стадиядә генә, димәк, операцияне вакытында ясаячаклар. Хастаханәгә дә елмаеп барып кердем. Операциядән уянгач, узды, бетте, дип уйладым. Озак та ятмый өйгә чыктым, әмма хәл юк, ашыйсы да, эчәсе дә килми. Шул вакытларда ирем мине елый-елый ашатты. «Аша», дип, кашыкны авызыма китерә, күзләрендә яшь мөлдерәп тора. Менә шул тотты мине. Әкренләп-әкренләп ашый башладым. Ирем бик тәрбияләде: һәр иртә аяк-кул бармакларыма массаж ясады. Җайлап кына йөртте. Шулай аякка бастырды. Мин инде, беренче стадия булган, дип, тынычланып беттем. Ике-өч көннән соң башланачак химиотерапиягә әзерләнәм. Палатада бергә яткан бер хатын хәл белешергә шалтыратты. «Кәгазьдә язылган саннарны интернеттан кереп караган идем, минем икенче стадия булган икән бит. Син карамадыңмы?» – ди бу. «Бәтәч, – мин әйтәм, – туктале, карыйм». Карасам, ни күрим: соңгы стадия, метастазалар киткән булган. Көтүләре белән мине алдаганнар! Шул вакытта шок кичердем. Ике көн ашамый-эчми тик яттым. Бөтен уем: мин үлсәм, ирем өйләнер дә кызымны читкә этәрерләр. Ярый, малай өйләнгән, кызым ул вакытта укып йөри әле. Минекеләр нәрсә булганын аңламый, үзем эндәшмим. «Нәрсә ятасың инде һаман, тор!» – диләр. Шуннан бөтен ачуым-үпкәм чыкты инде. «Сез мине үләр дип уйлыйсыз инде? Барыбер үлмим! Көтмәгез! Бөтенегезне дә кызык итәм әле!» – дидем. Ике көн яткан-нан соң ачудан торып та бастым. Үзем дә уйламаганмын инде. Башлангыч стадия булса, химиотерапия бирмәгән булырлар иде бит инде...

Беренче тапкыр химиотерапия алырга барган көнем хәтердә. Моңа кадәр бер тапкыр да елаганым юк иде. Бер тапкыр да! Химиотерапевтка кергәч, күземнән яшь ага башлады. Тыеп кына булмый бит! Аңлыйм: минем буа ерылды. Бөтенесе җыелган, күрәсең... Табиб миңа карады да: «Плакать собралась?» – ди. Эндәшмим, ә үземнең күземнән яшь ага да ага. «Мне тут не плачь, если будешь плакать, я тебя лечить не буду», – ди. Мин барыбер эндәшмим. Шуннан соң: «Вон отсюда! Успокоишься, зайдешь», – дип, бүлмәсеннән куып ук чыгарды. Коридорда бер читтә басып торган иремнән качып, аскы катка төшеп, рәхәтләнеп еладым. Тынычлангач, кире табибка кердем. «Будем плакать?» – ди. «Нет!» – дидем. Шулай итеп химиотерапевт миңа иң элек «шоковая» терапия үткәрде, аннан соң үземне кулга алдым инде. Ул вакытта дүрт тапкыр «химия» алдым. Чәчләрем тотам-тотам гына коелды. Тоттым да «накладка» алдым. Ул калган чәчкә каптырмалар белән генә ябыштырыла. Бик табигый күренә. Чәчем коелып беткәнне сизмәделәр дә. Ул «накладка»ны хәзер «Супер кияү»дә киеп уйныйм.

Баштагы мәлне табиблар миңа сәерсенеп тә карыйлар иде кебек. Үләр дип уйлаганнардыр инде, бер шәфкать туташы: «Ул әле үлмәдемени?» – дип, бик гаҗәпләнгән дә. *(Рәхәтләнеп көлә.)* Ә мин исән! Ул вакытта үлем турында уйламадым да. Төзелә башлаган йортыбызга күчеп, гаиләм белән матур итеп яшисе килү теләгем көчле иде. Якыннарым, коллегаларым зур терәк булды. Аларның ярдәмен тою да яшәргә көч бирә. Артист халкы бу җәһәттән бик мәрхәмәтле ул. Безнең театрда бигрәк тә. Йортыбызга күченгәндә килеп өмәләр ясап киттеләр. Рухи яктан да, финанс ягыннан да бик булыштылар. Әйтәм бит, артистлар шундый халык ул: синең театрданмы, башка театрданмы, ярдәм итәргә генә торалар. Авыр вакытларымда Камал, Тинчурин театры артистлары

да килеп хәлемне белешеп тордылар. Барысына да зур рәхмәт. Бу яктан мин бик бәхетле!

Мартта операция ясадылар, көзен инде мин «Кичер мине, әнкәй» спектаклендә Миңзифа роле белән репетицияләрдә кайнаша идем. Төшкә кадәр эшлим, аннан соң гомеопатка китәм. Мин аңа ике ел буе һәр көнне йөрдем. Ул минем өчен махсус дару да ясап бирде, гипноз белән дә дәвалады. Аның да файдасы тими калмагандыр. «Өйдә генә утырам» дигән уй бер секундка да башыма килеп карамады. Театр, гомер булмагандай, бик кирәк иде миңа. Өйдә ятканда әллә нинди уйлар килә бит ул. Ярый әле догалар укып тынычлана идем. Ә сәхнәгә чыккач, барысы да онытыла. Гомумән, авыруымны бөтенләй читкә алып куйдым. Ул хакта уйлап яшәмәскә тырышам. Ә нигә уйларга?! Рольләрем хәзер төрлечә бирелә. Хәлемә карап. Иртәнге якта хәлем начаррак була. Соңгы вакытта бигрәк тә. Дарулар тәэсиредер инде ул. Төш вакытына кеше булам. Яши башлыйм! Театрда рольләрем күп: «Кәҗүл читек»тә – Әби, «Ак чәчәкләр»дә – Рәисә, «Сөннәтче бабай»да – Фәхрия, «Питер Пэн»да – индеец... Барысын да яратып уйныйм. Гадәттә, соңгы рольне аеруча яраталар. Әлегә «Матур-City»дагы Гөлнара белән яшим. Аны режиссёрыбыз махсус юбилеем өчен Айгөл Әхмәтгалиевадан яздыртты. Һәр актрисаның күңелендә уйныйсы килгән роле кала. Минем дә бар андыйлар. Нинди роль икәнен әйтеп тормыйм. Ул роль өчен инде мин карт. 35–40 яшьләр тирәсендә уйнала торган ул. Әмма ул чакта театрдан китеп, бала карадым. Юк, өйдә утырганыма бер тамчы да үкенмим. Роль ул – бик тар төшенчә. Театр дөньясында гына кирәк. Аннан чыккач, ул вак бер әйбергә әйләнә дә кала. Дөнья бит ул бик зур. Һөнәрең белән генә яшәргә ярамый. Ул сазлыкка әйләнә алайса. Тормышның башка якларын да колачлап яшәү кирәк. Гаилә минем өчен беренче урында. Сине театрда күтәрергә дә, таптап китәргә дә, хыянәт итәргә дә мөмкиннәр. Ә гаиләң ташламаячак, ул хыянәт итмәячәк. Мин аларга бик ышанам. Иң авыр чакларда инандым инде моңа. Иң элек иремә, балаларыма, оныгыма кирәкмен. Аларга миннән башка бик начар булачак, ә театрда берни үзгәрмәячәк. Синең рольләреңне яңа бер актриса керә дә уйный. Өч көн сөйләрләр дә онытырлар, бу – гадәти күренеш. Әнә, әллә нинди бөек артистларны да кайчагында гына искә төшереп алалар да, шуның белән бетте, ә гаиләң сине гомере буе искә алып яшәячәк, онытмаячак. Иң элек гаиләмне беренче урынга куйдым. Ленар – икенче ирем. Беренче ирем белән озак яшәмәдек. Ул театрга каршы булды. Аңа ышанып беткән булсам, эшемне ташлаган да булыр идем. Әмма ул терәк булырлык кеше түгел иде. Ленар – минем кешем. Аның белән күп авырлыкларны бергә уздык. Ә андый гаиләләр гадәттә бик ныклы була. Әле мин өйдә утырган чакта Ленар авариягә очрады. Без хастаханәгә килеп җиткәндә, барыбер яшәмәячәк, дип, аны палатага да кертеп тормаганнар... Тавыш куптаргач кына операциягә алып кереп киттеләр. Аны теге дөньядан тартып алдылар. 21 көн буе дүрт кешелек кечкенә палатаның ишек төбендә йокладым: иремне сакладым. Өйгә алып кайткач та, озак тернәкләнде. Ул вакытта мин аңа һәр көн массаж ясадым. Аның аякка басачагына, йөреп китәчәгенә иманым камил иде. Бер-беребезгә авыр чакта шулай ярдәм иттек. Шуңа да хәзер бик якыннардыр инде. Безгә сөйләшергә дә кирәкми, күз карашыннан аңлашабыз. Кыяфәтеннән, күзеннән үк аның хәлен белеп торам. Ул да шулай ук. Яратудан да югарырак хис бу!

Бүген мин бик бәхетле кеше! Һәр көн иртән күземне ачуга: «Аллага шөкер, уяндым», – дим. Алдагысын үзгәртеп булмый, шуңа күрә бүгенге көн белән яшәргә кирәк. Артка карасаң, инде күп нәрсәләр үткән. Үткәннәр белән яшәү – ахмаклык, ә алда бу тормыш булмаска да мөмкин. Бүгенге көн шунысы белән кадерле. Бик кадерле! Нигә әле рәхәтләнеп яшәмәскә?! Авырулар Ходайдан сине сынарга дип бирелә. Йә сынып үлеп китәсең, йә тормышыңны үзгәртеп, башкача яши башлыйсың. Мин башкача яши башладым. Әйткәнемчә, авыруым турында уйлап яшәмим. Әйе, һәр көнне таргетлы терапия алам – дару төймәләре эчәм. Аны гомер буе эчәргә кирәк, аны эчәргә күнектем инде. Хастаханәгә барып, һәрвакыт тикшерелеп, күренеп торам.

Соңгы баруымда табиб күзләремә туры карамады әле. Әмма бу мине бер дә борчуга салмады. Үземнең хәлемне беләм: бар да яхшы. Ә иң мөһиме: яшәү дәртем сүнмәгән. Яшәү дәрте сүнмәсә, авыру җиңә алмый ул.

Кайсы вакытта китәсең туганда ук язылган... Язылганнан бер секунд та артыграк яшәмәячәгемне беләм. Әмма яшәгәндә тырышырга, көрәшергә кирәк. Күңелне төшереп, түшәмгә карап яту көчсезлек ул! Тырышсаң, була. Без зур йортта яшибез. Балаларыбыз, оныгым килеп йөри. Алар белән үткәргән һәр минут кадерле миңа. Бу авыруны кичергәннән соң дөньяга караш 180 градуска үзгәрә икән. Бик рәхәт бит яшәүләре, бик матур дөнья! Менә кара әле! (Рәмзия апа белән гримерка тәрәзәсеннән урамга карыйбыз – *Ч. Г.*) Әйе, көн ямьсез, салкын дип уйлар кайберәүләр. Юк, матур бит! Кояш! Тиздән яз! Тәрәзә төбендә гөлләр уяна башлаган. Яңа сулыш! Яңа тормыш! Ничек шуларны ташлап китәсең инде? Китәсе килми бит әле. Язны көтәм. Бакчага чыгып чәчәкләр утыртасым килә. Көзне дә көтәм. Яңа сезонда театрда яңа рольләр бирерләр дип өметләнәм. Ә үлемнән курыкмыйм. Мин аны башка яшәү яссылыгына күчү дип кабул итәм. Үлемнән соң тормыш барлыгына ышанам. Бардыр ул... Югыйсә әтием миңа хәзер дә ярдәм итмәс иде. Аның нindiдер эшләремне хуплап барганын сизәм.

Һәр минуттан ләззәт кичереп яшим, чөнки бу минутларым, бу гомерем башка кабатланмаячак. Нигә әле күңелне төшерергә?! Менә күз алдыңа китер әле: 8 Март бәйрәме булып узды. Йокыдан уянуыма ирем чәчәкләр, торт алып кайткан инде. Кәһвә ясап куйган. Ашадым-эчтем дә театрга киттем. Кичен спектакль уйныйсым бар иде. Кайтуыма, чәчәкләрен-бүләкләрен күтәреп, балалар килгән. Бөтенебез бергәләшеп табынга утырдык. «Әни, әни», – дип өзелеп торалар. Аларның янәшәмдә булуыннан, кайгыртуыннан нинди ләззәт алуымны белсәң икән. Якыннарым күземә карап торганда, депрессиягә бирелеп, сузылып яту – аларга карата зур җинаять бит ул. Мин аларга кирәк! Моны белеп яшәү шундый зур көч бирә...


Фото: pexels.com



Сорауларга педиатр, эндокринолог Гүзәл ЯРУЛЛИНА җавап бирә

Яз көне күпләр витаминнар һәм йод препаратлары куллана башлый. Мәсәлән, бер танышым балаларына йодны ел дәвамында бирә, укучы балалар өчен аеруча кирәк дип саный. Анализ тапшырмыйча һәм эндокринолог белән киңәшмичә генә йод препаратларын кулланырга ярыймы?

– Консенсус буенча, бөтен укучы балаларга, йөкле хатын-кызларга, имезүче хатын-кызларга, калкансыман биз белән проблемалары булган балаларга йод препаратлары кулланырга ярый. Моның өчен эндокринолог киңәше мәҗбүри түгел.

5 яшендә улыбызның буе – 95 сантиметр. Туганда ук бәләкәй булып туган иде – авырлыгы 2300 грамм, буе 46 сантиметр. Үз яшендәге балалардан буе белән шактый аерыла. Бу күрсәткечләр эндокринологка мөрәҗәгать итәр өчен сәбәпме?

– Чынлап та, улыгызның буе үз яшенә күрә тәбәнәк. Яшь нормалары буенча ул озынрак булырга тиеш. Сезгә мәҗбүри рәвештә эндокринологка күренергә кирәк.

Кызыбызга 2 яшь. Нәселдә шикәр авырулы туганнар бар. Баллыга аллергия дә чыга. Сусыз тора алмый, күп эчә, еш тирли. Бармагыннан кан анализы биргән идек, 5,6 дигән нәтиҗә чыкты. Борчылырлык сәбәп бармы?

– Сезнең гаиләдә шикәр авыруы нәселдән килсә дә, ул кадәр тирән тикшеренүләр узуның кирәге юк. Ләкин елга бер булса да, кан анализын биреп, шикәр күрсәткечен контрольдә тотарга кирәк.

Нәниләргә күчтәнәч!

Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.





Сорауларга офтальмолог Фәрит ГЫЙЛЬМАНОВ җавап бирә

Балабызга алты ай. Бер күзе кыек карый. Ничә айга кадәр балаларда кыек карау норма санала? Аны ничек төзәтергә?

– Кечкенә балаларда кылый күзлелек 1 яшькә кадәр – гадәти күренеш. Ләкин күзләре бер дә туры позициягә басмаса, ягъни кылый күзлелек даими күзәтелсә, табибка мөрәҗәгать итегез. Тумыштан булган кылый күзлелекне (инфантильное косоглазие) хирург ярдәмендә дәвалыйлар.

Кызыбызның бер күзе тумыштан бераз кызарып тора. Табибка күренгәндә тайпылышлар күзәтелмәде. Ләкин прививка ясар алдыннан да кайвакыт педиатр кызарган күзгә игътибар итә иде. Гел шулай ул, дип әйтәм. Авырый башласа да шул күзе ныграк кызара. Берәр инфекция турында сөйләмиме бу кызыллык? Аны ачыклар өчен нинди анализ бирергә кирәк?

– Күзнең гел кызыл булып торуы сирәк хәл. Табибка нәкъ менә чир башланганда, күзләр тагын да ныграк кызарып чыкканда мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шул вакытта табиб тикшереп, кирәкле дәвалау билгеләр, кирәк булса, өстәмә тикшерүләргә җибәрер.

Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга хирург-ортопед Айрат ГАРИПОВ җавап бирә

2 яшьлек улыбызның аяклары «Х» хәрефе формасында. Йөргән вакытта читенлеген күрми кебек, борчылмый. Үскән саен аяклар үзләре дә турая, диләр. Ничә яшькә кадәр аякларның мондый формасы норма санала?

– Тезләрнең бу формасын «түбән очлыкларның вальгуслы деформациясе» дип атыйлар. Аның факторлары берничә була. $Д_3$ витамины җитмәү сәбәпле, кальций алмашы бозылу, артык авырлык, баланың тиз үсүе аркасында килеп чыгарга мөмкин ул. Табаннарның вальгуслы деформациясе дә моңа сәбәпче була ала. Әлеге факторлар өстендә эшләмәсәгез, тезләр үзеннән-үзе төзәлмәячәк. Алай гына да түгел, түбән очлыкларның күчәре начарлануы да бар. Тез буыннарының вальгуслы деформациясе нәтиҗәсендә табаннарның 5 см аерылуы нормаль вариант саналуын да исәпкә алырга кирәк. Төгәл диагноз куяр өчен ортопедка мөрәҗәгать итегез. Түбән очлыклар деформациясе 8–9 яшькә кадәр яхшы төзәтелә. Зуррак яшьтә дә деформацияне төзәтергә тырышырга киңәш итәр идем.

4 яшьлек кызыбызда яссы табанлылык. Нәселдә дә бар ул безнең, әтисендә дә шулай. Дәвалау белән соңга калмадык микән? Яссы табанлылыкны физиотерапия белән төзәтеп буламы?

– Бала тәпи киткәч, гәүдә авырлыгы табаннарга төшә. Нәтиҗәдә, табаннарның вальгуслы деформациясе барлыкка килә һәм табан яссылана. 4 яшькә инде ул аермачык сизелә. Сезгә беренче чиратта балтырның юан мускулларын һәм табан мускулларын стимуллаштыруга юнәлтелгән дәвалау гимнастикасы белән шөгыльләнә башларга, ортопедик аяк киеме кияргә, массаж курслары алырга кирәк. Физиотерапия юнәлешенә килгәндә, әлеге мускулларга электростимуляция ясау яхшы ярдәм итә. Яссы табанлылык 10–11 яшькә кадәр төзәтүгә бирешә. Зуррак яшьтә моны эшләү авыррак булачак.

Кызыбызга тиздән өч ай була. Еш кына, башын уң якка борып, баш артына караган кебек итә. Ятканда да шулай борылып ятарга ярата. Кулда тотып йөргәндә алай эшләми кебек, сизелми. Бер айлык вакытта медосмотр узганда табиб тайпылышлар тапмаган иде. Кәкре муенлылык түгел микән дип шикләнәм. Төзәтеп буламы аны?

– Сезнең сүзләрдән чыгып, балада сул яклы кәкре муенлылык дип фаразларга мөмкин. Еш кына аның сәбәбе – муен мускулларының спазмы. Сирәк очракта баланың туганда имгәнүе, умыртка баганасының муен өлеше үсү аномалиясе дә сәбәп була ала. Сезнең очракта Шанц якасы алып, көнгә дүрт тапкыр 40 минут дәвамында баланың муенына кидертергә кирәк. Муен-яка зонасына массаж да файдалы булыр. Баланың игътибарын җәлеп итеп, башын икенче якка борырлык итәргә тырышыгыз.

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

СОРАУ–ҖАВАП

АЧ ТОРЫП ЯШӘРӘБЕЗ



Ач тору – артык авырлык белән көрәштә иң шәп ысул, ди диетологлар. Ул бик авыр, күпләр андый диетаны тота алмый. Әмма нәтиҗәсе бик яхшы. Стресстан соң организм ныклап эшли башлый – тән күзәнәкләре яңара, органнар эшчәнлеге яхшыра, төрле ялкынсынулар кими. Мондый нәтиҗәне ашаудан калмыйча да аласы килә. «FMD дигән туклану системасы бар. Fast Mimicking Diet – ачлыкны имитацияләүче диета. Ул чагыштырмача яңа алым әле. Ашыйсың, ләкин гадәтләнгәннән азрак. Ә организмда инде күзәнәкләр чистару процессы бара», – ди врач-диетолог, терапевт, «Триатлон» үзәге диетологы Элина БОРҺАНОВА.

FMD диетасының асылы нәрсәдә?

– Бу диета ач торуны имитацияли. Биш көн буе гадәти тәүлеклек калория 34–54 процентка кими. Бөтенләй ашамыйсың түгел, әмма организм ач тора. Безнең күзәнәкләрдә зарарланган макромолекулалар, ДНКдагы мутацияләр җыела. Нормада күзәнәкләр аларны юкка чыгара, әмма төрле авырулар һәм картаю аркасында бу «чистарыну» авырлаша. Күзәнәктә «чүп-чар» барлыкка килә, һәм ул үлә. Ач тору – чистарыну процессын, ягъни аутофагия феноменын эшләтеп җибәрә. Ач тору күпләр өчен авыр бирелә, күбесендә ярамау очраклары бар. Шуңа күрә дә FMD-диета уйлап табылган. Биш көнгә рационнан терлек аксымын (ит, терлек мае, йомырка, сөт продуктлары, балык, ипине) аласың. Ашалган ризыклар калориясе тәүлегенә 800–700 ккалга төшә. Гадәти туклану вакытында тәүлеклек калория 3000 ккалга якын. Бу диетаны тотканда һәрвакыт ашыйсы килеп тору – нормаль күренеш. Аннан башка ач тору һәм чистарыну процессы башланмый. Хәл киткәндә кара чәй эчеп куярга мөмкин.

Бу диета кемнәр өчен файдалы?

– Артык авырлыгы булганнарга, диабет куркынычы янаганнарга, Альцгеймер, атеросклероз белән авыручыларга бу диетаны ай саен, ә сәламәт кешеләргә өч айга бер тапкыр тоту киңәш ителә. Балаларга, авырлы йә бала имезүче хатыннарга, хәлсез кешеләргә ач торырга ярамый. Хроник авыруы булган пациентлар табиб белән киңәшергә тиеш.

Диета тотканда нинди продуктлар ашарга ярый?

– Биш көн дәвамында туклану рационы яшелчә, яшел үләннәр, җиләк-җимеш, аз күләмдә төрле ярма, кузаклылар һәм чикләвекләрдән тора. Гомумән, ашарга яраклы азык-төлектән тәмле диетик ризыклар әзерләп була. Мәсәлән, яшелчәләрдән рагу, ашлар, ярмалардан төрле боткалар пешерергә мөмкин. Дөрес, алар майсыз һәм суда йә үсемлек сөтендә әзерләнергә, алты аш кашыгыннан артмаска тиеш. Баллы ризыклардан көненә ике-өч кипкән җимеш кенә ашарга ярый.

Организмга тагын нинди файдасы бар?


– Иң беренче чиратта ул ябыгырга ярдәм итә. Бу диетаны тотканда 2,7 кг авырлык югала. Бигрәк тә эч куышлыгы тирәсендәге май катламы азая, бил нечкәрә. Шунысын да әйтергә кирәк, мускул массасы үзгәрми. Ач торуны имитацияләү канда холестерин һәм шикәр дәрәҗәсен киметә. Димәк, йөрәк, кан тамыры авыруларыннан, II тип диабеттан – профилактика. FMD-диета шулай ук хроник ялкынсынуларны киметә. Бу исә иммунитетка яхшы тәэсир итә. Ә иң мөһиме: картаю процессын да тоткарлый. Әлеге диетаны тотканнан соң тышкы кыяфәт бермә-бер яхшыра. Ул шулай ук яман шеш авыруларына каршы (бигрәк тә күкрәктәге) әйбәт профилактика да булып санала.

МУСКУЛЛАРНЫ ЯЛ ИТТЕРӘБЕЗ

Үз-үзеңә массаж ясау өчен хәзер төрле җайланмалар шактый. Шуларның берсе – соңгы елларда бик популяр булган массаж ролигы. Ул цилиндр формасында, өслегендә махсус чыгынтылары бар. Тәндәге нокталарга тагын да ныграк басу өчен шулай эшләнгән ул. Көн саен берничә минут шөгыльләнү массаж сеансы алган кебек нәтиҗә бирер. Чөнки роллер мускулларны киеренке халәттән чыгару өчен менә дигән җайланма. Ул шулай ук мускуллардагы авыртудан файдалы, хәрәкәт диапазонын зурайта, билгеле бер урыннарда кан йөрешен яхшырта. Тренировкаларны җайлап һәм ашыкмыйча үткәрергә кирәк. Юкса тәнгә күгәрекләр чыгарга мөмкин. Тәнегезне тыңлап эшләгез, җайсыз булганда басымны башка җиргә күчерегез. Күнегүләрне безнең даими экспертыбыз, тренер Резеда МУСИНА өйрәтә.





■ Аякларны тездән бөкләп, аркага ятабыз, куллар – баш астында. Калак сөякләре астына роликны куябыз да арка буйлап тәгәрәтеп йөртәбез. Бу вакытта янбаш идәнгә тияргә тиеш түгел.

■ Янбаш мускулларын киеренкелектән чыгарабыз. Бу күнегүдә хәрәкәтләнмибез. Роликны янбаш астына куеп, башта сул якта, аннары уң якта берәр минут чамасы ятабыз.

■ Киләсе күнегү күкрәк диафрагмасын ял иттерү өчен эшләнә. Ян белән ятабыз, аякларны кисештерәбез, бер кул алга сузыла, ролик – калак сөяге астында. Икенче кулны баш астына куябыз да гәүдәне әле алга, әле артка хәрәкәтләндерәбез.

■ Бот мускулларына да массаж ясыйбыз. Моның өчен роликны аяк буенча тәгәрәтәбез.

■ Иң соңыннан ял итәбез: роликны койрык сөяге (копчик) астына куеп, кулларны сузып, бер минут ятабыз. Күзләрегезне йомсагыз да була. Әлеге күнегү мускулларны да, үзегезне дә тынычландырыр. Ролик белән массаж ясаганда тигез сулыш алу мөһим.



QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Сыр белән помидорлы самса





«Сөембикә» журналын укучылар Венера АРСЛАНОВАның рецептларын яратып өлгерде инде. Аш-су остасы булапак, ул көн дә куллана торган иң гади ризыкларны да үзенчә төрләндереп, яңа рецептлар уйлап чыгарырга ярата.
Бу юлы ул тәкъдим иткән самса да гадәти генә түгел – яшелчәле, сырлы самса.
Быелгы апрель Рамазан аена туры килә. Күпләрегез Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен ураза тотадыр. Венера ханымның рецепты белән шушы самсаны ифтар табынына әзерләсәгез дә оттырмассыз. Ул, әлбәттә инде, бик тәмле һәм туклыклы. Камыры кетердәп тора, помидор, салат яфрагы һәм сыр эчлегенә сусыллык һәм үзенчәлекле тәм бирә. Һәркемнең кулыннан килерлек, җайлы гына әзерләнә ул.



Кирәк Камыр өчен: / 250 мл җылымса кайнаган су / 400 г он / 1 чәй кашыгы тоз / 100 г йомшарган атланмай.
Эчлек өчен: / 300 г ит / 2 баш эре суган / 100 г сыр / 1-2 помидор / бер тотам яшел салат яфрагы / түменчә тоз-борыч, паприка.
Моннан тыш, самсаларның өстенә сылар өчен 1 йомырка да кирәк булачак.

Эш барышы итне өчпочмакка тураган кебек, вак кына шакмаклап турыйбыз. Терлек ите урынына кош итен дә кулланырга була.
■ Суганны ваклап турап, ит янына кушабыз. Тоз-борыч, паприка сибеп, барысын бергә болгатабыз.
■ Тирән эчле савытка су, тоз, он салып, кыстыбыйга баскан шикелле камыр басабыз. Камыр кулга ябышмаслык булсын.
■ Әзер камырны ике тигез өлешкә бүлеп, 15 минут ял иттерәбез. Өстен капларга онытмагыз, камыр җилләмәсен!
■ Ике кисәкне дә, кыстыбыйга җәйгән кебек, аерым-аерым җәябез.
■ Һәр ике җәемгә дә атланмай ягып, берсе өстенә икенчесен куябыз һәм рулет сыман тәгәрәтеп төрәбез.
■ Төргән камырны 60 граммлы 14 кисәккә бүләбез. Һәрбер кисәкне өлеш тәлинкәсе зурлыгында җәябез.
■ Һәр җәем төбенә берәр салат яфрагы куеп чыгабыз. Яфрак өстенә итле эчлекне салабыз.
■ Помидорны юып, артык юка итми генә тәгәрмәчләп турыйбыз. Эчлек өстенә берәр тәгәрмәч помидор куябыз. Помидор өстенә эре угычтан уылган сыр түшәлә.
■ Җәемнең читен өскә таба күтәреп, пәрәмәч бөргән сыман бөрәбез. Уртасын зуррак калдырабыз – сыр күренеп торсын.
■ Самсаларны майланган табага тезеп, өстеннән күпертелгән йомырка сылыйбыз һәм 180 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз.
■ 40 минуттан – өсте кызаргач, самсаларыбыз әзер була. Ашларыгыз тәмле, тоткан уразаларыгыз кабул булсын!





Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA

Өйнең яме — гөлләрдә


Бальзамин

Аны Уоллер яки Валлер бальзамины дип тә атыйлар. Татарча кына гөле, диләр. Тиз үсә һәм өзлексез чәчәк ата торган үсемлек.

Артык эссе булмаган, үтәли җилләрдән сакланган ышык урынны ярата. Кышын исә 15 градустан алып, 18 градуска кадәр булган салкынчарак җир яхшы. Кына гөле яктылыкка таләпчән, ләкин җәй челләсендә көн буена туры төшкән кояш нурларында яфраклары көя башлый. Көнчыгышка караган тәрәзә төбендә үстерүе кулайрак. Андый мөмкинлек булмаса, гөлне күләгәләргә кирәк.

Дымлы һавада ул яхшырак үсә. Эссе көннәрдә һаваны өстәмә дымландыруны сорый. Яфракларына, туфрагына су бөркегәнне ярата, чәчәкләренә генә су тидермәскә кирәк. Бальзамин шаулап чәчәк атсын дисәгез, туфрагының кибүенә юл куймагыз. Дым кимүгә, чәчәк бөреләрен коя башлый. Язын һәм җәен суны еш һәм мул итеп сибәләр. Кыш көне су сибүне сирәгәйтәләр, ләкин туфрак кибәргә тиеш түгел. Кына гөле чәчәк атарга керешкәнче, һәр язда туфрагын алыштыралар. Чүлмәкнең бик киң булмаганын сайлагыз, таррак савытта ул купшырак чәчәк ата. Күчереп утыртканда тамыр муентыгын туфрак белән күмдермәскә тырышыгыз. Шулай ук күчергән вакытта гөлне матурлап кисәргә дә кирәк. Кына гөлен шар рәвешендә формалаштырсаң матур. Ел дәвамында сузылып үсеп киткән тармакларын өзгәләп торалар. Кисkәннән калган тармакларны сулы савытка утыртып, тамырландырырга була. Кына гөлен орлыктан үстерүе дә җайлы. Орлыкларны апрель, май башында тәрәзә төбендәге савытларга чәчәләр. Көннәр җылыткач, бальзаминны бакчага да чыгарып утырта аласыз. Чәчәк аткан чорда калийлы-фосфорлы ашламалар белән ашлауга мохтаҗ. Җәй көне ике атнага бер тапкыр тукландыралар. Органик ашламаларны өнәп бетерми. Тынлык чорында үсемлекне тукландыруны туктатып торалар.

Диффенбахияне эре, матур яфраклары өчен, бүлмәне яшелләндерүче буларак яратып үстерәләр. Агулы үсемлек, күчереп утыртканда, формалаштырганда сак булыгыз. Ул дымлылыкның югары булганын ярата, салкынча, үтәли җил йөргән урыннарда начар үсә, чирли. Тагын бер үзенчәлеге – суның сыйфатына таләпчән, каты, известьлы суны яратмый. Андый суны тондырып кына сибәргә мөмкин. Ә иң яхшысы – кар яисә яңгыр суы куллану. Бу гөл якты урынны, шул ук вакытта кояш нурлары туры төшмәгәнне ярата. Чуар яфраклылары яктылыкка аеруча таләпчән. Иң яхшысы – кояшлы тәрәзәдән 1 метр ара калдырып урнаштыру. Караңгырак почмакта утырса, ясалма яктыртырга кирәк булачак. Температура 20 градустан җылырак булса яхшы. 15 градус җылылык – иң түбән чик. Яз һәм җәй суны мулдан сибеп, кышын су сибүне киметәләр. Ләкин гөлнең туфрагы кибәргә тиеш түгел. Төбенә дә су җыелып утырмасын. Җәй көне һаваны өстәмә дымландыруны, яфракларына еш су бөркеп торуны сорый. Диффенбахияне җәй көне ике атнага бер тукландыралар. Иң мөһиме – ашламада известь булмасын. Аксыл чуар яфраклы төрләрен органик булмаган ашламалар белән ашлау яхшырак. Гөлне тамырлары савытка сыймый башлагач күчерәләр. Моның өчен февральдән башлап май башына кадәрге вакыт кулай. Савытның зуррагын сайлагыз, чүлмәк төбенә калын итеп дренаж салып калдырыгыз. Тиз үскәнлектән, диффенбахиянең аскы өлеше еш кына шәрәләнеп калучан. Бу очракта өске өлешен кисеп алып, тамырландырып утыртырга була.




Амариллис

Суганчалы бу үсемлекнең кыяксыман яфраклары 0,6 метрга кадәр җитә. Аны еш кына гиппеаструм белән бутыйлар. Аннан аермалы буларак, амариллисның чәчәк сабагының эче куыш булмый һәм яфракларын да бары чәчәк атмаганда гына күрергә мөмкин. Җәен температураның – 23 градус, тынлык чорында салкынчарак, 10 градус тирәсе булганын ярата. Амариллис гадәттә август ахыры, сентябрь башында чәчәк ата. Чәчәк ату чоры ике ай дәвам итә. 15 елдан картрак гөл чәчәк атудан туктый. Яктылыкка таләпчән. Көньякка караган тәрәзә төпләрендә яхшы үсә. Яктылык җитәрлек булмаса, чәчәккә бөреләнми. Бүлмәдә дымлылык нормада булса, өстәмә дымландырырга кирәкми. Яфракларын актив үстергән чорда айга бер ашларга кирәк. Моның өчен органик (сыер, тавык тизәге) ашламалар да, минераль ашламалар да ярый. Минераль ашламаларның азот кимрәк, ә фосфор белән калий күбрәк булганын сайлагыз.

Амариллисны сирәк, 4-5 елга бер генә күчерәләр. Күчерү өчен актив үсә башлаган чор яхшы. Чүлмәкнең авырын, тарын, ләкин биеген сайлагыз. Биеклеге 20 сантиметрдан да кимрәк булмасын. Утыртыр алдыннан суганчаларны сыек алсу төстәге марганцовка эремәсендә тотып, чирләрдән арындыралар. Туфракка күмдергәндә суганчаның өчтән бер өлеше өскә чыгып калсын. Бөтенләй күмдерсәң, чәчәк сабагы черергә мөмкин. Чәчәк атып бетереп, яфраклары корыгач, үсемлекнең тынлык чоры башлана. Бу вакытта суны бик сирәк, туфрагы кипкәннән-кипкәнгә генә сибәләр. Артык дымны авыр кичерә. Корый, саргая башлаган яфракларны өзмәскә кирәк, андагы туклыклы матдәләр суганчага күчә. Ә менә сулган чәчәк сабагын төбеннән кисеп алырга мөмкин. Җәй көне гөлегезне бакчага да чыгарып утырта аласыз. Ачык туфракта ул тагын да матуррак чәчәк ата.



Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Фото: www.pixabay.com

тест: нервларыгыз сәламәтме?

Тиз ритмга көйләнгән бүгенге тормышыбыз нерв системасына киеренкелек өсти. Кызып китүчәнлек, ярсу, хисләрне йөгәнләп калуның кыенлыгы – болар бар да әнә шул системаның эшендә чатаклыклар барлыгы турында сөйли. Көн дә очрап торган ярсыткычлар сезне чыгырыгыздан чыгара аламы? Әлеге сорауларга якынча гына җавап биреп тә, нерв системагызның никадәр тотрыклы эшләвен белергә мөмкин. Сорауларга җавапны түбәндәгечә бирергә мөмкин: бик, алай ук түгел, беркайчан да. Сезне ярсытамы:

- сез укырга теләгән газетаның бите бөгәрләнгән булу;
- өлкән яшьтәге хатын-кызның яшь кызлар кебек киенүе;
- сезнең белән сөйләшеп торган кешенең артык якын килүе (әйтик, трамвайда тыгын чакта);
- урамда тәмәке тартучы хатын-кыз;
- берәрсе сезгә карап йөткерсә;
- кемдер тырнагын кимерсә;
- кемдер сәбәпсез көлсә;
- кемдер сезне нәрсә эшләргә һәм ничек эшләргә кирәген өйрәтә башласа;
- яраткан кызыгыз (яки егетегез) гел соңга калса;
- кинотеатрда алдагы рәттәге кешенең борылгалап, фильмның сюжетын шәрехләп утыруы;
- әле генә укырга җыенган романыгызның эчтәлеген кемнеңдер сөйләргә тырышуы;
- кирәкмәгән әйберләр бүләк итүләре;
- җәмәгать транспортында кемнеңдер каты кычкырып сөйләшүе;
- артык көчле булган хушбуй исе;
- сөйләшкәндә кешенең кулларын бутый-бутый сөйләве;
- гел чит ил сүзләрен кыстырып сөйләшүче коллегагыз.

Сорауга «бик» дип җавап бирсәгез, 3 очко куегыз; «алай ук түгел» дигән җавапның һәркайсына – 1 очко, «беркайчан да» – 0 очко.

50 очкодан артыграк. Сезне сабыр һәм тыныч кеше дип әйтеп булмый. Сезне бөтен нәрсә, хәтта вак-төякләр дә ярсыта ала. Сез кызып китәсез, хисләрегезне тыеп кала алмыйсыз. Бу исә нерв системасының бик нык какшавына китерә. Сезнең белән якыннарыгызга бигүк рәхәт түгелдер.

Очколар саны – 12 дән алып 49 га кадәр. Сез халыкның күпчелегә керә торган төркемгә карыйсыз. Тиз кызып китмисез, нервларыгызны вак-төяк өчен әрәм итмисез. Ошамаган әйберләргә «аркагыз белән борыла» беләсез, аларны тиз онытасыз.

11 һәм аннан да кимрәк очко. Сез тыныч, сабыр кеше. Тормышка аек күз белән карыйсыз. Бәлки, бу тест сезне җитәрлек дәрәҗәдә ача алмагандыр. Ни генә булмасын, тиз генә чыгырдан чыга торган кеше түгелсез.

йолдызнамә май

Кучкар. Ыгы-зыгылы вакыт булса да, тормышыгызның уңышлы чоры. Айның беренче яртысы шактый катлаулы тоелыр, ләкин аннары инде тырышлыгыгызның нәтиҗәсен һәм уңайлы үзгәрешләрне күрерсез.

Үгезбозау. Глобаль үзгәрешләр көтелә. Үткәндәге борчулар белән мәңгегә саубуллашып, киләчәккә ныклы адымнар белән атлый торган чагыгыз. Лидерлык сыйфатларыгыз өстен чыгачак.

Игезәкләр. Ай башында бераз катлаулырак булыр. Яшәү көчегезнең кимеп китүен тоярсыз. Бу физик халәттә генә түгел, рухи яктан да үзен сиздерер. Моңа узучы хәл итеп кенә карагыз, тиздән бар да җайланыр.

Кысла. Киләчәккә глобаль планнар кору һәм уңышлы проектларга керешү өчен әйбәт вакыт. Хезмәт, эш өлкәсендә абруегыз артыр. Нииндидер көтелмәгән мәшәкатьләр килеп чыкса да, сез аларны җайлы гына хәл итәчәксез.

Арыслан. Бар да сез теләгәнчә генә бармас, бигрәк тә айның беренче яртысында. Ләкин күңелегезне төшерергә кирәкми, ай урталарында хәл уңай якка үзгәрер. Һөнәри яктан үсеш кичерерсез.

Сөмбелә. «Бер кул белән төен төйнәмиләр» – бу айның лейтмотивы әнә шундый. Дусларның, танышларның никадәр мөһимлеген тагын да ныграк аңлый башларсыз. Әлеге чор элемтәләр урнаштыру, аралашу, килешүләр чоры булачак.

Бизмән. Үзегезгә буй җитмәс планнар куймагыз. Ай башында бераз төшенкелек сизелер. Финанс өлкәсендәге мәсьәләләрне дә хәл итәргә туры киләчәк. Ай ахырында яхшы гына перспективалар көтелә, аларны кулдан ычкындырмагыз.

Чаян. Үзгәреш җилләре исәр. Көтмәгәндә үзенә бөтереп алган вакыйгалар барлык борчуларны оныттырыр. Яңа танышулар, яңа башлангычлар ае бу. Гадәтләнгән тормышыгызга яңалыклар ургылып керер.

Укчы. Тукталмаска! Айның шигаре сезнең өчен – шундый. Тырыш хезмәт һәм үҗәтлекнең уңай нәтиҗәсен күрәчәксез. Ләкин артык тырышып, сәламәтлегегезне какшата күрмәгез.

Кәҗәмөгез. Бу айда сезне галәм көчләре үзләре саклый. Тормыштан канәгатьләнү хисләре кичерерсез. Талантыгызны күрсәтергә җай чыгар. Язмышның бүләкләре мулдан булыр.

Сукояр. Айның башы шактый мәшәкатьле – яңа проектлар турында уйларга, яңа элемтәләр урнаштырырга туры килер. Тормыштан нәрсә көткәнегезне яхшы беләсез, көчегез җитәрлек – барысын да уңышлы башкарып чыгарсыз.

Балык. Уңышлы, нәтиҗәле, рәхмәтле ай. Югары көчләр сезгә үзләре ярдәм итә сыман. Яңа мөмкинлекләр ачылырга тора, аларны кулыгыздан ычкындырмагыз. Үзегезне бөтенләй башка яктан күрсәтергә менә дигән форсат килеп чыгар.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.





МӨСЕЛМАН КАНУННАРЫН ҮЗ ИТТЕМ

Рәссам-дизайнер Дания Әгъзамова Үзбәкстанда татар гаиләсендә туган, тик аларның гаиләсе 1993 елдагы сәяси киеренкелек башлангач та үз туган якларына – Башкортстанның Фёдоровка районы Фёдоровка авылына кайтып төпләнгән. Дания, урта мәктәптән соң, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университетында читтән торып укыган, шул ук университет кафедрасында эшләгән. «Университетта мин үзем кебек үк яулык бәйләп йөрүче курсташ кызлар белән бергәләп пыяла өлекләргә шәмаилләр ясарга өйрәндем. Без аларны күпләп ясадык һәм уңышлы гына саттык та хәтта. Сынлы сәнгать-графика факультеты деканы, хөрмәтле укытучыбыз, танылган рәссам, декоратив-гамәли сәнгать остасы Тәлгать Хәсән улы Мәсәлимов безне шушы техника нечкәлекләренә төшендерде. Диплом эшем дә пыяла өлеккә «Ашыгыз тәмле булсын!» дигән гарәпчә язулы бизәкле өстәл булды. Уфада бертуган апам Гөлнара, дус кызым Розалия белән «Ихлас» мәчетендәге мөселман дине курсларына йөрдек. Мөгалиммәбез Фатыйма Фәтхуллина мине булачак хәләл җефетем – 16 яшеннән үк намаз укучы Рөстәм белән таныштырды. Без бәхетле гаилә кордык! Бу вакытка инде мин бар мөселман кануннарын барлап, аларны үз иткән идем.

Фаҗига белән бәйле вакыйга ислам динебез кануннарын тирәнтен өйрәнә башларга тәэсир итте. Без утырган очкыч күккә күтәрелгәч, бер двигателе яна башлады, бар тормышым күз алдыннан үтте, үлемгә әзер булмавымны аңладым. Әлхәмдүлилләһ, бар да яхшы тәмамланды. Намазлар укый идем инде. Шушы мизгелләрдән соң динебезгә, мөселман догаларыбызга тагын да яхшырак төшенә башладым», – ди үзе турында Дания Фәнил кызы. Уфада ул сәләтле мөселман стилисты һәм визаж белгече буларак таныла. «Матурлык салоны ачарга да хыялланган идем. Әмма бер көн ирем Мәскәүгә күченәчәгебез хакында әйтте. Ул – бик талантлы программист. Башкалада матурлык академияләре курсларын үтеп, яңа белемнәр тупладым һәм татар кәләшләребезнең үтенечләре буенча аларга шәрык макияжын ясый, туй күлмәкләрен сайлаша, башларына бәйрәмчә итеп яулык бәйли башладым».


Дания Мәскәү татарлары арасында да иң яхшы, иң төгәл осталарның берсе булып таныла. Фикердәшләре белән бергәләп Мәскәүдә өч ел рәттән Никах фестивальләре оештыра, татар яшьләрен үз милли традицияләребезгә өнди. 2017 елдан башлап яшь милләттәшләребез өчен күп мәгълүмат туплаган «NIKAH day» журналының редакторы була.


«Әзер каллиграфик язмаларны киндерләргә күчереп, аларны язганда майлы яисә акрил буяулар кулланып, күңелемә хуш килгән татар, төрек, фарсы орнаментлары белән бизәп ясау миңа илһам өсти. Гадәттә, яшел, зөбәрҗәт, алтын төсләр белән ясалган сыйфатлы хезмәтләремне ошаталар, алар заманча интерьерларга туры килә. Төрки халык орнаментлары – катлаулы, бизәкләрдәге бихисап кечкенә детальләрне ясау өчен күп вакыт таләп ителә, әмма бу төр иҗат миңа бик ошый, шуңадыр да, ясалып бетүгә үк орнаментларга озаклап карап утырырга яратам! Беренче шәхси күргәзмәм 2016 елда Мәскәүнең «Крокус» сити-холлында үтте, анда җиде мең кеше җыелган иде. Дулкынландым. Хезмәтләремне ошаттылар», – ди рәссам.

Хәзер ул ире Рөстәм, уллары Фатих һәм Ридван, узган ел шушы якты дөньяга килгән кечкенә игезәкләре Җәмил һәм Вилдан белән Төркиядә, Анталья шәһәрендә яши. Олы уллары Россия уку программалары буенча оештырылган онлайн-мәктәптә укыйлар. Кечкенә уллары бераз үскәч, бакчага йөри башлар, Дания дә янә иҗат шатлыкларына әйләнеп кайтыр.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА










ДАНИЯ ӘГЪЗАМОВА





ӘЙДӘГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫЙК, ЯҢА ДУСЛАР ТАБЫЙК, БӨТЕН ДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН БЕРЛӘШИК!

Хатлар йорты – открыткалар җибәрү сервисы



16+

ООО «Медиа – партнёр» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2, пом. 14, ГРН 1111690004469. Реклама